ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

әһәмиятле / игелекле / мәңгелек

№ 12 (347)
ДЕКАБРЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

100

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА ЯШЬ

“

**Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы
Президенты:**

– Безгә борынгы бабаларыбызның бөек рухы белән сугарылган ватаныбызда туарга, яшәргә һәм үз халкыбызга хезмәт итәргә насыйп булды. Казанышларга бай йөз еллык тарихи юл – безнең горурлыгыбыз һәм киләчәк көнгә ышанычыбыз ул!

ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Сезнең кулыгызда «Татарстан»-ның юбилей саны – декабрьдә республиканың төп журналына 100 яшь тулды! Ул республикабызның яшьтәше һәм елъязмачысы. 100 ел эчендә журнал «Вестник Татарского областкома РКП (б)» хәзерге «Татарстан»гакадәр 9 тапкыр исемен алыштырган. Журналның әлеге тыгыз «тормышында» ТАССРның бөтен тарихы чагылыш тапкан.

Басма нәшер ителгән бер гасыр дәверендә нәрсә үзгәргән? «Татарстан» сезгә журналның төрле еллардагы 9 санынннан республика үсешенең 9 төп темасын яктырткан мәкаләләр тәкъдим итә. Элек ничек булган, хәзер ниндигә әйләнгән – боларны редакциядә төрле елларда эшләгән журналистлар язмалары мисалында күрсәтә. Ничек язганнар, ничек яктыртканнар, ничек битләргә салганнар... Ничек итеп «хезмәт ияләре үтенечe буенча» журнал исемен үзгәрткәннәр...

Димәк, башта «Вестник Татарского областкома РКП (б)» булган – раритет журналның тышлыгында «туган көне» итеп нәкъ менә 1920 елның 1 декабре күрсәтелгән. Беренче санның баш мөхәррире һәм оештыручысы – РКП (б) Татар өлкә комитетының беренче секретаре Александр Таняев. «Хәбәрче» сәхифәләрендә иң төп темалардан берсе яшь Татар республикасы хезмәтчәннәре йөрәгеннән һәм башыннан «халык өчен әфьюн булган» динне кысрыклап чыгару булган. Ә бүген Татарстанда дингә караш нинди? Боларга җавапны сез инде берничә биттән соң ук таба алачаксыз.

«Татарстан» журналының беренче гасыры хатирәләре буенча «сәяхәтегез» рәхәт һәм ләззәтле булсын!

Сезнең мәңге яшь йөзьяшәр редакциягез.

ЭЧТӘЛЕК

1 «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ НИЧЕК ОЕШКАН
- Татарстанда рухи дөньяны ничек җимергәннәр һәм торгызганнар

7 «ВЕСТНИК» НИ ӨЧЕН «СПУТНИК»КА ӘВЕРЕЛӘ
- Яшь Татреспубликадан халык ни өчен читкә агыла һәм бүген кешеләр яшәү өчен ник Татарстанны сайлый

13 «СПУТНИК АГИТАТОРА» НИ РӘВЕШЛЕ «КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ» ЖУРНАЛЫНА ӘЙЛӘНӘ
- Милли проектлар авыл тормышына нинди йогынты ясый

19 «КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ» ЖУРНАЛЫ «ПУТЬ ИЛЬИЧА» БАСМАСЫННАН НӘРСӘСЕ БЕЛӘН АЕРЫЛА
- Ни өчен кытайлылар Ленино-Кокушкинога килергә ярата

25 «ПУТЬ ИЛЬИЧА» ЖУРНАЛЫ НИ РӘВЕШЛЕ «ПРИЧАЛ» БУЛЫП КИТӘ
- Татар ләләсе чәчәк аткан мәлдә

31 «ПРИЧАЛ» НИЧЕК «СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА» ЖУРНАЛЫНА ӘЙЛӘНӘ
- 2021 елда Россиядә халык санын алу ничек үтәчәк

37 «СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА» НИ РӘВЕШЛЕ «ТАТАРСТАН БОЛЬШЕВИГЫ» ДИГӘН ИСЕМ АЛА
- «Татарстан» хәбәрчеләре репрессия эзләре буйлап йөриләр

43 «ТАТАРСТАН БОЛЬШЕВИГЫ» НИ ӨЧЕН, ИСЕМЕН ҮЗГӘРТЕП, «ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ»НА ӘВЕРЕЛӘ
- Заманча сәнгать галереясы ТАССР Күргәзмәләр залы эшен ничек дәвам итә

49 НИ ӨЧЕН «ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ» ПАРТИЯ БАСМАСЫ БУЛУДАН ТУКТЫЙ
- Республикабыз нефтьчеләре ничек итеп илебез икътисады өчен алгарышлы технологияләр уйлап табалар һәм сыныйлар

Редакция ТР Милли китапханәсенең периодик басмалар бүлеге коллективына ярдәмнәре өчен рәхмәтен белдерә.

ВЕСТНИК

На переломе.

1920

«ВЕСТНИК ТАТАРСКОГО ОБЛАСТКОМА РКП (б)» ЖУРНАЛЫ

Дөньяга туган чагында – 1920 елның 1 декабрендә – журналга «Вестник Татарского обласкома РКП (б)» дигән исем бирелгән. Аның беренче саны, ТАССР оешу турындагы Декретка кул куелганнан соң ярты ел үткәч, 3000 данә тираж белән дөнья күрә һәм яшь республиканың яңа теоретик һәм сәяси басмасына әверелә. Журнал партия эшчәнлеген, пролетариат тормышын яктырта, төрле циркулярлар һәм инструкцияләр бастыра, агитация һәм пропаганда белән шөгыльләнә.

МӨХӘРРИР



Александр Таняев

1920 елның 1 декабрендә дөнья күрәчәк «Вестник Татарского обласкома РКП (б)» журналының беренче санына Мәскәүдәге Октябрь кораллы восстаниесендә катнашкан һәм тарихка тәүге РКП (б) Татар өлкә комитетының беренче секретаре булып кереп калган Александр Таняев кул куя.

«Тыштан бик яшь күренгән Таняев бик гади һәм сөйкемле була, кешеләр белән гади сөйләшә, тагын да яхшырагы – тыңлый белә...» – журналның беренче мөхәррире турында замандашлары әнә шундый истәлекләр калдырган. Александр большевистик идеяләрне кәгазьдә дә аңлаешлы итеп җиткерә белгән. Партия әйдәманы һәм Мәскәү университетының физика-математика факультетын тәмамлап өлгерә алмаган студентның язмалары республика газеталарында даими басылып тора. Аның иҗат үрнәкләреннән берсе «Контрреволюция не дремлет» дигән мәкалә була. «Совет власте өчен уртак көрәш барышында берләшкән рус һәм татар хезмәт ияләре массалары, – дип яза автор, – почмаклардан торып, арттан килеп һөҗүм итүләргә совет власте тирәсендә тагын да ныграк туплану белән җавап бирәчәк, милли аерымлыклар таратуга каршы алар рус һәм татар хезмәт ияләренең тагын да ныграк берләшүе белән җавап кайтарачак».

Александр Таняев мөхәррир булып бер елдан да азрак вакыт эшли. 1921 елда партия аны Урта Азиягә командировкага җибәрә. Аннары Мәскәүдә Кызыл профессура институты, докторлыкны яклау, РСФСРның Мәгариф халык комиссариатында эшләү һәм 1937 елда кулга алыну булачак... ГУЛАГта 19 ел гомерен үткәргәннән соң, Таняев 1956 елда гына ирекккә чыгачак.

...1965 елда КПСС ҮК каршындагы Партия тарихы институты профессоры Александр Петрович Таняев Казанга килә. Бауман урамындагы Матбугат йортында журналистлар белән очрашканда ул үзенең фикерләре белән уртаклаша: «Мин, әлбәттә, илебездәге һәр урындагы кебек үк, Татариядәге уңышларның да бинһая зур булуына шикләнми идем. Әмма биредәге үзгәрешләр мине шаккатырды... Тик безнең үткәннәрне дә онытырга хакыбыз юк. Аларны белү ирешелгәннәрне бәяләргә, үткән юлны тулырак күзалларга мөмкинлек бирәчәк».

Репрессияләнгән. ГУЛАГта 19 елын үткәргән. 1956 елда акланган.

ИМАН АКАДЕМИЯСЕ

Автор: Ксения Сёмина

Дөньяга туган чагында «Вестник Татарского обласкома РКП (б)» дип аталган журналыбызның беренче саны безнең көннәргә кадәр сакланып калган. Әлеге басма белән танышканда игътибарыбызны «О работе на Востоке» дигән язма җәлеп итте. Көнчыгыш халыкларын милли изүдән коткару эшен, дингә каршы көрәшне көчәйтергә кирәк диелә анда. Бүгенге көндә рухи кыйблабыз нинди? Дини яңарыш нинди хәлдә? Юбилей санында үткәннәр белән бүгенгене чагыштырырга уйладык.

...Очлаеп килгән тар тәрәзәле бина ниндидер борынгы шәһәр кирмәнен хәтерләтә. Әлеге диварлар бик сайлап алынган, сирәк затларга гына ачык белем-гыйлемнәрне саклый. Без әлеге кирмән эченә – Болгар ислам академиясенә кереп, ата-бабаларыбызның рухи мирасын өйрәнүнең ни өчен бүген аеруча актуаль икәнлеген ачыкладык.

Фото: Александр Ефремов

Экскурсиянең беренче тукталышы – гыйбадәт залы. Озын коридорларда – сүрән генә яктылык сирпи, келәмнәр атлаган тавышларны баса, һәм дөнья ыгы-зыгысы каядыр артта калып югала. Китапханәгә барышлый коридорда берничә студентны очратабыз. Бер төрле фасондагы камзуллар һәм түбәтәйләр аларга җитди, мондый уку йорты өчен килешле кыяфәт бирә. Мин аларда гүя XX гасыр башы Казан мәдрәсәләре шәкертен күрәм, бәлки дә Мәүләви дәрвишләренә охшатамдыр. Тик шунда аларның берсе, заманча гаджетын алып, иптәшенә экранда нидер күрсәтә башлый...

КҮҢЕЛГӘ ДӘВА

Без иркен намаз залына керәбез. Кояш нурлары, биек пыяла түбә аша үтеп кереп, залны яктылыкка күмә. Монда без ислам кануннары һәм фикъһе, шул исәптән гаилә законнары белән бәйле фәннәр укытучы **Сәйф Али Мөхәммәд Әл-Асри** көтә. Бу темаларны студентлар мәхәллә кешеләренең көндәлек сорауларына дөрес һәм тулы җавап бирә алыр өчен өйрәнә. Шәех Әл-Асрига мин әнә шундый сорауларны бирәм дә. Мәсәлән, имам кешенең никахны саклап калырга булыша алу-алмавы турында.

– Хәдистә әйтелгәнчә, сиңа кыз димләргә килгәндә, аның ни-нәрсәсе барлыгын карарга кирәк. Мөлкәт турында да искә алына, әлбәттә, ләкин иң элек – кызның Аллаһтан куркуы, аны санлавы мөһим. Әгәр дә бу бар икән, андый хатын гаиләгезне саклап калачак. Шул рәвешле Пәйгамбәр кешелек сыйфатларын беренче урынга куя. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң яхшы үрнәге – Мөхәммәд пәйгамбәрнең әдәп-әхлагы һәм аның хатыннарына карата мөгамәләсе. Пәйгамбәрнең борчу-мәшәкатьләре бихисап булса да, ул хатыннары белән бик йомшак мөгамәлә кора. «Арагызда иң яхшыгыз – гаиләсенә карата яхшы мөгамәлә кылучы», – ди ул. Имам – Пәйгамбәрнең җирдәге илчесе. Ул, кайда, нәрсә сөйләргә кирәклеген белеп, җәмгыятьтәге кайбер мөнәсәбәтләрне ничек яхшыртып булганын өйрәтергә, аның яраларына татулаштыра торган бәлзәм, дәва сөртергә, күп проблемаларны чишә алырга тиеш, – дип җавап бирә соравыма Әл-Асри.



Социально-экономическая жизнь этого Востока уже имеет определенное русло, вполне отвечающее требованиям революции, но духовная жизнь, религия, обычай, национальные обряды еще глубоко гнездятся в его душе. Вот с этим чудовищным злом и надо бороться, бороться умело и организовано, ибо до сего времени бедный деревенский Абдул с богачем 'Ахмедом все еще ходят в одну мечеть, на одно кладбище и выражают свои глубокие религиозные чувства одинаково, пред одним алтарем.

БЕЛЕМ – КӨЧ. ҺӘМ ИМИНЛЕК

Китапханәгә үтәбез. Биредә заман өчен гадәти манзара – компьютерлы өстәлләр, бүләк китаплар куелган киштәләр. Төрле телләрдә – поляк, мажар, төрек һәм башка телләрдә басылган Коръәннәр. Академиянең өч ел эшләү дәверендә биредә 20 меңгә якын китап җыелган, аларның 90% – гарәп телендә. Әлеге белем учагында да технологияләр алда бара: бөтен каталог – электрон форматта, ә һәр китапка RFID-тамгалау җайланмасы көйләнгән, теркәлмичә генә алынган китап белән чыгып китәргә уйласаң, ул чыелдап хәбәр сала. Тик мондый хәл бик сирәк була. Ябык ишекләр артында исә – китап саклау урыны. Без эчкәрәк керә алмадык – ни кызганыч! Күптән түгел бирегә XV–XIX гасырларга караган Европа басмаларыннан гыйбарәт уникаль коллекция – академиянең химаячеләр советы әгъзасы Алишер Усмановның затлы бүләген алып килгәннәр.

Без бер студентның игътибарын читкә юнәлтеп, укудан аерып торабыз. **Рөстәм Цику** – магистратураның I курсында укый. Ул Адыгеядан килгән, анда имам-мөхтәсиб булып хезмәт куя. Эш барышында аңа шактый күп тормышчан мәсьәләләр чишәргә туры килә.

– Безнең мөхтәсибәткә 16 мәчет керә, аларда вәгазь, лекцияләр укыйбыз, мәхәллә халкы белән очрашулар үткәрәбез. Биредә ала торган белемем бүгенге шартларда бик кирәк. Хәзер, мәсәлән, бездә РФ хокук фәне буенча академик курслар бара. Мин мәхәллә кешеләренә аларның күбесе өчен таныш булмаган законнар турында сөйли алам. Әйтик, экстремистик рухтагы контентка лайк куйган һәм репост ясаган өчен җәза бирүне күздә тоткан нормалар турында, – дип аңлата Рөстәм. – Дингә кагылышлы темалар һәрвакыт бик четерекле. Провокациягә яшьләр генә түгел, ә инде төрле хезмәт баскычларын узган, югары белемле, тормышта үз урынын тапкан кешеләр дә бирелә. Әгәр мөэмин кешегә, фәлән-фәлән эшне Аллаһ хуплый, дисәләр, мондый сүзләр кайвакыт уйлап та тормыйча гамәлләр кылу өчен җитә кала. Бу юнәлештә эшләргә кирәк әле.

«СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘР» – ЯТЬМӘ УЛ

Безгә укучылар яши торган бүлмәне карарга рөхсәт иттеләр. Ул кунакханәдәге номерга охшаган – җыйнак, пөхтә. Үзендә үк душ кабинасы куелган ванна бүлмәсе бар, язу өстәле, суыткыч, караватъ... Монда кергәч, иң элек акылга шундый уй килә – заманалар үзгәрә, ә дини тәгълиматны өйрәнүче шәкертләрнең аскетизмы барыбер кала. Башкача, мөгаен, бу эшкә бар булмышың белән чуму мөмкин дә түгелдер. Сүз уңаеннан, укучылар арасында хатын-кызлар юк, академиядә ир-атлар гына белем ала. Буйдак студентлар без күргән кебек бүлмәләрдә яши. Гаиләлеләре Болгар шәһәрендә

фатирга кереп тора. Белем алучылар инде күп еллар имам булып эшләүче өлкәннәр дә шактый.

– Минем үз бизнесым бар иде һәм мәдрәсәдә дә укыттым. Аксакаллар вакытлыча «Нур» мәчете имамы вазыйфаларын башкаруымны үтенде. Мин риза булдым. Шулай 12 ел узып та китте, – дип сөйли Чистай шәһәре һәм районы имам-мөхтәсибе Мөхәммәт хәзрәт Кыямов. Хәтта аның кебек зур тәҗрибә туплаган имамнарга да академия бик күп гыйлем бирә ала. Мәсәлән, яшьләр белән уртак тел таба белүдә ярдәм итәргә мөмкин.

– Бүген өммәт нигездә 14–40 яшьлек егетләрдән тора. Алар бик күп сораулар бирә, ә җаваплар билгеле бер әзерлек таләп итә. Көн тәртибендә – балаларны һәм яшүсмерләрне деструктив, экстремистик оешмаларга, төркемнәрдән алып калу проблемасы. Явыз ниятлеләргә бу эштә интернет ярдәм итә. Анда яшүсмергә бик каты теләп тә, үзендә булдыра алмаган нәрсәләрне вәгъдә итәләр һәм бирәләр: ниндидер югары дәрәҗә, чиксез игътибар, акча, нинди дә булса рухи яраларны ачу, көчле кешеләр үрнәге. Андыйлар нормаль җәмгыятьтә дефицит. Күз салыгыз әле: хәзерге егетләр һәм кызлар кемгә охшарга тырыша – модельләр, инстаблогерлар, рэперларга. Яшьләребезгә бөтенләй башка кешеләрнең үрнәк алу өчен лаеклы булуын күрсәтү – безнең бер бурычыбыз, – ди Мөхәммәт хәзрәт. – Без аларга үз яшәү рәвешебезгә йөз тотарга тәкъдим итәбез. Чистайда безнең мөхтәсибәт төрле социаль проектлар оештыра. Безгә «Камалия» мәдрәсәсенең тарихи бинасын кайтардылар, һәм без анда 3 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшүсмерләр өчен «Камалия» исемле ял үзәге ачтык. Кайсы динне тоту монда әһәмиятле түгел. Мөселман яшьләре һәм өлкәннәр өчен без «Чәкчәк» гаилә клубын ачып җибәрдек. Православие җәмәгатьчелеге белән бергә, без көнгә өч тапкыр бушлай ашата торган социаль ашханә ачтык һәм кием-салым җыю-тапшыру үзәген оештырдык. Болар барысы да – «чын иман» һәм «толерантлык» сүзләренең ни белдергәнен төгәл күрсәтеп бирә торган мисаллар.

ХАК ИСЛАМ ЯКТЫСЫНДА

Сәяхәтебез дәвам итә – без иркен, матур уку бүлмәләренә күз салабыз. 3 еллык магистратура яки 2 еллык докторантура дәвамында биредә сөнни апологетика теориясе һәм практикасы, ислам һәм Россиядәге мөселман халыклары тарихы, ислам хокук белеме һәм аның методологиясе, Коръән белеме, хәдис белеме, фәнни-дини тикшеренүләр методологиясе, риторика һәм башка фәннәр өйрәнелә. Мин ноутбукларда ачылган гарәпчә текстлар күрәм. Борынгылык белән бүгенге көн арасындагы киртәләр юкка чыга. Сыйныф такталары урынына хәзер – экраннар, аларда вебинарлар бара – пандемия чорында күп кенә дәресләр онлайн-режимга күчерелгән. Студентлар Мәскәү, Санкт-Петербург, Дамасктагы укытучылары белән шул рәвешле аралаша.

– Мин Россиядә өч ел яшим, һәм үзем өчен ясаган төп ачыш: руслар – бик ихлас һәм гадел кешеләр. Моннан тыш, мин монда төрле конфессия вәкилләренең тыныч яшәвенең, нәтиҗәле тормыш алып баруының бик матур үрнәген күзәтәм, – дип сөйли шәех **Мөхәммәд Айман әз-Захрави.** Ул да фикъһе фәне белән бәйле дәресләр укыта. – Татарстанның үз академиясен булдыру өстенлеге, беренче чиратта, биредә хак ислам нигезләре өйрәтелүдә, дини хөкемнәрне теге яки бу сәяси доктрина файдасына үзгәртмичә генә укытуда. Мондый ислам Россия гадәт-йолаларын һәм кануннарын бозмый. Әлеге фәннәрне өйрәнү суфыйчылыкка да юл ача.

ДӨНЬЯДАН ВАЗ КИЧҮ ТАЛӘП ИТЕЛМИ

– Суфый – үзен тулысынча исламга багышлаган, аның барлык таләпләрен үтәүче, шикле эшгамәлләрдән сакланучы, җәмгыять һәм якыннары өчен файдалы кеше. Бу халәткә ирешү өчен дөньядан ваз кичү таләп ителми. Беркөнне мин дә шул дәрәҗәгә якынаермын дип өметләнәм, – дип аңлата **Хусейн Теркакиев,** Ингушетиядән килгән магистрант. Хусейнның бабасы дин гыйлемен өйрәнгән. Хусейн үзе дин белемен Ингушетиядә алган. Аның өчен академия – исламны фәнни өйрәнү юлында чираттагы адым.

Безнең бөтен әңгәмәбез Ислам мирасы үзәгендә уза. Күпмедер дәрәҗәдә бу – академия эчендәге музей. Биредә Мәрҗани, Насыйри, Фәхретдиннең фәнни хезмәтләре, дини эчтәлекле антиквар басмалар, 1910 нчы елларда Казан губернасында нәшер ителгән гарәпчә газеталар, календарьлар һәм брошюралар саклана. Хусейнның артында – XIV гасырда болгар язучысы Мәхмүд Әл-Болгари ибне Гали портреты тора, аның «Нәһҗел-фәрадис» («Җәннәт бакчаларына ачык юл») әсәре татар прозасының башлангыч ноктасы санала.



– Мин гомеремне ингуш мәгърифәтчеләре һәм дин әһелләре мирасын өйрәнүгә багышларга телим. Аларның хезмәтләре аз өйрәнелгән, әмма бу хезмәтләр безгә тарихыбызны, гореф-гадәтләребезне аңлау өчен күп мәгълүмат бирә алыр иде. Рухи камиллеккә омтылучы кеше буларак, мин мондый эшне үз бурычым дип саныйм, – ди Хусейн.

КАЙТУМЫ ӘЛЛӘ ЭЗЛӘНҮМЕ?

Экскурсиябез зур конференц-залда тәмамлана. Ярусլар рәт-рәт булып тезелеп киткән, диварлар нәфис гарәп язулары белән бизәлгән, декор эченә яшеренгән лампалардан яктылык төшә. Әйтерсең, без ниндидер борынгы җыенда тамашачыларны һәм ораторны көтеп утырабыз, һәм хәзер менә ул аларга ачы хакыйкатьне ачып бирәчәк.

– Йөз ел элек Россия мөселманнары яхшы өйрәнелгән, безнең төбәккә, менталитетка яраклаштырылган ислам динен тота. Төп дини хөкемнәргә бәйле карашлар, традицияләр формалаша. Әлеге белемнәр базасы гасырлар буена туплана килә. Әмма совет чорында ул тулысынча югала. Без үз мирасыбыз, ата-бабаларыбызның фикер сөреше белән элемтәне югалттык, – дип сөйли академиянең фән буенча идарәсе башлыгы **Руслан Сәяхов.** – 1990 нчы елларда ислам белән кызыксыну янә арта башлады. Әмма безнең төбәктән Шәрык илләренә укырга китүчеләр туган якларына еш кына гореф-гадәтләребезгә ят догмалар алып кайтты. 2000 нче елларда без әнә шундый тискәре тәҗрибәнең корбанына әвереелдек. Хәзер без рухи мирасыбызны, ислам мәгарифе системасын, дини грамоталылык һәм рухиятне актив торгызу һәм кайтару юлында. Алдыбызда ике юл бар: кайбер җитешсезлекләре булган иске традицияләрне кабул итү яисә гыйлем һәм рухият нигезләрен хәзерге заман таләпләреннән чыгып эзләү һәм яңадан кору. Тик, ни генә булса да, без барыбер үз рухи системабызга, үз фикерләү рәвешебезгә әйләнеп кайтачакбыз. Әйе, бүген яңа таләпләр турында күп сөйләнә. Тик алар шулкадәр яңа микән соң?



Ясно каждому из нас, что разрушить этот духовный алтарь нелегко и сделать это можно не так скоро. Его не разрушить одними красивыми речами с трибуны. Нам, коммунистам, работающим среди пролетариев освобожденного Востока, необходимо обратить самое серьезное внимание на этот больной вопрос и приложить все свои силы, чтобы провести это дело умело, аккуратно, без лишних трений.

ЭЛИТА КАТЛАМ ТӘРБИЯЛӘҮ

Россиядә ислам дине өлкәсендә бердәнбер югары уку йорты булган академиянең үсеш векторы инде анык билгеләнгән.

– Безнең миссиябез – илебезнең борын-борыннан килгән дини мирасын белгән, әйдәп баручы дини-хокукый мөселман мәктәпләре һәм агымнары, дөньяви фәннәр турында белемнәргә ия булган профессиональ мөселман дин әһелләрен һәм галимнәрен әзерләү. Аларның колачлы бурычы – Россия Федерациясенең фикер-карашларын халыкара аренада белдерү, мөселман дөньясында илебез мәнфәгатьләрен яклау, радикаль дини карашларның таралуына каршы тору, – дип сөйли Болгар академиясе ректоры **Данияр Абдрахманов.**

Академиядә мөселман җәмгагатьчелеге үсеше проблемалары, шул исәптән экстремистлык күренешләрен булдырмый калу мәсьәләсе белән бәйле фәтвалар әзерләячәк киңәшмә органы –Голәмалар шурасы оештырыла. Дин әһелләрен һәм мөселман уку йортлары мөгаллимнәрен аттестацияләү үзәге киләчәктә белем һәм һөнәри осталык дәрәҗәсен бәяләү, дини-идеологик карашларны билгеләү органы булачак. Ислам мирасын өйрәнү үзәге Россия мөселман халыкларының язма һәм басма мирасының борынгы үрнәкләрен ачыклау, җыю, тасвирлау һәм фәнни әйләнешкә кертү белән шөгыльләнә.

– Без дөньяның 12 алдынгы ислам оешмасы һәм югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итәбез. Былтыр академиябездә яклангaн ислам фәннәре докторы дипломы, элек Советлар Союзына кергән республикалар территориясендә югары ислам белеме бирү системасы сакланып калган бердәнбер ил – Үзбәкстан Республикасының югары аттестация комиссиясе тарафыннан танылды, – дип дәвам итә Данияр Абдрахманов. – Без мөселман белем бирү системабызны формалаштырабыз, мөселман дин әһелләренең үзаңын арттырабыз һәм мөселман элитасын булдыру хыялыбызга якынаябыз, дип ышанабыз.

Областной Комитет Р. К. П. (б)
Татреспублики.

СПУТНИК АГИТАТОРА

Выходит 2 раза в месяц.

№ 1.

КАЗАНЬ

15 сентября 1921 15 сентября

1921 «СПУТНИК АГИТАТОРА» ЖУРНАЛЫ

1921 елның сентябрендә «Вестник Татарского областного комитета РКП (б)» беренче тапкыр үзенең исемен җыйнаграк атамага – «Спутник агитатора»га алыштыра.

Ул яңа икътисадый сәясәт мәсьәләләрен, НЭПның төп бурычларын яктырта. «В партколлегии КПК» рубрикасы аеруча популяр була. Журнал 1921 елда укучыларга кадрларны «чистарту» белән бәйле коры саннар бастырып килә: «Партиядән чыгарылдылар: С.Д. Суслов, татар-башкорт мәктәбенең география укытучысы, – Колчак һәм Аненков контрразведкасының элеккеге тикшерүчесе Доболасов белән элемтәсе өчен; Б.Н. Питковская – троцкийчы Крамов белән элемтә өчен; авыл хуҗалыгы институты директоры А.И.Волосов – кондратьевчылар һәм чаянчылар белән дус булган өчен...» Әлеге коры исемлеккә йөзләгән татарстанлының аяныч язмышы яшеренгән. Журналның мондый саннары һәрвакыт аеруча кызыксыну уята: кешеләр репрессияләнгән туганнары турында мәгълүмат эзли.

«Спутник агитатора» исеме белән журналның дүрт саны чыгып кала.

Областной Комитет Р. К. П. (б)
Татреспублики.

СПУТНИК АГИТАТОРА

Выходит 2 раза в месяц.

№ 1.

В печать
Карпов

КАЗАНЬ

15 сентября 1921 15 сентября

Һәр санга яңа «сан буенча дежур» күзәтчелек иткән һәм бастырырга кул куйган: Татар өлкә комитетының беренче секретаре Карпов, агитпропаганда бүлеге мөдире Капралов, Главполитпросвет рәисе Манаев... 1921 елның ноябрендә журналны чыгару эшенә Гасыйм Мансуров кушыла.

Переселение,
как средство от голода.

За все время существования Русской земли до сих пор еще не было года, когда бы русский народ куда бы нибудь да не переселялся...

Переселялся он сначала от печенегов, татар, от литвы и от польских нашествий, от притеснений князей, воевод и помещиков, от прикрепления к земле, от гонений на старую веру, от рекрутчины, от налогов, от податей и повинностей. Потом после „освобождения" крестьян бежал он от круговой поруки и выкупных платежей;

ШӘҺӘРДӘ – ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘР

1921 елда «Спутник агитатора» исеме астында басыла башлаган журналыбызда шул чорга хас проблемалар яктыртыла. Шуларның берсе – халыкларның чит җирләргә күпләп күченеп китүе. Иң аяныч сәбәпләрнең берсе – Идел буенда корылык нәтиҗәсендә башлаган ачлык. Кешеләр, ачлыктан качып, Татреспубликадан читкә агыла. 400 меңгә якын – кайбер тарихчылар фикеренчә, 1920 нче елларда Татреспублика халкы шулкадәргә кимегән. Хәзерге вакытта исә киресенчә күпләр Татарстанны яшәү урыны итеп сайлый. Язмабыз шул хакта.

...Статистика белән бәхәсләшеп булмый – ул барысын да белә. Мәсәлән, Идел буенда урнашкан миллион кешелек шәһәрләрдән бары тик берсендә генә халык саны артуы билгеле. Һәм бу шәһәр – Казан. Татарстан башкаласына яшәргә, эшләргә, иҗат итәргә дип киләләр. Бирегә күрше төбәкләрдән һәм Россиянең ерак шәһәр-бистәләреннән күченәләр. Сәбәпләрен белү өчен, күченүчеләрнең үзләре белән аралашырга булдык.

Фото: Александр Ефремов; Иннополис Университеты сайтыннан алынды

«БЕЗГӘ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮНЕ ЫШАНЫП ТАПШЫРАЛАР»

Надежда Снигирева, архитектор, «Проектная группа 8» партнеры, катнаш проектлаштыру белгече:

– Мин Вологдада туып-үстем, архитектор белгечлеге алдым. Аннары дусларым белән үз командабызны булдырдык һәм территорияләрне үстерү проектлары белән шөгыльләнә башладык. Иҗтимагый киңлекләрне үстерәбез, катнаш проектлаштыру – гражданнарны да җәлеп итү аша шәһәр мохитен үзгәртәбез.

Беренче мәртәбә Казанга 2015 елда килдем – безнең команда «Рождественка» бюросы белән консорциумда Кабан күлләре системасы яр буйларын үстерү концепциясе конкурсында катнашты. Конкурста без җиңмәдек, шулай да мин үзем өчен Татарстанда иҗтимагый киңлекләр белән системалы эшкә ихтыяҗ булуын ачыкладым. 2016 ел башында катнаш проектлаштыру буенча чакырылган белгечләр сыйфатында безгә Әлмәттәге чараның модераторы булырга туры килде – мин шунда Татарстан Президенты ярдәмчесе Наталия Фишман-Бекмамбетова белән таныштым. Әлеге чарадан соң без Иҗтимагый киңлекләрне үстерү һәм анда җәмәгатьчелек катнашы системасын булдыру программасы белән Татарстанга эшкә чакырылдык. Ул чакта бу хыялдагы бурыч иде, һәм Казанда моңа ихтыяҗ булу калган бөтен Россиядән бик нык аерыла иде. Безнең мәнфәгатьләребез тәңгәл килде. Һәм без 2016 елда Казанга күчеп килдек, биредә һәм республиканың төрле районнарында эшли башладык. Казанда без Горки-Өмәт урманы, «Комсомолец» паркы кебек проектларда җәмәгатьчелек катнашын оештыру өчен җаваплы идек. Инде халыкны җәлеп итү буенча белгечләр сыйфатында гына түгел, архитекторлар буларак та «Ак чәчәкләр» бульвары проектын эшләдек. Көн саен йөзләрчә һәм меңнәрчә кеше файдаланган территорияләрне үстерүне безгә ышанып тапшырулары бик сөендерә!

Безнең команда өчен, беренче чиратта шәхси үсеш мөмкинлеген табу мөһим. Бүген без бөтен ил буйлап эшлибез, дип әйтеп була, әмма һаман Казанда яшибез, чөнки бу бик уңайлы шәһәр. Минем өчен төп критерий – иҗтимагый киңлекләр белән эшләү, икенче урында исә – тормыш сыйфаты һәм бәяләр нисбәте. Биредә искиткеч логистика, бик матур үзәк, тарихи объектлар. Шаккаткыч урыннар бар, сәламәтлекне ныгыту өчен мөмкинлекләр зур, театрлар күп.

Мәскәү белән чагыштырганда, монда бәяләр андагыдай югары түгел, шулкадәр үк акчага биредә күпкә сыйфатлырак продукт сатып алып була. Әмма Казанны башка бер генә шәһәр белән дә чагыштырасы килми. Биредә кешеләрнең калага мөнәсәбәте үзгә. Казанлылар үз шәһәрләре, үз мәдәниятләре, үсеш өчен ихластан борчыла. Һәм моның шулай булуы бик яхшы да! Бу үзең яшәгән шәһәр өчен нәрсә дә булса эшләү мөмкинлеге бирә.

Татарстанда иҗтимагый киңлекләрне үстерү программасы 2015 елдан бирле гамәлгә кертелә. Бу вакыт эчендә республика районнарында 400ләп парк, сквер, яр буе һәм бульвар төзекләндерелгән. Җирле халык бу эштә бик актив катнаша. Алар, әле проектлар эшләнә башлаганчы ук, проектлаштыру биремен формалаштыруда да, территорияләрне үстерүгә караган эскиз проектлары һәм концепцияләре буенча оештырылган җәмәгать тыңлауларында да катнаша. Программа гамәлгә кертелгән дәвердә иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү проектларына 500 тапкырдан артыграк тикшерү уздырылган, шулардан 98е 2020 елда online үткәрелгән.

Республикада тәкъдим ителгән ишегалларын, паркларны, яр буйларын, мәйданнарны, урамнарны төзекләндерү проектларын раслаганда катнаш проектлаштыру принциплары илебездәге «Уңайлы шәһәр мохитен һәм ТКХ формалаштыру» өстенлекле проекты кысаларында төзекләндерү проектларын гамәлгә кертүче 12 мең муниципалитет өчен мәҗбүригә әйләнгән.

2018 елдан алып, Татарстан Кече шәһәрләрдә һәм тарихи җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохитен тудыру буенча иң яхшы проектларның бөтенроссия конкурсында ел саен катнаша. Аны уздыру дәверендә Татарстаннан барлыгы 26 объект җиңгән. 2018 елдан бирле, Татарстан командасы откан грантларның гомуми күләме 1 миллиард 635 миллион сум тәшкил итә.

«КАЗАН – МӨМКИНЛЕКЛӘР КАЛАСЫ»

Евгения Косецкая, бадминтон буенча алты тапкыр Россия чемпионы:

– Минем Казан белән танышуым 2013 елда, бирегә коммерция турнирына килгән чактан башланды. Шул вакытта тренерым Игорь Назаровка Казанга күчәргә тәкъдим иттеләр. Нәтиҗәдә 2014 елның кышында без бирегә күчендек, башта – Теннис академиясендә, аннары илдә беренче булып төзелгән Бадминтон үзәгендә шөгыльләндек. Идел буе спорт һәм туризм академиясенең өченче курсында укуымны дәвам иттем.

Бу вакытта безнең тренерыбыз белән бергә Казанга күчеп килгән башка егет-кызлар белән Универсиада авылында яшәдек, Бадминтон үзәгендә шөгыльләндек. Ярышка кайдан акча алырга, воланнарыбыз бармы, кайсы вакытта күнекмәләр ясарга кебек сораулар беркайчан да тумады. Кыскасы, Казан бөтен мөмкинлекләрне һәм шартларны тудырды. Бездән бер генә нәрсә таләп ителде – шөгыльләнергә, ничек тә җиңү яуларга. Ә инде үзеңнең тылың нык булуын беләсең икән, бары тик яраткан эшең белән күңел биреп шөгыльләнәсе генә кала, һәм бу җиңүгә ышаныч уята.

Казанда балалар спортының да нык үсештә булуы куанычлы. Биредә балалар өчен мөмкинлекләр бик күп. Спорт юлын башлаганда бу бик мөһим. Бөтен ата-ана да баласы өчен инвентарь юнәтә, юл чыгымнарын түли алмый бит, гәрчә ул талантлы һәм перспективалы булса да.

Мин гомумән Казанны яратам. Беренчедән, шәһәр бик чиста, икенчедән, ул гел үсештә. Бөтен нәрсә күзгә күренеп үсә: яңа йортлар, районнар, спорт үзәкләре. Шәһәр гел үзгәрә, мин аның урамнарында йөрергә бик яратам. Үзем өчен бик күп яңа урын ачам. Әмма әле бер тапкыр да Кол Шәриф мәчетендә булганым юк, ә анда бик матур, диләр.

Татарстанның спорт инфраструктурасы:

⟶ **46** стадион

⟶ **235** өсте ябулы бассейн

⟶ **992** универсаль спорт мәйданчыгы

⟶ **624** сезонлы шугалак

⟶ **45** боз аренасы



Нечего подобного не знают заграничные страны, где не так удобны естественные пути сообщения и не так однородна поверхность и климат, где давным давно каждое племя обособилось в определенных границах, где неизмеримо высоко, по сравнению с нашей,



Эта неучитываемая многими разница дает до сих пор основание считать, будто наше население по природе „бродячее". Между тем, дело здесь не во вкусах, а в исторически сложившихся особенностях нашей политической и хозяйственной жизни, заставлявших несчастных переселенцев, „промыслом звериным питаясь, зверски в отчаянии жить" (утверждению одного из актов XVII века)...

«МӨГАЛЛИМГӘ ИРЕКЛЕ БУЛУ МӨҺИМ»

Евгений Зуев, Иннополис университеты укытучысы:

– Мин Мәскәүдән килдем. Берничә ел МДУда эшләдем, аннары Цюрихка чакыру алдым да шунда укытырга киттем, хәзер Россиягә кайттым. Әледән-әле берничә көнгә Татарстанга килеп, Иннополиста лекцияләр укый һәм кабат Мәскәүгә кайтып китә идем. Берничә елдан соң бирегә даими эшкә чакыру алдым һәм Иннополис профессорына әйләндем.

Барысы да шактый гади. Университет мөгаллиме өчен конкрет географик урын сайлау әлләни әһәмияткә ия түгел. Университетның яхшы булуы, укытучыга үзе теләгән тикшеренүләр белән шөгыльләнү мөмкинлеге биреләме-юкмы – шунысы мөһимрәк. Үзенә күрә ирекле булу инде. Иннополиста чакырылган профессор булып эшләгәннән соң, мин бик күп параметрлар буенча Казанның Мәскәүдән бер дә калышмавын аңладым. Шунлыктан бу минем өчен ниндидер радикаль карар булмады. Казан миңа бик ошый. Бик матур шәһәр ул.

Нәкъ менә Иннополиска күченү турында сөйләгәндә, беренчедән, биредә яңа университет, мин анда үземә кызыклы булган темалар белән шөгыльләнә алам. Мин тәкъдим иткән барлык курсларны кызыксыну һәм хәтта рәхмәт хисе белән хупладылар.

МДУ студентларын һәм Иннополис студентларын чагыштырсак, һичшиксез, соңгылары күпкә активрак, әзерлеклерәк, мотивацияләре көчлерәк. Гәрчә мин МДУда күптән эшләмәсәм дә һәм минем тоемлавым бераз искергән булса да, чынбарлыкта бу шулай. Ихтимал, әлеге мотивация киләчәктә үз белгечлегең буенча эшләү мөмкинлеге булуга бәйледер. Һәм үземнең шәкертләрем мисалында мин аларның барысының да диярлек Татарстанда калуын беләм. Берничәсе генә китте.

Иннополиста мин ничек яшимме? Теләсә кайсы яшь территориаль берәмлектә проблемалар була инде ул. Әмма бит болар әлләни мөһим дә түгел. Казанда яшәргә дә була, шуңа карамастан, миңа биредә тору күпкә уңайлырак. Һәм мин биредә яшәвемә бик канәгать. Үземнең эшемнән дә бик канәгать. Кемгәдер әйттем дә бугай әле, минем урыным монда ахры, биредә калырмын да, дип. Мин бу урынны сайлавыма бик шат.

200дән артык

Татарстан студенты, педагогы һәм фәнни хезмәткәре ел саен грант ярдәме ала

62

Татарстанда 10 ел эчендә 28 495 урынлы шулкадәр мәктәп төзелгән

229 292

Татарстанда шулкадәр бала өстәмә белем ала

1198

2012 елдан башлап шулкадәр мәгариф объекты капиталь ремонтланган

«ЦИФРЛАР» ӨЧЕН КИҢ КЫР

Виктор Щепинов, ТР Цифрлы трансформация үзәгенең социаль тармакны цифрлы үстерү бүлеге проектлары җитәкчесе:

– Мин Севастопольдән күченеп килдем. Әле менә ноябрь башында гына. МДУ тәмамладым. IT-тармагында күптәннән инде, Мәскәүдә дә, Санкт-Петербургта да эшләргә өлгердем. Үз һөнәрем буенча эшләгәндә, тәүге тапкыр Казанга 2011 елда килгән идем. Ул вакытта IT-паркта булдым, андагы кешеләр белән аралаштым һәм шул чакта ук, биредә эшләсәң һәм яшәсәң иде ул, дигән уй чалынып киткән иде башымда. Һәм шул вакыттан бирле әлеге фикер тынгылык бирмәде. Минем нәкъ менә дәүләтне автоматлаштыру эше белән ныгытып шөгыльләнәсем килә иде. Һәм Казанда эш тәкъдим ителгәч, рәхәтләнеп ризалаштым. Нинди дер көнкүреш вак-төяге турында ул чакта уйлап та тормадым, әмма, яшәргә урын эзли башлагач, биредә сыйфатлы торакның шактый күп булуын ачыкладым. Бу да күңелгә ятышлы сюрприз иде.

Үзеңне белгеч буларак сынауга килгәндә, биредә мөмкинлекләр бик күп. ТР Цифрлы үсеш министрлыгының шундый химаясе булганда, эшчәнлек алып бару җиңел. Прогресс бер урында гына тормый бит, дөнья үзгәрә, технологияләр үсә. Миңа иң ошаганы – биредә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталының бик нык алга китүе. Коммуналь түләүләрдән алып социаль ипотекага кадәр бик күп хезмәт күрсәтүне эченә алган шундый куәтле портал булу – төбәкләрдә сирәк очрый торган күренеш. Бу мине барыннан да күбрәк гаҗәпләндерде.

Тик безнең тормыш эштән генә тормый, ял, хобби, һәм гомумән көнкүреш тә бар бит әле. Казан миңа бер күрүгә үк ошады. Мин аның урамнарында җәяү йөрергә яратам. Биредәге ризыклар да бик ошый. Республиканың үзендә җитештерелгән продуктларның күп булуы да сөендерә.

Татарстан Республикасы цифрлы үсешнең гомуми дәрәҗәсе буенча һәрвакыт илдә алдынгы төбәкләрдән санала. Мәскәүнең «Сколково» бизнес-мәктәбе экспертлары эшләгән «Цифрлы Россия» индексыннан күренгәнчә, былтыр Татарстан, Мәскәүдән генә калышып, цифрлаштыру дәрәҗәсе буенча икенче урынга чыккан.

Республикада IT-тармакның төбәк тулай продуктына өлеше якынча 2,4% тәшкил итә, тулаем Россия буенча исә әлеге күрсәткеч 1% кына. Бүген Татарстан чыбыклы Интернет челтәренә кушылган абонентлар саны буенча (1 миллионнан артык абонент) Идел буе федераль округында лидер булып кала.

Татарстан «Цифрлы икътисад» илкүләм программасында актив катнаша, дөньякүләм масштабтагы IT-үзәкләр төзи, республикада цифрлы кадрларның нык лы әзерлеге һәм IT-компанияләр үсеше өчен шартлар тудыра...

Республиканың IT-сегментында барлыгы 3 меңгә якын компания исәпләнә, алар 43 меңгә якын эш урыны белән тәэмин итә. Республикада югары технологияле проектларны гамәлгә кертү өчен бөтен шартлар тудырылган. Инде 10 ел буе IT-парк уңышлы эшли, Россиядә беренче IT-шәһәр – Иннополис төзелгән. Югары уку йортлары һәм колледжлар ел саен 3 меңнән артык IT-белгеч әзерли.

1921
«КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ» ЖУРНАЛЫ

Дүрт номердан соң... янә журналның исемен үзгәртәләр. 1921 елның ноябреннән «Коммунистический путь» – РКП (б) Өлкә комитетының һәм Татреспублика Баш сәяси-агарту идарәсенең басма органы чыгарыла башлый. Барлыгы 26 номер дөнья күрә, тираж төрле елларда 1200дән 2000 данәгә кадәр үзгәреп тора. Марксизм һәм ленинизм, партия эшчәнлегеннән тыш, журнал көнүзәк иҗтимагый мәсьәләләрне күтәрә: дингә каршы көрәш, яшүсмерләр һәм хатын-кызларның революцион хәрәкәте, профсоюзлар эше, Бөтенроссия ҮБК закон проектлары, районнар тормышы, партия укулары, пролетариат мәдәнияте, яңа суд сәясәте, иминият системасын үстерү, коммунистик этика, милли мәсьәләләр, әдәби очерклар, тәнкыйть, геосәяси күзәтүләр... 1922 елда журналда беренче мәртәбә реклама пәйда була. 1923 елда журналга беренче тапкыр түләүле язылу системасы кертелә: 1 айга – 6 сум.

МӨХӘРРИРЛӘР

Гасыйм Мансуров

«Коммунистический путь» журналы белән җитәкчелек итәргә тарихчы, педагог, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Гасыйм Мансуров билгеләнә. Төркестан АССРда җинаять эшләрен тикшерү башлыгы, НКВД Коллегиясе әгъзасы булып эшләгән 27 яшьлек Мансуровны ТАССР ХКС рәисе урынбасары итеп куялар, өстәвенә, аңа «Коммунистический путь» журналы да йөкләнә.

Яшь совет республикасы журналистларга бай түгел, шуңа күрә бу профессия өчен иң яхшы кадрлар булып укытучылар санала: дөрес итеп яза да беләләр, кирәк булса, дөрес итеп өйрәтәчәкләр дә.

Гасыйм Мансуров журналда 1924 елга кадәр эшли. Аннары Мәскәүгә – Коммунистик университет студентларын, Мәскәү университетында Шәрык хезмәт ияләрен укытырга китә, соңыннан Шәрык этник мәдәниятләре институты проректоры була.

1929 ел ахырында аны «партиягә каршы төркемдә торуда, пантөркилек хәрәкәте, Кырымның «Милли фирка» оешмасы белән бәйләнешләр»дә гаеплиләр. Бер ел буе ул хөкем карарын көтә. 6 айны үлемгә хөкем ителгәннәр камерасында үткәргәннән соң, атып үтерү җәзасын төзәтү-хезмәт лагере белән алыштыралар.

1941 елда азат итәләр. Бөек Ватан сугышын Мансуров башыннан ахырына кадәр санитар поездында санитар буларак үткәрә.

Үлем җәзасы турындагы карар Соловкидагы 10 еллык төзәтү-хезмәт лагерена алыштырыла. 1990 елда (үлеменнән соң) аклана.

Михаил Корбут

«Коммунистический путь» журналының өченче җаваплы (баш) мөхәррире Казандагы Совет хокукы һәм совет дәүләте институты профессоры, фикер сөрешен инкыйлаб җилләре үстергән профессиональ марксист-тарихчы Михаил Корбут була.

Корбут – Россиядәге революция хәрәкәте тарихы, Россиянең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына караган законнар тарихы, Казан университеты тарихы буенча 120дән артык фәнни хезмәт авторы. Аның төп казанышларыннан берсе – 1919–1926 елларда Казан университетының рабфагын оештыру. Корбут «рабфак эше» концепциясен эшли – «элеккеге югары мәктәпне юкка чыгармаска, ә бәлки аның бөтен күзәнәкләренә үтеп кереп, югары мәктәпнең төп хезмәткәрләрен үз ягыбызга җәлеп итеп эшләргә». Аның абруе зур була – 1924 елның гыйнварында дөнья пролетариаты юлбашчысы белән хушлашу мәрәсименә Казан университетыннан бертавыштан ул җибәрелә. 1921–1925 елларда марксизм-ленинизмны пропагандалау белән шөгыльләнә, әлеге идеяләргә ихлас күңелдән ышана – журналның нигезен нәкъ менә шулар тәшкил итә дә инде.

1927 елда «кызыл профессор»ны «троцкийчыл оппозиция»дә катнашучы буларак партиядән чыгаралар. 1933 елда өч елга Казахстанга сөрергә карар итәләр. 1936 елда – советларга каршы агитациядә гаепләнә – тагын өч елга Казахстанга сөрелә. 1936 елның июнендә Корбутны 5 елга төрмәгә утырталар.

**1937 елның августында 38 яшендә атып үтерелә.
1956 елда (үлеменнән соң) аклана.**



Автор: Нияз Әхмәдуллин

КЕРЕМЛЕ ЭШ

Чираттагы мәртәбә үз исемен алыштырган журналыбызда авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. «Коммунистический путь» журналында авыл җирендә алып барылырга тиешле эшләргә багышланган мәкаләләр күпләп дөнья күрә. Бүген дә «Татарстан» журналы, үз кыйбласына тугры калып, авыл кешеләренең тормышы-көнкүреше турында сөйли...

Бөлгенлеккә төшүнең әллә ничә ысулы бар, әмма иң ышанычлысы авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү. Эшкуарлар арасында инде берничә дистә ел шундый мәзәк йөри. Авыл хуҗалыгы эшкуарының юлында очраган барлык җитди киртәләрне, авырлыкларны исәпкә алганда, әлеге сүзләр һәрвакытта да мәзәк кенә булып калмый. Хәер, дәүләт ярдәм кулын сузганда бу кыенлыклар бермә-бер кими. Татарстан тәҗрибәсе тәвәккәллек сорый торган эшне ничек керемлегә әйләндерү үрнәге булып тора.

Фото: Солтан Исхаков



ЗАДАЧИ КОМИССИИ ПО РАБОТЕ В ДЕРЕВНЕ при Татобкоме РКП (б).

В постановлениях XIII с'езда партии по работе в деревне имеется следующий пункт. „Для дальнейшего изучения опыта работы партии в деревне, для разработки руководящих указаний в этой области и проверки выполнения намеченной с'ездом работы — создать комиссии по работе в деревне при Ц. К. и при Областных Бюро“. Необходимо сознаться, что эта директива проводилась очень слабо, в Татреспублике были только слабые попытки ее осуществления. Между тем вопрос о работе в деревне в настоящее время приобрел первостепенное политическое значение.

ЧИКЛӘРНЕ ҖИМЕРЕП

Бүген Татарстан – авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәре буенча Россиядә лидерлар арасында. Россия авыл хуҗалыгы җирләренең 2,2% ын биләп, республика ил күләмендәге тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең 4,2%ын җитештерә. Татарстан – сөт җитештерү буенча танылган лидер (Россиядә җитештерелгән сөтнең 6%ы). Без бөртеклеләрне, терлекчелек продукциясен җитештерү күләме буенча да лидерлар арасына керәбез, сөт, ит, йомырка, ипи белән үзебезне – 100%ка, шикәр комы белән – өч тапкырдан артыкка, үсемлек мае белән алты тапкырдан артыкка тәэмин итәбез.

Мондый нәтиҗәләрнең нигезендә озак еллар дәвамында авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ярдәм программалары аша күрсәтелгән булышлык ята. Күп кенә төбәкләрдә агробизнеска ярдәм итү турында уйлап та карамаганда, республикада күп кенә ярдәм формалары, инде сыналып, үз җимешләрен бирә башлады.

Республика җитәкчелеге авылның социаль һәм икътисадый инфраструктурасын үстерү белән системалы рәвештә шөгыльләнә. Юллар төзекләндерелә һәм яңалары салына: авыл торак пунктлары юллар белән тоташа (соңгы ун ел эчендә авыллар арасында салынган юлларның гомуми озынлыгы 1150 километрга якын), фермер хуҗалыкларына һәм терлекчелек комплексларына килеп җиту өчен каты өслекле һәм вак таш түшәлгән юллар төзелә. План буенча модульле фельдшер-акушерлык пунктлары (8 ел эчендә 500дән артык ФАП) һәм ветеринария пунктлары (550дән артык) корыла. Әлеге программаларны бүген федерациянең башка субъектларында да үрнәк итеп алалар. Район үзәкләрендә җәмәгать киңлекләре пәйда була, ареналар һәм бассейннар ачыла. Торак төзү программасы актив рәвештә гамәлгә ашырыла. Быелдан башлап, «авыл ипотекасы» программасы буенча 3%лы кредит алырга мөмкин.

Татарстанда бүген авыл җирендә 900 меңнән бераз гына артык кеше яши. Соңгы 20 ел эчендә авыл районнарында халык саны 100 мең кешегә кыскарды, өстәвенә, нигездә шәһәргә агылучы яшьләр хисабына. Шуңа күрә программаларның төп бурычы – тормыш өчен уңайлылыклар тудыру, яшьләр авылда төпләнсен, туган җирләрендә эшләсен һәм яшәсен өчен, аларда кызыксыну уяту. Советлар чоры сүзләре белән әйткәндә, шәһәр белән авыл арасындагы чикләрне бетерү. Бу бүгенге көндәге өстенлекле эш юнәлеше, аның нәтиҗәләре шәйләнә дә кебек.

Бу эшләрдә максатчан социаль программалар да уңай роль уйный. Мәсәлән, авыл җирлегендә гомер итүче, яше 25кә кадәр булган хатын-кызга беренче баласы туганда – 50 мең сум, яше 29га кадәр булган хатын-кызга өченче һәм тагын да күбрәк баласы туганда 100 мең сум акча түләнә. Аграр вузларда укучы студентлар өчен махсус стипендияләр (10 мең сумга кадәр) каралган, авылга эшкә кайтканда – 300 мең сум, хезмәт юлының беренче елында өстәмә 7,5 мең сум акча бирелә. Яшь белгечләр өчен торак төзелеше программасы гамәлгә ашырыла. Югарыда санап үтелгәннәр – саллы ярдәм, тик бу да әле программалар комплексының бер өлеше генә.

«КЕЧЕ ФОРМА»ЛАРНЫҢ ЗУР НӘТИҖӘЛӘРЕ

Программаларның мөһим өлеше – аграр сферада гамәлдә булган бизнесны киңәйтергә яисә стартаплар ясарга, хуҗалыкны алып барырга ярдәм итә торган икътисадый шартлар тудыру. Бүген республикада аграр комплексның гомуми күләмендә хуҗалык итүнең кече формалары субъектларының (аларга шәхси ярдәмчел хуҗалык (ШЯХ), крестьян-фермер хуҗалыклары (КФХ), гаилә фермалары, авыл хуҗалыгы кооперативлары керә) өлеше 50%тан артып китә. Димәк, кече формалар югары технологияле эре агрохолдинглар белән көндәшлек итәргә сәләтле.

Хәзерге вакытта Татарстанда 450 меңнән артык шәхси, 4 меңгә якын фермер хуҗалыгы һәм 300дән артык авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативы эшли. Югарыда аталган барлык бу категорияләр өчен махсус әзерләнгән программалар эшли. Мисалга, ШЯХ өчен шәхси утарларда терлек, беренче чиратта, савым сыерларын тотар өчен субсидияләр бүлеп бирелә. Республика җитәкчелеге, ШЯХларны авылда яшәү рәвешен саклауның, гаилә бюджетлары керемен арттыруның бер шарты буларак карап, аларга эзлекле рәвештә ярдәм күрсәтә. ШЯХларга субсидия бирү белән бергә, мини-фермалар төзелеше программасы гамәлгә ашырыла. 2015–2019 елларда дәүләт ярдәмендә 2134 мини-ферма

салынган, болар өчен республика бюджетыннан ярты миллиард сумнан артык акча бүленгән, нәтиҗәдә программада катнашучыларда сыерларның баш саны 5000гә арткан.

КФХ ярдәм программасы кысаларында соңгы тугыз ел эчендә 1400 крестьян-фермер хуҗалыгы якынча 3,6 млрд сумлык ярдәм алган. Быел гына да 152 КФХна грантлар аркылы 900 млн сумлык ярдәм күрсәтелгән. Статистикага караганда, һәрбер шундый хуҗалыкта, кимендә, 3–4 кеше хезмәт куя. Нәтиҗәдә 500 яңа эш урыны ачылыр, дип көтелә, ә бу хезмәт хаклары, җирле бюджетларга керә торган салымнарның артуы дигән сүз.

Быел коронавирус пандемиясе китереп тудырган икътисадый проблемаларга да карамастан, авылга финанс булышлыгы күрсәтү күләме кимемәде. ТР вице-премьеры, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровның сүзләренә караганда, республиканың аграр секторын үстерүгә 2020 елда 14 млрд сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Шуның 9 млрд сумга якыны – республика акчалары, 5 млрд сумы – федераль бюджеттан.

Әлеге акчалардан ел саен 2 млрд сумнан артыграгы нәкъ менә хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүгә юнәлдерелә. Мәсәлән, узган 2019 елда хуҗалыкларның исәп-хисап счетларына 2,5 млрд сум акча күчерелгән. Быел гаилә фермаларын (әлеге максатларга 350 млн сум каралган), эш башлаучы фермерларга (250 млн сум), кооперативларга (300 млн сум) үсеш программалары буенча грант ярдәме күләмнәре һәм шартлары сакланып калган.

Фотолар ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды, Рифкать Билданов

МИЛЛИ ПРОЕКТКА – ЧИРАТ

Узган елдан башлап, Татарстан үз эченә «Агростартап» грантын алган «Фермерларга ярдәм күрсәтү һәм авыл кооперациясен үстерү системаларын төзү» федераль милли проектны тормышка ашыруда актив катнаша. Аның шартлары шактый кызыктыргыч. Эш башлаучы фермерга эшенә үз акчасын 10% күләмендә салу таләп ителә. Әгәр грант суммасы 2 млн сумнан артып китми икән, җиңүче, кимендә, бер яңа эш урыны булдыру йөкләмәсен ала, әгәр ярдәм күләме әлеге суммадан артып китә икән, хуҗалыкта, кимендә, ике хезмәткәр эш урыны белән тәэмин ителергә тиеш.

Эшкуар грантны бары тик бер генә мәртәбә алырга хокуклы. Дәүләт биргән акчаларны җир участогын сатып алуга, җитештерү биналарын төзү яисә реконструкцияләү өчен проект документацияләрен эшләүгә, склад яисә җитештерү биналарын сатып алуга яисә ремонтлауга, юллар төзүгә яисә коммуникацияләрне тоташтыруга, мал-туар, авыл хуҗалыгы техникасы яисә инвентаре, күпьеллык үсемлекләр утырту өчен, утырту материаллары сатып алуга тотарга рөхсәт ителә.



При Татобкоме комиссия создана из 17-ти товарищей, с одной стороны знающих деревню, а с другой непосредственно соприкасающихся в своей работе с ней. В качестве плана ближайшей работы Комиссии было принято—изучение и разработка мероприятий по следующим вопросам: 1) социально-экономические процессы в деревне; 2) содержание работы деревенских парт'ячеек; 3) низовой советский аппарат и мероприятия по его оживлению; 4) деревенская кооперация; 5) совхозы и различные формы сельско-хозяйственных об'единений; 6) культурно-просветительная работа в деревне; 7) батрачество и работа Всеработземлеса; 8) вопросы подготовки работников для деревни; 9) содержание работы среди молодежи; 10) содержание работы среди крестьянства; 11) вопросы шефства и организации землячеств.

Шунысы куанычлы: быелдан «Агростартап» саллыракка әйләнде. Грантлар суммасы шактыйга артты (сөтчелек һәм итчелек МЭТ юнәлеше буенча – фермерның бизнес-проектына 3 млн сумнан 5 млн сумга кадәр һәм фермер кооперативта торган очракта кооперативны үстерүгә 4 млн сумнан 6 млн сумга кадәр).

Ике ел эчендә «Агростартап» программасы буенча 164 фермер (600 млн сумнан артыклык) грант ярдәме алган. 52 кооператив 128 млн сумлык субсидиягә ия булган. Марат Җәббаров сүзләренә караганда, «Агростартап»ка гына да инде 300 гариза килгән, алар 1,2 млрд сум акчага дәгъва итә, бу әлеге проектның авыл хуҗалыгы эшкуарлары тарафыннан энтузиазм белән каршы алынуын аңлата. Инде грант алырга теләүчеләрдән чират тезелде, дип әйтергә була.

«Агростартап» белән бергә, Татарстан киләсе елдан яңа «Агропрогресс» грантын кертергә планлаштыра, аның суммасы 30 млн сумга җитә ала. Яңа грантлар авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен билгеләнә, исемлеккә КФХ, шәхси эшкуарлар, авыл хуҗалыгы кооперативлары керми.

– Монда барысы да чын эшсөярләр: роботлар гына түгел, гаилә дә тырышып эшли, – ди Минсинә Латыйпова.

РОБОТЛАР ГЫНА ЭШЛӘМИ

ТР Биектау районында яшәүче Минсинә һәм Ленар Латыйповлар агробизнеста яңа кешеләр түгел. Беренче мәртәбә сөт терлекчелеге белән алар ун ел элек шөгыльләнә башлый. Акрын-акрын гына эш оешып китә, гаилә алга таба да эшчәнлек юнәлешен үстерергә карар кыла. 2014 елда беренче тапкыр грант оталар. Акчага биналарны зурайталар, савым сыерларының баш санын арттыралар. Бизнесның үз кагыйдәләре: күләмнәрнең артуы продукциянең үзкыйммәтен киметүгә китерә, димәк, рентабельлек тә арта. Шуңа күрә узган елда эшкуарлар терлекчелек фермасын арттыруга эре грант алуга гариза тапшыралар һәм оталар. Эшкуарларга бизнес-планны эшләргә ТР Фермерлар ассоциациясе җитди ярдәм күрсәтә. Дәүләт ярдәменең күләме 28,8 млн сумны тәшкил итә.

– Грант шартлары буенча, без проектка үзебездән 20 млн сумга якын акча кертергә тиешбез, – дип аңлата Минсинә Латыйпова. – Шуңа күрә без 14 миллион сум күләмендә үз акчабызны керттек һәм җитмәгән 7 млн сумны «Россельхозбанк»тан кредитка алдык.

Грант акчаларына нәселле терлек сатып алдык: күрше республикадан 80 баш голштин токымлы таналар (бүген инде алар бозаулады) һәм үзебезнең районнан 48 баш голштин. Тулысынча роботлаштырылган саву һәм ашату линияләре урнаштырдык, биналарны зурайттык. Башыннан ахырынача – барлык процесслар да автоматлаштырылган.

– Кредитны кайтару срогы – биш ел, – дип, исәп-хисап белән таныштыра фермер. – Бүгенге темплар белән барганда, киләсе елның ахырына банк белән тулысынча исәп-хисапны өзәрбез һәм табыш ала башларбыз, дип ниятлибез.

– Татарстан фермерларына күрсәтелә торган ярдәм башка бер генә күрше төбәктә дә юк, – дип сүзгә кушыла Минсинәнең ире Ленар. – Күрше республикалардан безгә, Татарстанга ничек күченеп килергә, монда, безнең республика территориясендә, үз бизнесларын башлап җибәрергә теләп, киңәш сорап, миңа инде әллә ничә мәртәбә мөрәҗәгать иттеләр. Алар безгә кызыгып карыйлар.

– Татарстан фермерларына күрсәтелә торган ярдәм башка бер генә күрше төбәктә дә юк, – дип сөйли Ленар Латыйпов.



Бүгенге көнгә Латыйповлар хуҗалыгында 198 МЭТ исәпләнә, шуларның 130 башы – савым сыеры. Уртача алганда бер сыердан 4,5 мең килограмм сөт савып алына. Агымдагы елның 11 аенда фермерлар якынча 10 миллион сумлык продукция саткан.

Грант бирү шартлары буенча, хуҗалыкта сыерларның баш саны, җитештерелә торган сөт күләмнәре кимемәскә тиеш. Моннан тыш, фермада алар өч яңа эш урыны булдырырга тиешләр.

– Бүген инде бер кешене эшле иттек. Ел ахырына кадәр тагын ике кешене эшкә алабыз, – дип сөйли Минсинә Латыйпова.

Фермерларның 380 гектар мәйданда үз җирләре бар. Җәй көнне тагын 7-8 кеше эшли, алар уртача 30 меңнән 40 мең сумга кадәр хезмәт хакы ала, шәһәр белән чагыштырганда да начар түгел.

Ялланган хезмәткәрләрдән тыш, эти-әниләренә ике балалары бик зур ярдәм күрсәтә.

– Алар җомга көнне кич кайтып, якшәмбе кич белән генә китәләр. Ял көннәрендә безгә булышалар, – ди фермер.

Монда барысы да чын эшсөярләр: роботлар гына түгел, гаилә дә тырышып эшли. Авылдашларына да эш табыла.

Һәм бу республика ярдәм кулы сузган бер ферма мисалы гына. Үз чиратында республика агросәнәгате инде бүген үк инициативалы авыл хезмәтчәннәренә таяна ала. Алар сынатмас!

1925

«ПУТЬ ИЛЬИЧА» ЖУРНАЛЫ

Дөнья пролетариаты юлбашчысы вафатына бер ел тулгач, 1925 елның 21 гыйнварыннан «Коммунистический путь»ны аның истәлегенә «Путь Ильича» дип үзгәртәләр. Ул Ленин эшен, СССРда һәм чит илләрдә коммунизм хәрәкәте үсешен киң яктырта башлый. «Безнең карашыбызча һәм йөзләгән иптәшнең фикерләренчә, – дип яза янә исеме үзгәртелгән журнал редакциясе баш мәкаләдә, – «Коммунистический путь» артык катлаулы, массакүләм укучыга аңлашылмый иде. «Путь Ильича» журналында... үзебездә, Татариядәге, һәм Көнчыгыш илләрендәге (Төркия, Иран, Кытай, Әфганстан һ.б.) партия тормышын яктыртырга тырышачакбыз».

Журнал мәдәният өлкәсендәге вакыйгаларга игътибарын арттыра. 1925 елда Татреспублика Парижда оештырылган Халыкара декорация эшләре күргәзмәсендә катнаша, басмада шул хакта укыйбыз: «Татреспублика чигешләрдән, баш киемнәреннән гыйбарәт бик бай экспозиция тәкъдим итә, шулай ук көнчыгыш телләрендәге китаплар күрсәтелгән үзенчәлекле бүлек тә бар, алар арасында да Татреспублика китаплары аерылып тора».

Сәяси материаллар белән бергә, журналда әдәби әсәрләр – шигырьләр, очерклар, хикәяләр, тәнкыйть мәкаләләре, бик күп рәсемнәр һәм фотолар басыла башлый.

МӨХӘРРИР

Григорий Цыпин

Яңартылган журналның җаваплы (баш) мөхәррире һәм аның идея илһамчысы Григорий Цыпин була. «Вечерняя Москва»ның журналистлары аны яхшы белә һәм бүгенге көнгәчә ярата, чөнки Цыпин ул газетада да эшләгән. Ул килгәч, «Вечерняя Москва»ның беренче битендә көн кадагындагы зур фото һәм язу пәйда булган – аны «фотофельетон» дип атаганнар. Язмаларга да үткен башисемнәр куелган. Аларны редакторларның махсус «өчлеге» уйлап таба торган булган.

«Цыпиннан» яңалыклар күп булган – заманында ул Мәскәүнең иң яшь баш мөхәррире саналган. Башкалага кадәр, тагын да яшьрәк чакта, ул периферияда мөхәррирлек итә – Курскида, Әстерханда, Харьковта. Ә инде үзенең мөхәррирлек юлын Григорий Евгеньевич Казанда башлый. Башта – «Красная Татария» газетасында, анда ул үзенең креативлыгы белән әлләни аерылып тормый, аның каравы, 1925 елда – ярты елдан соң исеме «Причал»га алыштырылачак «Путь Ильича»да эшләп тә карый инде!

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлегендә сакланган «Путь Ильича» һәм «Причал» саннары бүгенге көнгә кадәр укучыда гаять зур кызыксыну уята – барысы да журналны сокланып һәм дөньясын онытып укый: зур фотографияләр, үткен башисемнәр – менә Цыпинның «Вечерняя Москва»сы каян башланган.

Әбиләр һәм бабайлар яшенә җиткән «балалар» «Причал» мөхәррирен «алтын» китаплар буенча белә. 1935 елда Григорий Цыпинны Детиздат мөдире итеп билгелиләр. Ул анда зиннәтле алтын төпләнмәле китаплар чыгара.

Григорий Цыпинны 1937 елның декабрендә – нәкъ менә Яңа ел алдыннан кулга алалар. Ә инде 1938 елның 29 августында «контрреволюцион террорчылык оешмасында катнашкан өчен» атып үтерү турындагы хөкем карары гамәлгә ашырыла. 1956 елда Григорий Цыпинның исеме аклана.

1938 елның 29 августында – 39 яшендә атып үтерелә.
1956 елның 8 декабрендә (үлеменнән соң) аклана.

ЛЕНИНО-КОКУШКИНО: «УЛЫБЫЗ ТУСА, ИСЕМЕН ВЛАДИМИР ДИП КУШАЧАКБЫЗ»

Автор: Татьяна Вафина

Фото: Ната Смирнова

Дөнья пролетариаты юлбашчысының вафатыннан соң ук «Путь Ильича» дип үзгәртелгән журналның Владимир Ленинга багышланган тулы бер саны зур кызыксыну уятты бездә. Анда Казан университеты фотосы, юлбашчыга багышланган хикәя, шигырьләр, аның анкетасы, үлеме турында некролог һ.б.лар урын алган. Бүген республикабызда Ленин истәлеге ничек саклана, аның белән бәйле урыннар ни хәлдә – материалыбыз шул хакта.

Юл, тәгәрмәчкә урала-урала, әллә кайларга алып китә, ә авыл һаман бетми дә бетми. Совет чорында шушы очсыз-кырыйсыз юл буйлап зур-зур автобусларда октябрятларны алып киләләр иде, дип сөйлиләр. Ә яңадан җибәрмәгәннәр, имеш. Шул ук вакытта берәү дә бу төр мәктәп укучыларының күпләп югалуы турында милициягә хәбәр итмәгән. Бәлки, яңадан шәһәргә бу автобусларда комач төсендәге яңа галстук бәйләгән пионерларны алып киткәнгәдер...

Советлар чорыннан калган шушы серне ачар өчен аның үзегенә – дөнья пролетариаты юлбашчысы Владимир Ульяновның бабасы – алпавыт Александр Дмитриевич Бланкның йортына киләбез. Яшь Ленин – ул чакта әле Ленин түгел – биредә еш кунак булган, беренче сөрген вакытын да монда уздырган.

ПИОНЕРЛАРЧА ЯШЬ КАЛУ СЕРЕ

Музейның фәнни хезмәткәре Константин Кадров әлеге пионерларның (дөрес, галстуксыз, әмма инде сакаллы, мыеклы кешеләрнең һәм оныклары белән) 19 май – Пионерлар көнендә бирегә килүе турында сөйли. Утар буйлап йөриләр, хатирәләргә биреләләр һәм күз алдында гүя яшәрәләр.

Музей өчен тагын бер изге көн – 22 апрель. Аны коммунистлар ярата. 1870 елда дөньяга Ленинны биргән язгы көндә алар биредә тантаналы митинг үткәрә, инде кире кайтарып булмаган үткәннәрне искә ала...

– Ә менә Зюганов Казанда булганда, бирегә килеп тә китмәде, – дип ризасызлыгын белдерә Константин Иванович. – Ә без аны көттек...

ТУРИСТЛАР АГЫМЫ

Туристларның башка категорияләре – биредә сирәк кунак. Әмма алай ук сирәк тә түгел. Музей-йортның ишегенә эленгән прайста «өлкәннәр өчен билет бәясе – 100 сум, балаларга – 50 сум» дип язылган. Чит ил гражданнарына – 200 сум.

– Чит ил кешеләреннән биредә иң күбе кытайлар була, – дип ачыклык кертә Константин Иванович. – Менә күптән түгел генә бер туристик компания белән килешү төзедек – зур-зур төркемнәре белән алып килә торган булачаклар.

Сирәк булса да, башка илләрдән дә дөнья пролетариаты юлбашчысы яшәгән җирне күрергә килеп чыккалыйлар икән. Барыннан да бигрәк аларны утардагы йорт кирәк-яраклары һәм Владимир Ульянов яшәгән флигель кызыксындыра.

– Ул вакытта ук булган әйберләр бик аз калды, – ди Константин Иванович. – Утар өч тапкыр янды, инкыйлаб вакытында ук әле җирле крестьяннар тар-мар итеп чыккан булганнар.

МУЗЕЙ ЯДКАРЬЛӘРЕ

Шәхсән үзебезгә барысы да ошый – искесе дә, яңасы да: керосин лампасы да, кулъюгыч та, самовар да, рояль дә. Миче бигрәк тә. Тик менә үсмер Ильич белән энесе Дмитрий бүлмәсендәге карават кына артык бәләкәй тоела, әйтерсең лә, балалар караваты.

– Ульяновлар барысы да тәбәнәк буйлы булган бит, – дип, ачыклык кертә фәнни хезмәткәр.

Менә без дә озын буйлы түгел, әмма мондый кыска караватка барыбер сыймабыз кебек. Кызганыч, тикшерер өчен ятып карап булмый – җәймәсе ап-ак. Музей музей инде: барысы да «тикшерүчеләр»дән һәм «тотып караучылар»дан тасма белән аерып куелган. Карарга гына ярый.

ОТЛИЧНИКЛАР ҺӘМ МЕДАЛИСТЛАР ГАИЛӘСЕ

Музейда әлеге мөхтәрәм гаилә әгъзаларының барысының да портретлары бар. Владимир Ульяновның әнисе ягыннан гына да 30 икенче буын туганы булган. Һәм аларның барысы да бабаларының утарында җыелыша торган булган. Балаларның һәм эти-әниләрнең укымышлылыгы сокландыра.

Халыклар юлбашчысының этисе – Илья Николаевич мәктәпне көмеш медальгә тәмамлаган. Ә Казан университетыннан математика фәннәре кандидаты булып чыккан.

Олы кызлары Анна мәктәптәге уңышлары өчен көмеш медаль алган, аннан соң Петербургта Югары хатын-кызлар (Бестужевлар) курсларында тел-тарих бүлегендә белем алган.

Александр – Володя Ульяновның өлкән абыйсы – мәктәпне алтынга бетергән. Икенче алтын медальне аңа Петербург университетының физика-математика факультетындагы табигать фәннәре бүлегендә өченче курсны тәмамлаганда, диплом эше өчен биргәннәр.

Апасы Ольгага яхшы укыганы өчен гимназиядә стипендия алып уку хокукы бирелә һәм эти-әнисе укыган өчен түләүдән азат ителә.

Владимир үзе дә мәктәпне алтын медальгә тәмамлый, Мариинск хатын-кызлар гимназиясен алтын медальгә тәмамлаган Ольга апасы кебек үк.

Кечкенә Дмитрий белән Маняша да уку буенча эти-әнисенең йөзенә кызыллык китерми. Шулай итеп, эти-әниләренең балалары белән горурланырлыгы була.

СОВЕТ КЫЗЛАРЫНЫҢ ХЫЯЛЛАРЫ

Кайбер туристлар, бигрәк тә кызлар, Володяның уңышларыннан тәэсирләнеп, фикерләр дәфтәренә болай дип язып калдырганнар: «Улыбыз туса, исемен Владимир дип кушачакбыз».

Истә әле: әлеге юлларның авторы да совет чорына туры килгән биш яшьлек чагында, Ильичның балачагы турындагы китапларны иҗекләп укыганда, шулай дип хыялланган иде. Балачак хыялларына тормышка ашарга насыйп булмый: авторның гаиләсендә уллар да, вундеркиндлар да үсми.

Бер генә нәрсә күңелгә тынычлык бирә: әлеге гаиләгә карасаң, артык укымышлы балалар революцион үзгәрешләр ясарга әвәс була диган фикергә киләсең. Ульяновларның алты баласы да революционер булып китә. Ә әниләре язмышына патшага үтенечләр белән мөрәҗәгать итәргә, сөргеннәргә, төрмәләргә йөрергә язган була...

Константин Карпов, әле хәзер дә Пионерлар көнендә бирегә пионерлар килә, дип сөйли.

На том месте, где раньше была усадьба Бланк, ныне высокий столб стоит. На столбе дощечка с надписью:

> **ЗДЕСЬ**
> **стоял дом, в котором жил**
> **ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ УЛЬЯНОВ**
> **(Н. ЛЕНИН)**
> **в свои детские годы и в 1886—1889 г.г.**

* * *

Свидетель юных лет Ильича, Яков Дмитриевич Феклин, и ряд других крестьян - старожил деревни Кокушкино хорошо помнят молодого Владимира Ильича и все семейство Ульяновых.

Этот период в жизни деревни Кокушкино,—ныне Ленино—по единодушному отзыву крестьян — оставил глубокий светлый след в их памяти.

— Как за пазухой жили. И никогда нам ни в чем никакого отказа не было.

Свидетель юных лет Ильича—крестьянин Яков Дмитриевич Феклин.



БЕРДӘНБЕР ОЧРАК

Бланк утарында яшәгән кешеләр бу фани дөньядан күптән бакыйлыкка күчкән. Ленино-Кокушкинода алар турында хәтерне саклыйлар. Сакларлык та шул. Нәкъ менә совет чорында утарга пионерларның игътибары зур булу сәбәпле, авыл бүген дә зур, бай яши.

Эш бар (телисең икән – кошчылык фабрикасында эшләргә була, телисең икән – совхозда), мәктәп бар, газ-су-асфальт кергән. Әгәр дә инде көянтә аскан берәр апаны очратасыз икән – ул бердәнбер очрак, әйтергә кирәк, экзотика. Менә без бара торган юл аша буш чиләкләрен көянтәгә асып, кая бара ул апа? Ярый әле Ленино-Кокушкинода хәрәкәт салмак, машиналар сирәк уза. Туктап, көянтә аскан апа сызып үткән теге куркыныч сызыкны берәр хорафатларга ышанмый торган кеше атлап чыкканын көтеп торырга кирәк булуы мөмкин.



Авыл бүген дә зур һәм бай булып кала.

МИЛЛӘТЛӘРНЕҢ УН БУЫНЫ

Халыклар дуслыгы һәм бөтен милләтләргә карата толерантлык темасы аеруча актуаль булган заманда Володя Ульяновның шәҗәрә агачына игътибар итми калып булмый. Ул ун буын эчендә үзендә төрле милләт канын катнаштыруы белән кызыклы: бирeдә немецлар да, шведлар да, яһүдләр дә, руслар да, 1/8 өлешкә калмыклар да бар. Чувашлар да бар, диләр.

Көянтә аскан апа – җирле экзотика...

ТОРМЫШТА БЕРЕНЧЕ АДЫМ МӨҺИМ

Сәяхәткә йомгак ясап, болай дияргә була: Ленино-Кокушкино – чиста һава, Үшнә елгасында балык тоту мөмкинлеге һәм ыгы-зыгыдан тәмам туйган шәһәр кешесе өчен тансык тынлык ул.

– Яз көне бирегә аккошлар кайта, – дип сөйли музей фондын саклаучы Люция Зиннәтуллина. – Безгә яз көне килегез!

Музей-тыюлык хезмәткәрләре, утарны аудиоүсеш белән тәэмин итү кирәк, дигән фикердә торалар. Менә Константин Иванович халыкка Ленин туган көнне аның сөйләгән сүзләрен тыңлатырга тели. Оригиналда. Кунакларга Ленин турындагы җырларны тыңлатсаң да, яхшы булыр иде. Әмма утарда магнитофон да, колонкалар да юк. Тавыш чыгара торган кораллардан җәйге флигельдә иске рояль генә тора... Туристларны Ленинның үткәненә әнә шулар да алып кайтса, файдалырак булыр иде дә бит.

Асылда, чынга ашыра алмаслык хыял да түгел, кыйммәтле нәрсә түгел бит инде. Балачагында пионер булган теләсә кайсы меценатның кулыннан килерлек эш. Пионерлар ничек җырлый иде әле: «Неба утреннего стяг, в жизни важен первый шаг...»

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ

Бик җайлы. Казаннан Самосырово ягына таба чыгабыз да, 42,6 чакрым юл узгач, күрсәткечтәге юнәлешкә таба борылабыз.

ТАРИХИ НЕЧКӘЛЕКЛӘР

Авылның исеме турында авыл кешеләре болай дип хәтерли: «Элек монда агачлык булган, күкеләр кычкыра торган булган... Ни өчен Кукушкино түгел, ә Кокушкино? Кем белгән инде...» Күрәсең, биредәге сөйләшкә яраклаштырылгандыр. Шунысы төгәл билгеле: авыл Казан ханлыгы чорында ук булган һәм ул Татар Яңасаласы дип аталаган. Күкеләр, күрәсең, Россия империясе вакытында үрчегәндер, һәм шуннан соң Кокушкино дигән исем биргәннәрдер. Аннан соң, 1924 елда, Ленинның вафатыннан соң, аңа юлбашчының исеме дә өстәлә. 1964 елдан соң юлбашчының исемен дә, элекке күкеләр исемен дә алган һәм Ленино-Кокушкино булып киткән.

ИСТӘЛЕККӘ НӘРСӘ АЛЫРГА

Музейда бернинди магнитлар да һәм шуның ише вак-төякләр каралмаган. Аның каравы совет чорында ук чыгарылган китапчыкны бушлай алырга була. Анда алты урынлы саннан торган телефоннар да бар әле. Татарстанны – Татария, Самараны Куйбышев дигәннәр. Музейда бүген дә бушлай таратырлык булгач, ул вакытта бу буклетларны ничә миллион тираж белән чыгардылар икән?! 50 000 данә, дип язып куелган астына. Татариянең туризм һәм экскурсияләр буенча өлкә советы заказы буенча, диелгән. Күчтәнәчләр-сувенирлар кирәк булса, «Үшнә» балык хуҗалыгына кереп чыгарга киңәш итәбез. Кичке ашка яңа тоткан балык та сатып алырга була. Без карп балыгы алдык. Ә июль аенда сатуга белуга (кырпы балыгы) чыга башлый. Патша балыгы Ленин урыннарында үстерелә!

Совет чорында шушы очсыз-кырыйсыз юл буйлап зур-зур автобусларда октябрятларны алып киләләр иде, дип сөйлиләр.

1925

«ПРИЧАЛ» ЖУРНАЛЫ

РЕДАКЦИЯДӘН

«Путь Ильича» журналының беренче саннары дөнья күргәннән соң, укучыларыбыздан күпсанлы хатлар алдык. Татреспубликаның төрле почмакларыннан журналны җанлырак, төрлерәк, кызыклырак итәргә кирәклеге турында кайбер күрсәтмәләр килде.

Укучыларның хатларында, гомумсәяси мәсьәләләргә караган материаллар белән беррәттән, беллетристика, фән һәм техника, дөнья хроникасы һ. б. ш.ларны күбрәк урнаштырырга кирәклеге турында язылган.

Журналыбызны укучыларның теләкләрен үтәп, без аны «Причал» дип үзгәртеп, 5 нче саныбызны чыгарабыз һәм киләсе саннарны да әлеге теләкләргә ярашлы рәвештә бастырачакбыз.

«Путь Ильича» журналына язылучыларның барысы да шулай итеп «Причал» журналын алачак.

Редакция

На международной декоративной выставке в Париже

Статья П. Дульского

Задачи, которые преследует СССР на Парижской выставке, хорошо определены т. Л. Б. Красиным:

„На этой выставке мы собрали подлинные образцы народного художественного творчества, пробившегося сквозь тяжелые годы гражданской войны к новой эпохе. Однако, затрачивать огромные суммы и конкурировать в этом отношении с другими государствами, конечно, мы не могли. Тем важнее показать иностранцам, как мы работали все эти годы и в каком направлении движется и идет наше искусство.

Татреспублика выставила очень богатый отдел вышивок, и среди них всех приводит в восхищенье „подзор“, шитый золотом и серебром по коричневому бархатному фону.

Очень полно представлен у Татреспублики отдел головных уборов, начиная от старомодных колпаков и кончая шитьем золотом на мотивы современности, где основой орнаментации послужил узор герба—„серп и молот“.

Имеются также в отделе Татреспублики изделия из кожи, цветная обувь, которой до сих пор славятся татары.

Чираттагы үзгәреш җилләре нәтиҗәсендә «Причал» дип атала башлаган журналыбызда гаять кызыклы материалга тап булдык. Анда Татреспубликаның 1925 елда Парижда үткәрелгән Халыкара декорация эшләре күргәзмәсендә катнашуы турында язылა. Ул чакта татар чигеш үрнәкләре, кул эшләре дөнья күләмендә искиткеч уңыш казана. Милли татар һөнәрчелеге бүген ни хәлдә? Бүген шул хакта сөйлибез.

ТАТАР ЛАЛӘСЕ ЧӘЧӘК АТКАН МӘЛДӘ

Автор: Ната Смирнова

Әкиятләрдә генә явыз үги әни үги кызын умырзая эзләргә кыш көне урманга җибәрә. Татарстанда исә кышын чәчәк артыннан урманга йөрергә кирәкми. Ел фасылы нинди булуга карамастан, умырзаялар, лаләләр, тагын әллә нинди матур гөлләр халыкның иң модалы катламы киемен чәчәккә күмә. Чөнки татар бизәге һәм колоритына мәхәббәт дөньяны яулый бара.

Фото: Ната Смирнова

МИНИАТЮРАДАГЫ
МИЛЛИ МАТУРЛЫК

Шундый үзенчәлек күзәтелә: Казанның модалы кызлары бәләкәй түбәтәй кия башлады. Бу миниатюр матурлыкны Миләүшә Мусина ясый.

Миләүшәнең үз ательесы бар, аңа ул әбисенең әнисе Миңлениса исеменнән алып MISA дип кушкан. Миңленисаның тегү машинасы гаиләдә хәзер дә саклана, ул ирсез калган әбисенә балаларын ачтан үтерми калырга булышкан. Миләүшә һәрвакыт замана кызларының гардеробында милли символикалы әйберләр булсын иде, дип хыялланган – һәм менә аның кәләпүшләре популярлык казанган инде. Кызлар таҗ кебек түбәтәй киеп төшкән фотоларын социаль челтәрләргә куярга ярата, шулай итеп оста дизайнерның клиентлары гел арта бара, татар модасы популярлаша.

Реклама.

САРМАН
ФУТБОЛКАЛАРЫ

Татар мотивлары – һәрвакытта да кыйммәтле киемнәр генә түгел. Аларның кайберләре гади халык алырлык арзан да, шул ук вакытта матур да. Мондый урынны без Сарманда таптык – Алия Нәфыйкованың яңа һәм яшьләрчә бренды үзендә гади көндәлек киемне һәм милли колоритны берләштерә.

– 2015 елның маенда, әле студент чагымда, мин практика үттем, – дип сөйли бу гади футболкаларның авторы Алия Нәфыйкова. – Анда мин татар бизәге белән кызыксына башладым. Үз халкымның мәдәнияте белән илһамланып, мин үзем дә нәрсәдер уйлап табарга булдым. Һәм татар милли бизәкле футболкаларда тукталдым. Минем һәрвакыт үземнең йөрәгемә якын, оригиналь эш белән шөгыльләнәсем килә иде, һәм татар бизәгенә мәхәббәт миңа хыялымны тормышка ашырырга булышты. Минем өчен болар барысы да – татар символикасы, бизәкләре, борынгы халык җырлары бик якын, алар мине дәртләндерә.

Ять-яшь кенә булса да, Алиянең хыяллары бик зур. Ул үз бренды киемнәренең һәр гардеробта булуын тели. Идеяләре белән интернетта теләп уртаклаша. Анда аның иҗатына мөкиббәннәр дә, милли колоритлы футболка сатып алырга теләүчеләр дә байтак.

– Татар дизайнлы кием-салым һәм аксессуарларның трендта булуы бик шәп, – ди Алия. – Элегрәк масс-маркетлар бер типтагы киемнәр тәкъдим итә иде, ә кешеләрнең үз күңелләренә ятышлы әйбер киясе килә бит. Милли колоритлы кием, «үзебезнеке» булганга, җанны җылытырга сәләтле.

СӘНГАТЬ ӘСӘРЕ
БУЛАРАК ЧИТЕК

Милли колоритлы мода турында сүз башланган икән, биредә инде модельле туфлиләр белән генә булмый. Милли костюмга чәмчәле читекләр яки чүәкләр дә кирәк. Шуларны эзләп, күн мозаикасыннан уникаль аяк киеме тегүчеләр янына киттек. Илдус Гайнетдинов хатыны Әлфия Артемьева белән үзләренә шундый максат куйган – татар милли кәсебен саклап калу һәм торгызу.

Реклама.

Мозаикалы аяк киеме күн кисәкләреннән уникаль, башка халыклар сәнгатендә очрамый торган кул җөе техникасында ефәк, алтын һәм көмеш җепләр кулланып тегелә.

ҺӘР ПАРЫ БЕРДӘНБЕР

– Мин бу кәсеп белән 1977 елдан, Арча фабрикасында эшләгән чагымнан алып шөгыльләнәм, – дип исенә төшерә Илдус Гайнетдинов. – Әмма мондый аяк киеме конвейерда әзерләнергә тиеш түгел. Әгәр аны механик әзерләүгә кайтарып калдырсаң, мондый матурлык килеп чыкмый. Һәр пар – бердәнбер. Аңа чигүче үзенең күңелен куша. Чиккәнче дә әллә никадәр эш эшләргә кирәк: модель уйлап табу, бизәк, өлге, төрле төстәге күн сайлау. Һәр читек – сәнгать әсәре ул. Кызганычка, бик кыйммәтле әсәр түгел. Кулдан эшләнгән читекләр уртача 10 меңнән 27 мең сумга кадәр тора. Чүәк һәм туфлиләр исә – 1600 дән 4 мең сумга кадәр. Европада мондый аяк киемнәренең бәясе 500 евродан башлана.

ТАТАРЛАР ГЫНА КҮННЕ ВАК КИСӘКЛӘРГӘ ТУРЫЙ

– Башта күнне вак кисәкләргә турап, аннары кулдан тегү белән татарлардан кала башка беркем дә шөгыльләнми. Менталитет үзенчәлеге, – дип горурланып күрсәтә вак күн кисәкләрен Әлфия Артемьева. – Без барыбыз да бөтен нәрсәне эшли беләбез, әмма кемнең күңеленә нәрсә якынрак, шуның белән шөгыльләнәбез. Илдус Хаҗимулла улы – искиткеч бизәкче, белеме дә, үзенең эчтән тоемлавы да менә дигән. Мин күбрәк төсләр белән эшлим. Ниндидер сорау туса, бергәләп тикшерәбез, планлаштырабыз... Бик тиз кирәк булганда, без төн эчендә яңа аяк киеме тегеп өлгертә алабыз.

ИДЕЯЛӘР КОСМОСТАН КИЛӘ

– Һәр бизәккә мәгънә салынган, – ди Илдус. – Мәгънәсез берничек тә булмый. Мин күңелем теләгән рәсемне ясыйм. Идеяләр космостан килә...

Әлфия төрле төс, форма һәм үлчәмнәрдән күргәзмәгә дип ясаган беренче коллекцияләренең «мизгел эчендә сатылуын» искә төшерә.

Фото: Ната Смирнова

«ИҖАТЫМ БЕЛӘН БАЙМЫН»

Кәсепчеләр үз эшләреннән күргәзмә оештыру турында хыяллана. Әмма әлегә килеп чыкмый, «җитештерү бөтен нәрсәне йотып бара».

– Бөтен керемне үсешкә тотабыз. Олы улыбыз безгә кушылды инде, сумкалар белән шөгыльләнә. Кечесе дә әкренләп кул арасына керә. Бәлки, алар безнең кәсепне гөрләтеп эшләтә алыр, – дип хыяллана әти-әни.

– Миннән еш кына, син баймы, дип сорыйлар, – дип йомгаклый әңгәмәбезне Илдус. – Мин болай җавап бирәм: миңа бөтен нәрсә җитә. Минем күңелем бай, мин үземнең иҗатым белән баймын.

Реклама.

– Минем бурыч татар милли аяк киемен популярлаштыру иде, – ди ул. – Гәрчә күпләр миңа, үз тамырларыннан оялгандай, миллигә охшатып кына ясарга да киңәш биргәләде. Ә без үз бизәкләребезне бик матур, дип саныйбыз. Һәм әгәр дөрес калыпта, дөрес төстә һәм дөрес концепция белән тексәң, бу менә дигән модалы читекләр булып чыга. Мин әйбернең аутентик нигездә, әмма заманча булуын теләдем.

КӨНДӘШЛӘР ЮК

– Безнең эш уңышлы гына көйләнеп киткәч, халык уяна, бу бик җиңел, дип уйлый башлады. Әмма ничек уяндылар, аннары шулай йокыга да киттеләр, – дип елмая Илдус, ул вакыттагы көндәшлекне исенә төшереп. – Кешеләрнең түземлеге җитми. Бу бик катлаулы. Мин һәрвакыт авыл белән элемтәдә торам. Без чигә торган урында бу – геннар дәрәҗәсендә – мондый эшне һәр йортта күп еллар буе башкарганнар. Бу бик керемле җитештерү түгел, тиз арада акча эшләп булмый. Без көнне төнгә ялгап, ялсыз эшлибез, аннан соң гына нәтиҗәсе күренә. Кешеләргә исә бик тиз арада һәм бик күп керем алу кирәк. Барысы да уйлый: менә, китаптан бизәк күчереп алган да, чиккән. Безнең бик җиңел һәм гади бизәкләребез дә, бик катлаулылары да була. Һәр чәчәкне, һәр төенне җентекләп эшләргә, гармонияле күренсен өчен, һәркайсының үз урынын табарга кирәк.

Бервакыт минем яныма булачак эшкуарларның берсе килде дә, чигә торган бер машинаны сатуымны сорады. «Әлбәттә. Менә минем чигүчеләремнең берсе пенсиягә чыгарга җыена, сөйләшсәң, бәлки ризалашыр», – дим. Ул егылып китә язды. Ул боларның барысы да кулдан эшләнүен күз алдына да китерә алмаган. Аның бизнес-планы да әзер булган үзе, тик барып кына чыкмады.

АЯК КИЕМЕННӘН КҮЗЛЕК САВЫТЫНА КАДӘР

Үзенең барып чыкмаган көндәшләрен көлемсерәп искә алса да, Илдус заказларның көннән-көн арта баруын, үзләренең генә өлгерә алмауларын танырга мәҗбүр. Хәзер базарга охшаш брендларның чыгуы бер дә начар нәрсә түгел. Аяк киеме генә түгел, панно һәм җиһазлар да ясарга туры килә икән. Милли символикага ихтыяҗ бөтен тармакларда да үсә.

– Кол Шәриф мәчетендә без пуфиклар һәм банкеткаларны ясадык, – дип санап китә Илдус. – Камал театрында, «Туган авылым» комплексында… Татар бизәкле галантерея – сумкалар, күзлек савытлары, әйбер тышлары җитештерәбез. Мондый әйберләр уникаль, теләсә кемгә бүләк итеп була. Бу – VIP-бүләкләр. Алар бөтен дөньяга тарала.

Реклама.



#МОЙТАТАРСТАН

Татар бизәге кием тегүгә генә илһамландырмый. Дизайнер Ринат Сәфәров, мәсәлән, аларны кружка, оекбаш, телефон чехолларына төшерә...

Аны релакс-буягычларга, блокнотларга, картиналарга «үреп кертә», аңардан хәрефләр һәм, безнең татарстанлылар йөрәгенә аеруча якын булганы, #МИНЕМ РЕСПУБЛИКАМ принтларын ясый – анда һәр шәһәр исеме милли бизәкләр белән язылган. Менә ул, гамәлдәге чын ватанпәрвәрлек! Ринат туган ягының мирасын социаль челтәрләрдә данлый һәм саклый бит – тамырлары белән горурлана, аның дизайнерлык миссиясе шунда.

Ләйсән Хаҗиева,
«Ләйсән сәйләннәре» милли татар киемнәре коллекциясе модельеры:

– Моннан 100 ел элек без үзебезнең милли костюмны югалтканбыз. Ул бары тик китапларда, әбиләр хәтерендә генә калган. Асылда, хәзер ул юк. Татар милли киеме стилендә эшләнгән костюмнарны, кызганыч ки, бүген без сәхнәдәге артистларда гына күрә алабыз. Һәм мин аны торгызырга, заманчалаштырырга, стильләштерергә маташам. Без аны, оялмыйча, көн саен киеп йөрерлек булсын иде.

Зөлфәт Зиннуров,
эстрада җырчысы,
алып баручы:

– Безнең олимпиячеләрнең спорт киемнәре коллекциясе моңа күрсәтмә иллюстрация була ала. Аны бүген президент, төбәк җитәкчесе, мэрлардан башлап гади кешеләргә кадәр барысы да кия. Минем фикеремчә, республика җитәкчеләре, танылган кешеләр популярлаштыруда катнашмаса, милли киемнең киләчәге өметле булмаячак. Шәхсән мин үзем милли киемне бик рәхәтләнеп киеп йөрер идем.

Разил Вәлиев,
Татарстанның халык шагыйре

– Атаклы татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани, милләтне саклау өчен, аның телен, гореф-гадәтләрен, көйләрен, җырларын, ашларын һәм шул исәптән киемен дә саклау зарур, дип санаган. Һәм без боларның барысын да саклау өчен шартлар тудырырга тиеш. Безне дә, әйтемдәге кебек, татар киеме буенча каршы алсыннар, тик татар акылы буенча озатсыннар иде...
Милли кием көне булдыруны республика җитәкчелеге хуплый. Аны үткәрү көнен генә билгелисе калды. Ихтимал, бу 30 августта булыр. Республика бәйрәменә Татарстанда яшәүче барлык милләт вәкилләре үз милли киемнәреннән килсә ничек матур буласын күз алдына китерәсезме?!


СПУТНИК
ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ОРГАН
ТАТАРСКОГО ОБЛАСТНОГО КОМИТЕТА ВКП (б)
№ 4—5

1926
«СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА» ЖУРНАЛЫ

1926 елның мартында «Причал»-ның исемен кабат алыштыралар.

Хәзер инде ул «Спутник партийного активиста» дип атала. ВКП (б) өлкә комитетының айлык теоретик һәм сәяси органы рус телендә төп-төгәл ун тапкыр чыга. «Спутник партийного активиста» белән бергә татар телендә партия өлкә комитетының «Җитәкче» журналын чыгара башлыйлар. Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр барысы 139 сан чыгып кала.

МӨХӘРРИР

Мендель Хатаевич

Мендель Хатаевич журналның җаваплы – баш дип укы! – мөхәррире генә түгел, бер үк вакытта ВКП (б) ның Татарстан өлкә комитетының җаваплы – баш дип укы! – секретаре да булган. Әлеге яшь, тынгысыз большевикны яшь Татар республикасы белән командалык итәр өчен Самарадан җибәрәләр. Нәкъ менә шунда, Валериан Куйбышев белән иңгә-иң торып революция өчен көрәшкәндә, ул кыю чыгышлары белән таныла.

«Эшче оппозиция»гә каршы үзенең төп сүз сугышын ярлы гаиләсеннән чыккан, бары тик башлангыч яһүд мәктәбен генә тәмамлаган Мендель Хатаевич 1921 елның 2 февралендә Самарада гомумшәһәр партия җыелышында ачкандыр. Ул Ленинның профсоюзлар турындагы тезисларын яклап сүз ала һәм, бөтен кешене шаккатырып, танылган оратор Лев Троцкийны «тар-мар итә».

Журналистикага мәхәббәт белән Мендельдә 13 яшендә үк уяна – ул газеталар таратып, ипилек акча эшли. Ә 1911 елда туган шәһәре Гомельдә хәтта үзенең газета киоскысын ача, соңрак үз киоскысы аша большевикларга легаль булмаган газеталар таратырга да булыша.

Революцион тормыш Мендельне чыныктыра. Кулга алулар, сорау алулар, кыйнаулар, Себергә сөрелүләр, могҗиза белән генә «үлем поезды»ннан котылып калу... 1925 елда ТАССРга ул мондый характеристика белән килә: «Үзен алдан күрүчән һәм зирәк җитәкче итеп күрсәтте».

Аның 1931 елның апрелендә иптәш Сталинга язган хаты саклан-ган: «Нервлар хисабына, бернинди көчне дә кызганмыйча, гаять зур киеренкелек белән эшләргә туры килә. Мин шәхсән үземнең үткәннәрем белән... партия мәнфәгатьләрендә һәм аның беренче боерыгы буенча... теләсә кайсы мизгелдә үземнең тормышымны бирергә тулысынча әзер булуымны расладым».

Һәм ул үзенең тормышын партия боерыгы буенча бирә дә – 1937 елның 9 июлендә Хатаевичны, «контрреволюцион террористик оешмада катнашу»да гаепләп, кулга алалар һәм иң югары җәзага хөкем итәләр.

1937 елның 27 октябрендә атып үтерелә. Аңа ул чакта 44 яшь була.
1956 елның февралендә (үлеменнән соң) аклана.

АЗРАК КЫНА ТАТАР?

Автор: Нияз Әхмәдуллин

«Үсә баручы совет хуҗалык төзелешендә тулы бер чаралар, халык хуҗалыгында баланс булдыру өчен... статистика мәгълүматлары кирәк. Шундый мәгълүматларның берсе – халык санын алу», – дип яза 1926 елгы Бөтенсоюз халык санын алу турында «Спутник партийного активиста» дип атала башлаган журналыбыз. Без дә әлеге проблеманы күтәреп, билгеле сәбәпләр аркасында, 2021 елның апрель аена күчерелгән Бөтенроссия халык санын исәпкә алу турында язарга уйладык.

Бу турыда сәясәтчеләр һәм галимнәр, төбәк җитәкчеләре һәм милли активистлар берничә ел элек сөйләшә башлады. Россиялеләрнең милли үзбилгеләнешенә кагылышлы мәсьәлә аеруча зур кызыксыну уята. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та үзенең ТР Дәүләт Советына еллык Юлламасында халык исәбен алуның әһәмиятен билгеләп үтте: «Халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре икътисад, демография, социаль өлкәдә стратегик планлаштыру өчен генә түгел, һәр милләт өчен дә бик мөһим».

Президентның «һәр милләт өчен» дип басым ясавы мөһим. Россия Федерациясенең күпмилләтле субъектларының берсе булган Татарстан өчен бу, һәрхәлдә, шулай. Күрәсең, 2021 елны Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан иткәндә дә әлеге фактор хәлиткеч дәлилләрнең берсе булгандыр.

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан



Всесоюзная демографическая перепись 1926 года

Зачем нужна перепись

Многие важнейшие вопросы в области советского строительства требуют обширных статистических данных, не могут быть правильно разрешены без точных сведений о населении. Есть ли в настоящий момент такие данные? Есть, но они не соответствуют действительному состоянию вследствие глубоких сдвигов, происшедших в населении за последние годы революции. В настоящее время население по Союзу исчисляется с ошибкой в 5—10% в ту или другую сторону, а по отдельным районам этот процент достигает еще большего размера. При таком положении вещей вполне естественно, что ряд работ по выявлению экономической и социальной жизни нашей страны теряет свою ценность, делает выводы подчас неверными.

ПАНДЕМИЯ ЙОГЫНТЫСЫ

Иң яңа Россия тарихында өченчесе булган гомуми исәпкә алу 2020 елның көзендә узарга тиеш иде (моңа кадәр ул 2002 һәм 2010 елларда үткәрелде). Әмма коронавирус пандемиясе үз төзәтмәләрен кертте, халык санын исәпкә алу 2021 елның апреленә күчерелде. Шул ук вакытта, Росстат мәгълүматларына караганда, вакыт күчерелү чарада катнашучыларның куркынычсызлыгы турында кайгырту белән генә бәйле түгел, ә язгы карантин аркасында, оештыру ягыннан әзерлек җитмәүдә дә. «Халык санын исәпкә алуны, беренче чиратта, безнең өчен экипировка, планшетлар ясаучы заводларның карантин вакытына эшчәнлеге туктатылып торуы сәбәпле күчердек», – дип сөйләде Росстат җитәкчесе урынбасары Павел Смелов.

2021 елгы халык санын алу тулы мәгънәсендә инновацион булачак. Россиялеләр бу юлы гадәти исәпкә алу кәгазьләрен күрмәячәк (алар сирәк очракларда гына кулланылыр дип ниятләнелә). Барысы да цифрлы чорга хас шартларда оештырыла: исәпкә алучыларның һәрберсе планшет белән йөри, гражданнар әйткән мәгълүмат урында ук теркәлеп бара. Исәпкә алучылар белән турыдан-туры аралашырга теләмәүчеләр, өйдән торып кына яки күпфункцияле үзәкләргә мөрәҗәгать итеп, «Госуслуги РФ» сайтында анкеталарны мөстәкыйль рәвештә тутыра ала. Исәпкә алучыларны өйләренә кертергә, шулай ук анкеталарны үзлектән тутырырга теләге булмаган ватандашларыбыз өчен дә шартлар тудырылган. Әлеге категория гражданнарга махсус исәпкә алу участоклары оештырылачак.

ЯҢАЛЫКЛАР ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘР

Халык санын алу эшендә төп нигезне моңа кадәр бирелгән традицион сораулар тәшкил итә. Нәкъ менә фундаменттагы үзгәрешләрне ачыклау, ягъни чагыштырмача анализ үткәрү, озак вакытлы тенденцияләрне билгеләү өчен традицион сораулар (җенес, яшь, милләт, туган тел, гражданлык һ.б.) халык санын алу вакытларында кабатланырга тиеш тә инде. Ләкин, Росстатта аңлатуларынча, кайчагында гаилә хәле турындагы, беренче карашка, төгәл куелган сорауга ир-атлар һәм хатын-кызлар төрлечә җавап бирә. Мисал өчен, ир белән хатын гражданлык никахы белән бергә яши, уртак балалар үстерә, ди. Бу вакытта хатын үзен никахта дип исәпли, ә ир-ат, киресенчә: «Паспортта штамп юк, мин ирекле кеше», – дип саный. Шул рәвешле, халык санын алу нәтиҗәләре буенча да «өйләнгән» ир-атлар саны кияүдәге хатын-кызларныкына караганда кимрәк булып чыгарга мөмкин. Россиядәге үзбилгеләнүнең кырыс чынбарлыгы әнә шундый.

Традицион сораулар белән беррәттән, заман таләп иткән сораулар да биреләчәк. Шулай итеп, яшәү өчен акча чыганаклары турындагы сорауга «хезмәт хакы», «эшмәкәрлек кереме, үзмәшгульлек» кебек җавап вариантлары кертелгән. Халык санын алу барышында гражданнарга рус һәм башка телләрне белү турында гына түгел, ә аларны көндәлек тормышта куллануга кагылышлы сорауга да җавап бирергә туры киләчәк.

ТАТАРЛАР ИНГЛИЗЧӘ КИТӘ

Татарларга һәм Татарстанга карата шуны әйтергә мөмкин: үткәрелгән соңгы өч халык исәбен алу нәтиҗәләре татарлар саны, аерым алганда, татар телен белә торган татарлар санының кимүе динамикасын күрсәтә. Фактлар үҗәт: алар декларация һәм чынбарлыкны үз урыннарына куя.



Халык санын алуның соңгы өчесен алып карыйк: 1989 елдагы соңгы совет чоры, 2002 һәм 2010 елларның ике гомумроссия исәп алуларын.

1989 елда РСФСРдагы татарлар саны – 5 520 000, 2002 елда – 5 550 000 кеше, шулардан 4 880 000 кеше туган телен белүен күрсәткән (ягъни 670 мең татар үз телен белмәгән). 2010 елдан җан исәбен алу Россиядә 5 310 649 татар яшәвен ачыклаган (татарлар саны 240 меңгә кимегән), алар арасында 4 280 718 кеше татар телен белүен әйткән. Миллионнан артык татар үз телен югалткан дигән сүз. Саубуллашмыйча гына, инглизчә китү бу.

Бу урында ике нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Бер яктан, туучылар санының уңай динамикасы шартларында татарларның абсолют саны кимүе күзәтелә. Димәк, татарлар саны киму тискәре табигый үсеш нәтиҗәләренә бәйле түгел. Белгечләр бу процесска тәэсир итүче факторлар арасында көчәя баручы ассимиляцияне, шулай ук статистика аномалияләрен аерып күрсәтә. Әйтик, 2002 елда Башкортостанда татарлар саны берьюлы 130 меңгә кимегән, ә башкортлар саны, 1989 ел белән чагыштырганда, 350 мең кешегә арткан. Алда торган халык санын алу нәтиҗәләре төгәлрәк булыр һәм янә ышаныч уятыр, дип өметләнәсе генә кала. Ике республиканың җитәкчелеге арасында ныгый барган үзара аңлашу безгә моңа исәп тотарга мөмкинлек бирә.

Тагын бер мөһим фактор – исәп алу кәгазьләрендә татарларның ясалма критерийлар нигезендә вак этноконфессиональ һәм этномәдәни төркемнәргә бүленүе. Бу процессның инициаторы буларак Россия Фәннәр академиясенең Антропология институты директоры Валерий Тишков чыгыш ясаган иде. Татарстан җитәкчелеге һәм республиканың әйдәп баручы галимнәре мондый алымны берничә тапкыр тәнкыйтьләп чыкты. Керәшеннәр, мишәрләр, әстерхан, касыйм, себер татарларын аерым халыклар итеп бүлгәләү, башка төркемнәр тирәсендә дискуссияләр оештыру татар халкының аерым вәкилләре арасында аңлашылмаучанлык тудырды.

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан

Бу юлы халык санын алу өчен сораулар төзегәндә тирәнрәк уйлап эш йөрткәннәр, күрәсең. Валерий Тишков узган елның җәендә Казанда булганда үз фикерен болай аңлатты: «Кемдер үзе турында татар дип кенә әйтә. Икенче берсе, мәсәлән, үзен «казанлы», өченчесе – «казан татары», «себер татары» яки «керәшен», дип атарга теләр. Әмма барлык бу җавапларны да берләштерәчәкләр. Халык төркемнәре булачак. Мәсәлән, помор һәм казаклар рус төркемнәре итеп теркәләчәк, керәшеннәр дә, шул рәвешле, татар төркеме буларак исәпкә алыначак. Ләкин нагайбәкләр аерым кече халык дип санала, алар төп халык булып кала да».

Агымдагы ел башында ТР Дәүләт Советы спикеры Фәрит Мөхәммәтшин да халык санын алу өчен биреләчәк сорауларның төгәлрәк булуы белән килеште: «Мин сораштыру битен карап чыктым. Хәзер тәкъдим ителгән документлар безне канәгатьләндерә. Алардан пенза, түмән, мишәр, типтәр татарлары төшереп калдырылган». Аның сүзләренә караганда, Татарстан гозере буенча сораштыру битендә милләтне күрсәтүче графа гадиләштерелгән: «Үз

Национальный момент в предстоящей переписи

Вопрос „о национальности“, который значится в формуляре данной переписи, даст возможность при разработке его получить прежде всего числовое выражение отдельных народностей, а в соединении с вопросом „грамотность“, „профессия и занятие“, „физическое состояние“ и др. мы получаем такие цифры, которые будут иметь доминирующее значение при решении всех экономических и культурно-политических вопросов в национальном разрезе. Эти цифры, следовательно, имеют огромное значение в наших условиях, так как национальный вопрос в его практическом разрешении занимает одно из первых мест в совстроительстве.

Известно, что народности, населяющие СССР, при царском строе всегда обслуживались в меньших размерах как в области просвещения, так и в области хозяйственного строительства. Достаточно будет привести следующие цифры, характеризующие жизнь татар при царском строе, цифры, говорящие гораздо убедительней, чем много слов, о том, как „заботились“ о татарах при царском строе.

милләтеңне сайлап аласың, үзеңне кем дип саныйсың, туганда кем булгансың – рус, мордва, чуваш, татармы. Минемчә, бу халыкның милләт, яшь һәм гаилә хәле буенча санын билгеләгәндә тагын да объективрак булырга мөмкинлек бирәчәк».

Башка тискәре тенденциягә йогынты ясау билгеле бер сәбәпләр аркасында күпкә катлаулырак. Татар телен белгән татарлар санының куркыныч масштабларда кимүен халыкның үзаңына мөрәҗәгать итү, «үзеңне татар итеп тоярга» кебек өндәмәләр белән генә туктатып булмый. Федераль дәрәҗәдә дә, Татарстанда да җитди чаралар күрергә кирәклеге аңлашыла.

Соңгы халык санын алу нәтиҗәләре күрсәткәнчә, 2010 елда Россия буенча татар телен белү дәрәҗәсе уртача 80% тәшкил иткән, ә Татарстан һәм Башкортостанны исәпкә алмасаң, бу күрсәткеч – 54,7%. Белгечләр фаразларына караганда, мондый тенденцияләр сакланып калганда, югарыда аталган ике республикадан читтә яшәп, телне белүчеләр бөтен татар халкының өчтән бер өлешеннән дә кимрәк булырга мөмкин. Шул ук вакытта, татар телен белүен күрсәткән кешеләр арасында да аны куллану дәрәҗәсе шик тудыра.

АЗ ГЫНА ИСӘПКӘ АЛЫНМЫЙ

Узган ел Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты фәнни җитәкчесе Валерий Тишков «татар-башкортлар» дигән яңа этник төркем кертергә тәкъдим иткән иде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу инициативага болайрак җавап бирде: «Минем фикерем: бераз украиналы, бераз рус булып язылу дөрес түгел. Кеше үзен украин, рус, башкорт яки татар итеп тоярга тиеш. Билгеләнергә кирәк».

Катнаш гаиләләрдә туган һәм яши торган кешеләрнең үзбилгеләнеше белән бәйле катлаулы вазгыятькә җавап биреп, Татарстан вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразыев Россия төбәкләрендәге, бигрәк тә катнаш гаиләләрдә яшәүче татарлар өчен: «Халык санын алу барышында безне ничек язарлар, ә балаларны ничек язарга?» дигән сорауның актуаль булуын таныды.

– Без аларның һәркайсын ишетергә һәм һәр татарның исәпкә алынуына ирешергә тиеш, – диде Конгресс җитәкчесе.

Бөтендөнья татар конгрессы, үз позициясен ныгытып, милләтләре «дөрес күрсәтелмәгән» татарларның мәнфәгатьләрен судларда яклау өчен Татарстанда юридик үзәк төзү турында Казанның Sergis адвокатлар коллегиясе белән килешүгә кул кую инициативасы белән чыкты.

Sergis җитәкчесе Гөлнара Сергеева фикеренчә, эш консультацияләр белән генә чикләнәчәк. Тик, кирәк булса, юристлар судларда да эшләргә әзер. «Безнең бурыч – гражданнарның хокуклары бозылуына юл куймау», – дип аңлатты ул адвокатлар коллегиясе ролен. Татарларның бөтен ил буенча таралып яшәүләрен исәпкә алсак, юридик үзәк «барлык төбәкләрдәге татарлар белән эшләргә» ниятли. Шул ук вакытта консультацияләр түләүсез нигездә оештырыла.

Халык санын алу барышы юристлар ярдәменең ни дәрәҗәдә кирәк булуын күрсәтәчәк. Әмма шунысы мөһим: БТК Татарстаннан читтә яшәүче татарларның да хокукларын яклау ниятен раслаучы актуаль инициатива белән чыкты.

Озак калмады, илнең һәр гражданинына үзбилгеләнергә туры киләчәк. Халык санын алу битләрендә милләткә кагылышлы сорауга җавап ачык калган, монда мөмкин булган җавап вариантлары юк. Исәпкә алу кәгазендә респондент күрсәткән милләт теркәлә. Халык санын алу эше башланганчы, Татарстанга илнең төрле төбәкләрендә яшәүче татарлар белән диалогны дәвам итү, аларга үз позициясе турында мәгълүмат җиткерү бик мөһим. Әгәр халык санының киләчәктә кимүенә юл куймасак, телне ничек саклап калу һәм яңадан торгызу турында уй-фикерләребез тагын да нигезлерәк булыр, мөгаен.

СҮЗ УҢАЕННАН

Халык санын алуда катнашу – ирекле һәм аноним эш, аннан баш тарткан өчен бернинди санкцияләр дә каралмаган. Дәүләт тарафыннан алып барыла торган статистика җыюның башка формаларыннан (салым хезмәтләре, Эчке эшләр министрлыгы, ЗАГС органнары) халык санын алу шундый ирекле булуы белән аерылып тора.

ФИЗИКА ҺӘМ ЛИРИКА

Теләсә кайсы җитди эш артына тере кеше эмоцияләре яшеренгән. Халык санын алу – коры статистика мәгълүматларын җыю гына түгел. Халык санын алуны популярлаштыручы һәм ил алдында торган проблемаларны тирәнтен аңлап, халык уй-фикерләрен оста итеп такмакларга сала:

«Жду я переписи сроков,
чтоб в анкете написать:
Пусть нагонят эфиопов –
будем Пушкиных рожать!»

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан

1932

«ТАТАРСТАН БОЛЬШЕВИГЫ» («БОЛЬШЕВИК ТАТАРИИ») ЖУРНАЛЫ

1932 елда «Җитәкче» журналының татарча версиясе «Татарстан большевигы» дип үзгәртелә. Ә «Спутник партийного активиста»ның исеме «Большевик Татарии»га алыштырыла. 3000 тиражлы «Большевик Татарии» ВКП (б) Татар өлкә комитетының төп журналына әверелә, һәм ул җирле партия комитетларының, аеруча беренчел оешмаларның эш тәҗрибәсен гомумиләштерергә һәм киң яктыртырга тиеш була. Шушы исем белән ул 1941 елга кадәр чыга.

МӨХӘРРИРЛӘР

Гасым Мансуров

«Татарстан большевигы»на беркадәр вакыт ВКП (б) Татар өлкә комитетының икенче секретаре Барый Абдуллович Абдуллин җитәкчелек итә. Ул Татар өлкә комитетының элекке агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире Миңгәрәй Сәгыйдуллинга каршы җимергеч мәкалә язган автор буларак билгеле. Күпмедер вакыттан соң Сәгыйдуллин утырган төрмәгә, шул ук камерага Барый Абдуллин үзе дә барып эләгә. Аларның очрашуын Евгения Гинзбург үзенең танылган «Крутой маршрут» китабында тасвирлый.

Барый Абдуллинга куелган гаепләү сәбәбе оригинальлеге белән аерылып тормый: «Татар АССРда контрреволюцион троцкийчыл милләтчелек оешмасына җитәкчелек итү һәм идеология фронтында һәм авыл хуҗалыгында зыян китерү».

1937 елның 3 августында атып үтерелә. Аңа 38 яшь була.
1957 елның 1 августында (үлеменнән соң) аклана.

Зәки Гыймранов

1934 елдан 1936 елга кадәр «Татарстан большевигы»на Зәки Закирович Гыймранов җитәкчелек итә. Аңа кадәр ул Казан коммуналь төзелеш инженерлары институты директоры булып эшли. 1936 елда аны соңыннан «сәгыйдуллинчылык» дип исемләнәчәк сул милләтчелек төркемен оештыруда гаеплиләр. Гаепләү карарында Гыймранов 1922 елдан 1928 елга кадәр Татар өлкә партоешмасы җитәкчелегенә каршы актив көрәш алып барган, дип белдерелә.

1937 елның 3 августында атып үтерелә. Аңа 39 яшь була.
1957 елның 1 августында (үлеменнән соң) аклана.



Лазарь Пинхасик

Лазарь Соломонович Пинхасик турындагы истәлекләр, күрәсең, 1937 елның июль аена кадәр үзе җитәкчелек иткән «Татарстан большевигы» журналында – үз кулы белән язып бастырган мәкаләләрендә генә сакланып калгандыр. Һәм тагын… «СССРдагы сәяси террор корбаннарының ачык исемлегендә».

Лазарь Пинхасик бик күп, еш һәм бары тик партия таләп иткәнне генә яза. Ул чын мәгънәсендә үлгәнчегә кадәр аңа тугры була. 1937 елда Пинхасик исеме беркемгә билгесез рәвештә журнал битләреннән юкка чыга һәм шуннан соң беркайчан да беркайда да күренми.

1938 елның 9 маенда атып үтерелә. Аңа 35 яшь була.
1956 елның 28 апрелендә (үлеменнән соң) аклана.

Атылган кешеләрне яшерен генә Архангел зиратына күмгәннәр.

Фото: Александр Ефремов

КАРГЫШЛЫ ЕЛЛАР

Автор: Алсу Троицкая

1932 елда «Татарстан большевигы» дип атала башлаган журналда шул чорларда башланган репрессияләр турында материаллар киң чагылыш тапкан. «Халык дошманнарының» нәрсәдә гаепләнүләре, исем-фамилияләре һ.б.лар басылган. «Татарстан» журналы сезгә 1937-1938 елларның зур террор урыннары буйлап яд итү экскурсиясе тәкъдим итә...

«Һәркайсыбызның бу дөньяда шундый урыннары бар...» – дип яза шагыйрь. Уйлар диңгезенә чума торган урыннар. Күп-күп еллар узгач та: «Ни өчен?» – дип ялварачак затлар хакында уйлана торган урыннар...

БЕРЕНЧЕ ТУКТАЛЫШ. КАЗАН «ЛУБЯНКА»СЫ

Казанның «Черек күл» паркындагы шугалак. Гамьсез балалар бозда шуа. Ә янәшәдә генә, каршы якта, бүген дә салкынлык бөркелгән бина тора. 1930 нчы елларда анда НКВД идарәсе урнашкан була. Аның тәрәзәләрен күзәтәм. 1937 елның февралендә кулга алынган Евгения Гинзбург шул тәрәзәләрнең берсеннән шугалакның бер почмагын күргән булса кирәк. Әлеге урыннан берничә йөз метр ераклыкта, Ленин бакчасында, сәяси репрессия корбаннарына хәзер тыйнак кына һәйкәл куелган. Анда нибары бер сүз чокып язылган: «Кичер...»

ТӘМУГКА РӘХИМ ИТЕГЕЗ

1937 елда бу шугалак манзарасы Евгения Гинзбургның котын ала. Үзенең «Крутой маршрут. Хроника времён личности» китабында ул соңыннан болай дип язачак:

«Черек күлдәге подвал. Бу сүзләр котны очыра иде. Һәм менә мине конвойчы шул подвалга озата бара. Ничә басма төшәсе иде? Йөзме? Меңме? Хәтерләмим. Баскычның һәр басмасы йөрәкне кысып куйганы гына исемдә, шул вакыт башыма кызык бер уй килә: тормышта уйлап та тормыйча, «тәмуг» сүзен еш әйткәләгән, ә хәзер, үлгәннән соң, җәһәннәмне үз күзләре белән күрергә тиеш гөнаһлы бәндәләр дә менә шундый хис кичерәдер...»

«ҮЗ ТӨРМӘҢДӘ»

Кулга алынып бер атна узгач, Гинзбург бер бүлмәдәге көзгеле киң тәрәзәдән Черек күл шугалагын күреп ала: «...Бу манзарадан аерыла алмыйча, мин бер мизгелгә тораташ калам. Дөньяда мондый нәрсә була ала микәнни? Бастырып җәзалау өчен карцерлары, мине көн саен куркыта торган «махсус ысуллары» булган шушы дөньяда?..

Кинәт тыштан «бәрхет» баритонлы тавыш яңгырый:

– Матур, әйеме?

Бары шулчак кына мин ян тәрәзә янында базык кына гәүдәле хәрбине күрем алам.

– Бүген бәйрәм, Кызыл Армия көне. Тимераякта шуучыларның зур ярышы, – дип аңлата ул шундый тыныч тавыш белән, әйтерсең, бергәләп табында чәйләп утырабыз. Аннары исә бөтенләй җылы, якын итеп өстәп куя: «Сезнең олы балаларыгыз да, мөгаен, мондадыр? Алеша һәм Майя... Алар тимераякта шуадыр бит?»



Галлюцинация түгелме бу? Балаларымның исемнәрен кем телгә алды? Һәм мин түзеп тора алмадым. Алар минем күз яшьләремне күрмәячәк, дип үз-үземә ничә мәртәбә ант иткән идем. Әмма бу юлы көтелмәгән яктан китереп суктылар. Яшьләрем елга булып ага...

Майор Ельшин илһамланып китеп, ун минут чамасына сузылган нотык сөйләп җибәрә. Чыгышының төп мәгънәсе шуннан гыйбарәт: үз-үземне тотышым дөрес түгел икән. Син бит, янәсе, гестапога эләкмәгән. Горур калып дәшмәү, беркетмәгә кул куюдан баш тарту, җинаятьтәшләреңнең исемнәрен әйтергә теләмәү әнә шунда урынлы булыр иде. Ә монда бит син үз төрмәңдә...»



Хөкем ителүчеләрне Черек күлдәге НКВДның эчке төрмәсе ишегалды янәшәсендәге махсус бинада атып үтергәннәр.

Ровель Кәшәпов, Федераль куркынычсызлык хезмәте музее директоры:

– Мәскәүлеләр өчен «Лубянка» нинди мәгънә йөртсә, 30 нчы елларда ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты (НКВД) идарәсе паркка күчкәч, Черек күл дә казанлылар өчен шундый яңгыраш ала. Массакүләм кулга алулар котылгысыз рәвештә массакүләм җәзалауларга китерә. Ул вакытта тоткыннар Черек күлдәге НКВДның эчке төрмәсендә тотыла. 2005 елга кадәр бу бина РФ Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе архивы өчен файдаланылды. 2014 елда Татарстанның Эчке эшләр министрлыгы карамагына тапшырганнан соң, әлеге бина җимерелде. Хөкем ителүчеләрне шунда ук, эчке төрмә ишегалды янәшәсендәге махсус бинада атып үтергәннәр. Атып үтерү эшен комендант җитәкчелегендәге 3-4 кешедән гыйбарәт махсус команда башкарган. Мәетләр төнлә ябык автомобильдә эчке төрмә капкасы аша чыгарылган. Аларны яшерен рәвештә Архангел зиратында җирләгәннәр. Зиратның штаттагы кабер казучылары, сер саклау турында кәгазь имзалап, алдан ук уртак каберлекләр казып куя торган булган. 80 нче еллар ахырында ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының тикшерү бүлекчәсе, шаһитлардан сораштыру юлы белән, шул елларда атып үтерелгән тоткыннарның күмелү урынын ачыклый.



Боевая перестройка партийной работы

...Мы имеем много фактов зажима самокритики, а к чему это пр[illegible] водит, видно на примере городской партийной организации. Гор[illegible] [illegible] работал оторванно от партийных организаций. „Правда" со[illegible] [illegible]шенно правильно писала о бюрократическом стиле руководства [illegible]анского горкома партии.

[illegible] самокритики мы имели в горкоме самоуспокоенность и [illegible]одушие. В результате в бюро горкома пробрались враги народа— [illegible]тагиров и Гацеев, членом бюро горкома был также забюрокра[illegible] [illegible]ся председатель горсовета Аксенов, защищавший активную [illegible]трреволюционерку Гинзбург. А горком партии за декларациями [illegible] благополучии не сумел разглядеть и разоблачить вреди[illegible] [illegible], троцкистов, правых, контрреволюционных националистов, [illegible]бравшихся на предприятия, в учреждения и в учебные заведения.

барыгызга да сәлам әйткән!» – дип әйтеп сала. Кем әләкләгәне билгесез, тик шунысы хак: 14 елдан соң, куркыныч 1937 елда, «халык дошманы» белән бу әлемтәсен Тинчуринның исенә төшерәләр һәм, шуңа өстәп, Япония файдасына шпионажда гаепләләр. Ни өчен нәкъ менә Япония? Чөнки ул вакытта Исхакый «кояш чыгышы иле»ндә яшәгән.

Кулга алганнан соң, ел буе Кәрим Тинчуриннан гаебен танытырга тырышалар, ләкин әдипне сындыра-бөгә алмыйлар...

Хакимиятнең әхлаксызлыгы чик-чама белми: «халык дошманы»ның хатыны Заһидә Тинчурина ирен тоткынлыктан азат итү өчен көрәшә, 1938 елның 15 ноябренә каршы төндә атып үтерелгән башка кешеләр белән бергә иренең дә Архангел зираты почмагындагы уртак чокырга ташланганлыгын белми дә кала ул. Күренекле режиссерның төгәл үлем көне күп еллар узгач кына билгеле булды.

ИКЕНЧЕ ТУКТАЛЫШ. АРХАНГЕЛ КАБЕРСТАНЫ ЧОКЫРЛАРЫ

Архангел зираты Даурия һәм Һади Такташ урамнары чатында урнашкан. Капка төбендә үк диярлек уң якта зур таш тора. Анда: «Сәяси репрессияләр елларында атып үтерелгәннәр истәлегенә. Мәңгелек хәтер!» Күз чагылырдай ап-ак карда – җете кызыл канәферләр. Исемлекне укыйм: исеме, фамилиясе, туган елы һәм үлем көне. Стелаларның берсендә таныш исемне табам: Тинчурин К. А. 1887–15.11.1938.

Тирә-якта караңгы, һичкем күренми. Мондагы кәшәнә янына киләм. Аның кечкенә бурасы үзәк аллеядан күренеп тора. 2007 елның февраленнән Архангел зиратында туганнары һәм якыннары җирләнгән казанлылар биредә мәңгелек йокыга талганнар рухына панихида уздыруга заказ бирә ала...

Анатолий Елдашев, туган як тарихын өйрәнүче:

– Бу иске шәһәр каберлеге, 1918 елдан башлап, Казанда сәяси репрессия корбаннарын җирләү өчен, хакимият тарафыннан рәсми төстә танылган урын булып тора. «Мемориал» иҗтимагый оешмасы тарафыннан 1998 елда монда 10 стела урнаштырыла, аларда 1929 елдан 1943 елга кадәр атып үтерелгән 2743 кешенең исеме язылган. Өч тапкыр күбрәк кеше исә лагерьларга җибәрелгән.

КӘРИМ ТИНЧУРИН

Татар театрына һәм драматургиясенә нигез салучы дип саналган режиссер өчен 1938 ел 1924 елда ук башлана. Ул чакта Кәрим Тинчуринны, Казанда «театр эше канәгатьләнмәслек булганга күрә», эштән читләштерәләр. Хакимият режиссердан Гаяз Исхакыйдан килгән хат өчен әнә шул рәвешле үч ала.

– 1923 елда Берлиннан Казанга бандероль килә. Адресаты – Кәрим Тинчурин, – дип сөйли театр тәнкыйтьчесе Нияз Игламов. – Конвертта тюркология җәмгыяте журналы, ә анда – Исхакыйның яңа пьесасы, кызы турында кайгырткан өчен рәхмәт хаты да бар. Тинчурин дустыннан килгән бу хәбәрне яшерми. Театрга килгәч: «Гаяз абый

ӨЧЕНЧЕ ТУКТАЛЫШ. ЧИСТАЙ? ЧИСТАРТУ УРЫНЫ...

Юлыбыз Чистайга китерде, Карл Маркс һәм Фрунзе урамнары чатында торабыз. Биредә, йөзләгән «халык дошманы» өчен соңгы сыену урынына әверелгән Авдеев зиратында, тып-тын. Ал гранит ташның уртасыннан зур хач калкып чыккан һәм чәчәкләр ята. Бу – сәяси репрессияләр корбаннары истәлегенә куелган мемориаль комплекс.

«Халык дошманнары»н атып үтерү урынына – бүген 5 нче тикшерү изоляторы урнашкан Карл Либкнехт урамы, 1 В адреслы бинага кадәр җәяүләп атлыйбыз. Ерак ара түгел. Чистай төрмәсе диварлары янында басып тору да җанны өшетә, үзеңне, әйтерсең, мәетләр дөньясына әләккәндәй хис итәсең...

Чистай төрмәсе.

Авдей каберлеге.

ЯЗЫШУ ХОКУКЫННАН МӘХРҮМ. МӘҢГЕГӘ

Борис Пастернак мемориаль музееның өлкән фәнни хезмәткәре Рафаил Хисамов сөйли:

– Чистайда атып үтерү процедурасы мөмкин кадәр гадиләштерелә. Чистай төрмәсенең подвал бүлмәсендә идәнгә көрән таплар белән чуарланган брезент җәелә, аннан бераз түрдәрәк тоткынны пулялар чокып бетергән диварга каратып бастыралар, аяк астында – аккан канны җыеп алу өчен пычкы чүбе. Үлемгә хөкем ителгәннәрне, җәза подвалына кертканче, эчке киемгә кадәр чишенергә мәҗбүр итәләр. Атылган тоткыннарның өске киеменә кызыгучылар күп була... Шундый очрак мәгълүм: бер репрессияләнгән кешенең хатыны төрмә хезмәткәрендә иренең кыска тунын танып алган. Бу хатын иренең язмышы турында белергә теләп, әлеге хезмәткәргә ташлана, ә ул исә, күккә ымлый да, оялып-нитеп тормыйча, турыдан ярып сала: «Тавыш чыгарсаң, син дә аның янына олагырсың».

БЕР ЯРЫМ ЯВЫЗ

Ул куркыныч вакыйгаларның бер шаһиты искә алганча, эш тәртибе болайрак була: «Без баш артына, түбә өлешенә тидерергә тырышып ата идек. Әгәр төз атылган икән, үле гәүдә бер тиюдә үк йөзтүбән яки ян якка егыла. Әмма бик тәҗрибәле һәм корыч нервлы кешеләр генә болай атарга сәләтле булды...»

Мәетләрне күмү урынына илтү өчен, төрмәнең иң кара йөзле надзирательләреннән берсе – үз эшенең алыштыргысыз «остасы», «Бер ярым Иван» кушаматлы Авдей билгеләнгән. Зур гәүдәле әзмәвер бик аз сөйләшкән, аны телсез кеше дип уйлаганнар. Ул үзе белән штык куелган бик борынгы «берданка» винтовкасы йөрткән. Бу мылтык атмаган, әмма штык бик яхшы үткенләнгән булган. Алай-болай чокырдан ыңгырашкан тавыш ишетелсә, ул керосин лампасы яктысында мәетләр өстенә җиңел генә сикереп төшеп, кем булуына карап тормыйча, штык белән кадаган. Авдей бөтен тавышлар беткәч кенә тынычланган.

ДҮРТЕНЧЕ ТУКТАЛЫШ. ГУЛАГ УТРАВЫ

Зөя утрау-шәһәренә килеп җитәбез. Менә инде Успение Богородица монастыре да күренде. Өч өлештән торган тимер баскычлардан күтәрелгәч, без аның ак таш диварлары янына килеп чыгабыз. Иң әүвәл күзгә ташланган нәрсә – сәяси репрессия корбаннары истәлегенә куелган һәйкәл. Рәшәткә артында – күгәрчен очыручы тоткынның тетрәндергеч йөзе. Аның күзлек пыяласы артындагы күзләре бүгенге Зөянең кайчандыр куркыныч урын булуы турында уйланырга мәҗбүр итә...

УЯНЫРГА ЯЗМАГАН ЙОКЫ

«Төрмәгә утырткач, баштагы мәлдә бик куркыныч төш күрәсең кебек, ә син йолкып алынган тормыш чынбарлык булып тоела. Аннары (2–3 айдан соң) өйрәнеп китәсең һәм камера – коточкыч гомер сөреше урыны дип уйлый башлыйсың, ә ирек исә – хәтта тормыш күңелсезлекләре һәм ыгы-зыгысы да рәхәтлек китерә торган ниндидер әкияти төш булып тоела. Вак-төяк тормыш күңелсезлекләрен йөрәгеңә якын алма – төрмә турында хәтерлә».

Зөя тоткыны Владимир Голицынның хатыннан.

Рәссам Владимир Голицын – борынгы князь Голицыннар нәселе вәкиле, 1943 елның 6 февралендә Зөядә пеллаградан үлә. Бу хакта гаиләсенә аның ерак туганы, шунда ук тоткынлыкта тотылган Софья Олсуфьева хәбәр итә. Үлем турында язу тыелганга күрә, Елена Голицынага аталган хатында ул рәссамның үлеме турында болай дип хәбәр итә: «6 февральдә иртән аны, котмәгәндә, этап белән җибәрделәр, аның каравы ул хәзер әтисе белән бергә».


...когда руководящие органы оторваны от масс, когда к сигналам ...партийных и непартийных большевиков не прислушиваются, тогда ...этим пользуются.

...это видно хотя бы на таком примере. В Казанском государствен... педагогическом институте контрреволюционер Касымов вел ...тельскую работу. Коммунисты и беспартийные писали в райком ... безобразий, а Молотовский райком поручал расследовать ... факты... Касымову и потом даже не запрашивал подтвер... ...или не подтвердились эти факты. Удивительно ли, что при ... положении голос масс заглушался, а вредитель Касымов ...наказанно творил свое гнусное дело.

Софья Владимировна үзе Голицыннан соң бер ай гына яшәп кала һәм шушында, Зөядә үлә.

АЛТЫН ФОНДКА КЕРГӘН ШАГЫЙРЬ

Бөек татар шагыйре Хәсән Туфан исеме дә Зөя колониясе белән бәйле. 1942 елның 7 мартында ТАССРдагы НКВД хәрби трибуналы аны атып үтерергә хөкем итә, ике атнадан соң хөкем карарын ун ел лагерь җәзасына алыштыралар. Хәсән Туфан Зөя колониясеннән СССР Югары Советы Президиумына «Калган җәза срогын иректә үлем белән алыштыру турында ярлыкау үтенече» яза һәм үзен, гаебен кан белән «юар» өчен, фронтка җибәрүләрен сорый. 1950 елда җәза срогы тәмамланганнан соң, көтеп алынган ирек урынына Хәсән Туфан Новосибирск өлкәсенә мәңгелек сөргенгә озатыла. 1956 елның 9 апрелендә генә СССР Генераль прокуроры карары нигезендә шагыйрь азат ителә һәм аклана, Казанга кайта. Иҗаты татар шигъриятенең алтын фондына кергән шагыйрь аклануы турында үзе исән чакта ук белеп калган «бәхетле» кешеләрнең берсе була...



1983 елда Илларион Голицын һәм Михаил Трубецкой, туганнары Владимир Голицын һәм Софья Олсуфьеваның Зөя колониясендә газап чигүенә бер хәтернамә буларак, Успение монастыреның көнбатыш диварына ике истәлек тактасы урнаштыралар.

КЕШЕЛӘР

1937–1938 елларда Татарстанда НКВД сәяси гаепләүләр буенча гына да 2485 үлем хөкем карары чыгара, 400 дән артык кеше төрле категориядәге суд карарлары нигезендә җәзалана. Ә 1939–1940 елларда «халык дошманнары»на каршы көрәш турында Политбюро карарын үтәүчеләрнең үзләрен хөкем итәләр һәм атып үтерәләр.

Язмышның ачы көлүеме: 58 нче маддә буенча хөкем ителгән Евгения Гинзбург Магаданда «кайчандыр искиткеч шәп эшләгән майор Ельшин»га – үзен озак-озакка төрмә-лагерьлар газабына озаткан бәдбәхеткә бердәнбер икмәк паен бирә.

Әйе, күп кенә «сәяси тоткыннар», күп еллар тәмуг җәзалары кичерүгә карамастан, мәрхәмәтлелек һәм кешелеклелек хисен югалтмый. Кеше булып кала алар...

Зөядә өяз төрмәсе әле патша заманында ук булган. Успение монастыре территориясендә балигъ булмаганнар өчен 1920 ел ахырында колония-коммунаны оештыручылар әнә шуны истә тотып эшли. 1933 елда колония ябыла, аның мөлкәте ТАССР Эчке эшләр халык комиссариатының совхозын төзү өчен нигез булып тора. Зыянга эшләп килгән совхоз 1936 елда иң күбе 200 кешегә исәпләнгән авыл хуҗалыгы колониясенә әйләндерелә.

1937–1948 елларда Зөядә ТАССР Эчке эшләр халык комиссариатының төзәтү-хезмәт колониясе эшли. 1937 елның мартында аны сәнәгать колониясе разрядына күчерәләр һәм 8 нче номер бирәләр. Анда тире эшкәртү цехы ачыла. 1939 елдан колония 5 нче номерлыга әйләнә. Ике зона – ир-атлар һәм хатын-кызлар зоналарыннан гыйбарәт колониядә тоткыннарның чик саны өч йөз илле кеше тәшкил иткән. Монда, нигездә, РСФСР Җинаять кодексының 58 маддәсе буенча – «контрреволюцион эшчәнлек» өчен хөкем ителгәннәр эләгә. Тоткыннарның яшәү шартлары коточкыч. Колония эшләгән елларда биредә төрле хисаплар буенча берничә йөздән алып берничә меңгә кадәр тоткын үлгән.

Зөядә сәяси репрессия корбаннары истәлегенә урнаштырылган һәйкәл.

1958

«ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ» («КОММУНИСТ ТАТАРИИ») ЖУРНАЛЫ

Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы җимереклекләр чорында журналны чыгару тукталып тора. Ә 1958 елның гыйнварыннан татар һәм рус телләрендә «Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарии») исеме белән кабат чыга башлый. Хәзер инде ул КПССның Татарстан өлкә комитетының теоретик һәм сәяси журналы, аның битләрендә КПСС өлкә комитеты секретарьларының чыгышлары, коммунизм һәм социализм турында лекцияләр һәм консультацияләр, икътисад, сәясәт, тарих, мәгариф, әдәбият турында материаллар басыла. Аларның авторлары фән хезмәткәрләре, предприятие җитәкчеләре, җәмәгать активистлары була. Журналда укучылар хатлары да урын ала, алар арасында Бакый Урманче исеме дә бар. Әдәби әсәрләр басыла, әйтик, Туфан Миңнуллинның «Мин», Дж. Оруэллның «Милләтчелек турында язмалар»ы басылып чыга.

1977 елда «Коммунист Татарии» – «Татарстан коммунисты» журналы Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә.

МӨХӘРРИРЛӘР

Шәмси Хамматов

Шәмси Хәбибуллович Хамматов – 1958–1959 елларда яңа исем белән яңадан чыга башлаган «Татарстан коммунисты» журналының беренче җаваплы (баш) мөхәррире. «Матбугат – теләсә кайсы партиянең үткен идея коралы... «Татарстан коммунисты» журналы чыгу безнең илдә ленинчыл милли сәясәт тантана итүе күрсәткечләреннән берсе...», – дип яза беренче санда баш мөхәррир. Шәмси Хамматов 20 елдан артык Татарстан Журналистлар союзына җитәкчелек итә, Татарстан журналистикасының брендына әверелә. КФУда журналистика кафедрасы да аның инициативасы белән булдырыла.

Җәмил Гыйльманов

Җәмил Ибраһимович Гыйльманов «Татарстан коммунисты»на 1962 елдан 1964 елга кадәр җитәкчелек итә. Орден-медальләр белән бүләкләнгән фронтовик, абруйлы партия хезмәткәре. «Үз халкыма һәйкәл куярга телим», – дигәндә, ул «һәйкәл» итеп Татарстан кешеләренең Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары турында фундаменталь хезмәт булдыруны күздә тоткан.

Шәүкәт Вәлиев

18 ел буе «Татарстан коммунисты» җитәкчелегендә (1969–1987 еллар) Шәүкәт Мирсәяфович Вәлиев тора. Белеме буенча – юрист, профессиясе буенча – журналист, инануы буенча – коммунист. Аңа еш кына үз фикерен партия өлкә комитеты бюроларында, хәтта КПСС ҮКда да дәлилләргә туры килә. Үз вакытында ул, Үзәк комитет идеологларына саллы дәлилләр китереп, журналны чыгаруны дәвам итәргә кирәклеген раслый. Сүз уңаеннан, СССРдагы автономияле республикалар арасында – безнең журнал бердәнбер була.

Нәкъ менә журналга Шәүкәт Вәлиев җитәкчелек иткән чакта «Татарстан коммунисты» Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә. СССРның бөтен тарихы дәвамында бары 5 кенә журнал мондый бүләккә лаек була: «Вокруг света» (1982 ел), «Гражданская авиация» (1981 ел), «Дальний Восток» (1983 ел), Carelia (1978 ел), әмма «Татарстан коммунисты» аны беренче булып – 1977 елда ала.

Александр Афанасьев

Александр Иванович Афанасьев «Татарстан коммунисты» журналына 1987–1990 елларда җитәкчелек итә. Үзгәртеп кору чоры ул еллардагы язмаларда үз эзен калдыра: тизләнеш, хәбәрдарлык, хуҗалык исәбе, әчке партия дискуссияләре, репрессияләргә, тарихка һәм илнең киләчәгенә яңача караш. Катлаулы вакыт тәҗрибәле мөхәррирдән җитди тырышлык таләп итә: заманнан артта да калмаска, артык алга да чапмаска кирәк. Ни дисәң дә, журнал партия органы, ә совет чоры үтеп барган вакытта коммунистлар арасында чынбарлыкка төрлечә, кайчакта диаметраль капма-каршы фикерләр була.

Дамир Шәрәфетдинов

Дамир Рәүфович Шәрәфетдинов «Татарстан коммунисты» журналына озак җитәкчелек итми: 1990 елдан 1991 елга кадәр генә. Аның мөхәррирлеге иң давыллы елларга туры килә: 1991 елда, РСФСР Президенты карары белән тыелып, КПСС юкка чыга. Партия генәме, дөнья картасыннан Советлар Союзы да юк була. Шул ук вакытта яңа Россия, яңа Татарстан төзелә башлый. Әмма бу инде башка тарих, анысын инде яңа исем белән чыгучы журнал яктырта башлый.

«ПРОМЕТЕЙ» УТ ЭЗЛИ

Автор: Ксения Сёмина



Фото: Заманча сәнгать галереясының «ВКонтакте» челтәрендәге рәсми төркеме, ТР Президенты матбугат хезмәте

«Татарстан коммунисты» журналының эчтәлеге белән танышканда, сәяси юнәлешле басма булуына карамастан, аның күптөрле темаларны яктыртуына игътибар иттек, шул исәптән мәдәният турында да шактый кызыклы материаллар басылган анда. 1980 нче елның 7 нче санында Казанда яңа күргәзмәләр залы ачылу турында хәбәр ителә һәм әлеге залда рәссамнарның «Зур Идел» бишенче зона күргәзмәсе урнашуы турында языла. Хәзерге вакытта бу юнәлештә нәрсәләр эшләнә? Язмабыз шул хакта.

«Мин төсле күкнең сүрүен җиңдем, ертып алдым һәм барлыкка килгән капчыкка төсләрне салып, төенләп бәйләп куйдым. Йөзегез! Сезнең алда – иксез-чиксез ак упкын», – дип язган Казимир Малевич бер күргәзмәнең каталогына. Казандагы Заманча сәнгать галереясы шулай оештырылган ки, биредә хәтта менә шундый иҗади гыйбарәләр дә бер караудан аңлашыла торганга әйләнә.

ӨРӘКЛӘР ҺӘМ ХИСЛӘР ХАКЫНДА

Галерея чыгышы белән Казаннан булган Россия рәссамы Игорь Вулох күргәзмәсе белән моннан ике ел элек ачылган иде. Аның нонконформистик абстракт полотнолары мәйданчыкның төп идеяләреннән берсен чагылдыра: Татарстан белән бәйле сынлы сәнгатьне өйрәнү һәм тамашачыга ачу. Моның өчен бик күп төрле чаралар файдаланыла.

РАДУГА НАД «БОЛЬШОЙ ВОЛГОЙ»

В нынешнем году в культурной жизни Казани произошло большое событие — открылся новый выставочный зал — прекрасный белокаменный дворец искусств, построенный по проекту зодчих республики. Строгость очертаний, лаконизм, компактность, собранность формы отличают внешний облик этого здания. Оно своеобразно сочетает в себе остро выраженные черты современности, новаторские устремления передовой архитектурной мысли с романтическими отголосками прошлых исторических стилей. Разумно, гармонично организовано внутреннее пространство: широкий доступ света обеспечивает наилучшее восприятие произведений живописи, скульптуры, графики.

Былтыр декабрьдә галереяда «Мергасовский. Flashback» күргәзмәсе эшләде. 1928 елда төзелгән Мергасов йорты республика иҗат элитасының берничә буынын, шул исәптән рәссамнарны да сыендырган. Монда Магдалина Мавровская, Надир Әлмиев, Вячеслав Бибишев һәм аның карикатурачы «кардәшләре», Илгизәр Хәсәнов, Виктор Тимофеев яшәгән һәм иҗат иткән. Әлеге фонда иң кызыклы шәхесләрнең берсе – Казанның атаклы нонконформисты Алексей Аникеенок. Аның кояш һәм шатлык бөркегән картиналары күргәзмәнең нигезен тәшкил итә. Рәссамнар Лев Переулков, Ксюша Шачнева, Виктор Тимофеев һәм фотограф Тимур Һадиев Мергасов йортын үзләре күзаллаганча гәүдәләндерә. Анда табылган фототасмалар ярдәмендә Тимур Һадиев кайчандыр бу йортта яшәгән кешеләр образларын җанландырган фильм монтажлый. Лев Переулков, йорт фотосурәтләренә абстракцияләр салып, Казанның күп кенә данлыклы конструктивистлар өчен илһам алу урыны булуын искә төшерә.

Мергасов йортына багышланган күргәзмәдән соң галереяда «Шум города kzn» экспозициясе урын ала. Яшь дизайнерлар, архитекторлар, урам сәнгате вәкилләре Alesha, Neji201, Мидат Вәлиев, Лиля Долбина, Катерина Конюхова, Salqin, Анастасия Морозова шәһәр тормышын «көз-

1990 нчы еллардагы сәнгать әсәрләре әйләндереп алган.

Болар – галерея ачылганнан бирле гамәлгә кертелгән проектларның бер өлеше генә. Аларның һәркайсы – үзе бер микрогаләм. Экспонатларның һәркайсының ясалу тарихы һәм авторлары турында мавыктыргыч мәгълүмат туплана, лекцияләрне республикабыз сәнгать белгечләре генә түгел, башка шәһәрләрдән чакырылган экспертлар да укый. Шул ук вакытта галерея үз иҗат юлын – идеаль концепция эзләвен дәвам иткән кебек тоела.

гедәгедәй чагылдырган» эшләрен тәкъдим итә. «Уайт уолз, уайт уайн, уайт пипәл (ак диварлар, ак шәраб, ак кешеләр. – Ред. иск.). Миңа яңа изм кирәк», – дип хәбәр итә стрит-артчы Alesha төшергән «Для чего я это делаю» фильмы барган монитор янындагы табличка. Salqin иҗат иткән хикмәтле керамик формалар – әллә фантастик әгъзалар, әллә ташка әйләнгән хисләр төере янында тамашачылар бик озак туктап тора. Neji201 картинасы – «Чалмалы ханым» сюрреалистик портреты, анда авыз урынына күзләр һәм яулык сурәтләнгән.

Хәзерге заман иҗаты белән экспериментлар үткәреп карагач, галерея белгечләре концептуаль ретроспективага мөрәҗәгать иткән. Һөнәре буенча патологоанатом, шул ук вакытта сәләтле фотограф та булган Евгений Балашов республика рәссамнары, фотографлары, актерлары һәм 1990 нчы еллар иҗат интеллигенциясенең башка вәкилләре фотопортретларының зур коллекциясен музейга тапшырган. Күргәзмә «Фотология бытия» дип атала (Казан фәлсәфәчесе Владимир Юриновның Балашов белән хезмәттәшлектә язылган китабы да шундый исемдә). Фотограф модельләре арасында Илгизәр Хәсәнов, Виктор Тимофеев, Геннадий Архиреев, Александр Артамонов, Фәрит Гобәев, Евгений Канаев, Рамил Гали, Ольга Юхновская һәм башкалар бар. Портретлар «табигый мохиттә» куелган: аларны шул чакта шәһәрне шаулаткан мәдәни вакыйгалар турында газета-журналлардан кисеп алынган мәкаләләр (мәсәлән, тере боди-арт күргәзмәсе хакында), иҗат көнкүреше предметлары, видеоартлар,

САФ КҮҢЕЛЛЕ АКЫЛЛЫБАШЛАР

Шуңа таба ясалган адымнардан берсе – ноябрьдә тәмамланган гаять зур «Космос гасыры Прометее» проекты, ул төсле музыка һәм видеоарт пионеры Булат Галиев иҗатына багышланган. Әлеге күренекле шәхес гомере буе яктылык һәм музыка сәнгатьләрен кушу идеясе белән яна. Аның җитәкчелегендә «Прометей» фәнни-тикшеренү институты күптөрле уйлап табулар белән шөгыльләнә – дискотекалар өчен стробоскоп җайланмаларыннан алып, космик кораб белән идарә итү системасын күзәтү аппаратына кадәр: нормада аппарат экраны тигез яна, нинди дә булса җитешсезлек килеп чыкса, төс үзгәрә. «Прометей» Салих Сәйдәшев музее экспозициясе өчен стереотавыш системасын эшли – экспонатлар тамашачылар белән «сөйләшә» башлый. Галиевне синестезия феномены (тавыш ярсыткычларына җавап буларак күрү тойгысы үзгәрү һ.б.) бик кызыксындыра. Тарихта беренче буларак «Прометей» Александр Скрябинның «Прометей» музыкаль поэмасын һәм София Гобәйдуллинаның «Аллилуя» җырын «төсләндерә». Казан циркының һава торышына бәйле рәвештә яктыртылуы үзгәрү дә – бу институт проекты.

«Прометей» җиһазларыннан, Галиев үзе уйлап тапкан инсталляцияләрдән («Саф күңелле акыллыбашлар»), аның эшенә бәйле документлар һәм фотосурәтләрдән гыйбарәт экспозиция 2020 елда да нәкъ шул ук җирдә – 1987 елда биредә үткән «Пространство. Вакыт. Сәнгать» күргәзмәсе урынында ачыла.

Быелгы экспозициянең кураторы – Дәүләт Третьяков галереясының күргәзмә проектлары кураторы, сәнгать белгече **Кирилл Светляков.** Аның идеяләренең берсе – Третьяковкада «Прометей»ның 1987 елгы күргәзмәсен кабатлап күрсәтү.

– Галиев шәхесе дөньякүләм дәрәҗәдәге проектлар белән шөгыльләнүче рәссамнар, галимнәр, композиторларны үзенә тарта. Казан яктылык сәнгатенең тулы бер секторы барлыкка килү үзәгенә әйләнә. Материал күп, әллә ничә экспозиция оештырырга җитәрлек. Галиев темасын үстереп, галерея берьюлы берничә бурычны хәл итә ала: үзенең җирле тәңгәллеген күрсәтә, заманча сәнгать тарихын өйрәнү белән шөгыльләнә торган музей абруена яулый, моңа аваздаш проектлар тудыра торган башка музейлар һәм күргәзмә мәйданнары белән хезмәттәшлек урнаштыра, – ди Кирилл Светляков. – Үсеш өчен үзеңне күрсәтә белү, имидж, урынның изгелеге бик мөһим. Шул рәвешле кызыклы рәссамнар тартыла, биредә үзләренә ниндидер тирән һәм хикмәтле фикерләр тәкъдим ителәсен белгән тамашачылар җәлеп ителә. Шундый даны булган музей, инде абруена зыян китермичә генә, эксцентрик проектларга да алына ала. Күргәзмәләрдә лекцияләр укылу, экскурсияләр үткәрелү дә бик яхшы. Кешеләр үзләренә күрсәтелгән нәрсәне аңларга, күргәннәре хакында фикер алышырга, авторлар һәм кураторлар белән аралашырга тели. Күргәзмәгә кергәндә куела торган текст тамашачының хәзер күрәчәк предметларга мөнәсәбәтен билгели, шулай ук әлеге мәйданчыкның компетентлыгы һәм җитлеккәнлеге хакында да күп нәрсә сөйли.

Эксперт фикеренчә, язмышлары Татарстан белән бәйле тарихи шәхесләргә мөрәҗәгать итү дә үсеш концепциясенә ачкыч була алыр иде.

– Миңа Барлык диннәр храмын төзегән Илдар Хановка багышланган күргәзмәне күрү бик кызык булыр иде. Гомумән, Казан һәм Татарстанда тарихи вакыйгаларга зур йогынты ясаган амбицияле персонажлар бихисап. Алар дөньякүләм проблемаларны хәл иткән. Әлеге глобальлек һәм локальлек темасын күргәзмәләр аша кызык итеп ачарга мөмкин, – ди Третьяков галереясы кураторы.

СӘНГАТЬНЕ НӘРСӘ ҮТЕРӘ

Әмма бу амбицияле проектларны кем тормышка ашырачак соң? Alesha, Катерина Конюхова («Шум города» эшләре авторлары) һәм башка яшь, перспективалы рәссамнар Казаннан китә яки үз әсәрләрен башка төбәкләрдә иҗат итә. Республикада галерея киләчәктә таяна алачак рәссамнар бармы алар? Галерея үзе дә алар белән хезмәттәшлеккә әзерме икән әле?

– «Зур Идел» күргәзмәсе оештырылган дәвердә рәссамнар белән килешү төзелә, аларның картиналарын музей сатып ала иде. 1980 елгы күргәзмәгә куелган картиналарның күбесе хәзер дә галерея коллекциясендә саклана. Мондый заказлар ике бурычны хәл итә иде: заманга һәм аның проблемаларына аваздаш әсәрләр язылса, ә рәссамнар заказ һәм хезмәт хакы ала. Яңа галереядагы экспозиция өчен актуаль материал кирәк. Тик ул кайдан килсен? Күпчелек базар ихтыяҗын исәпкә алып эшли, сатып булырлык хезмәтләр яза. Грантлар ярдәме, проект заказлары кирәк, – дип саный Россия рәссамнары иҗат берлегенең Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге



Участие художников Татарской АССР в создании этой выставки характеризуется высокой активностью. Приведем для сравнения такие цифры: на второй зональной выставке «Большая Волга» в 1967 году от республики участвовало 49 художников, на третьей (1969) — 44, на четвертой (1974)— 56, на пятой — 119.

Кардинально изменилась «география» представительства мастеров изобразительного искусства республики на выставке «Большая Волга-80». В ней приняли участие не только художники Казани, но и Лениногорска (М. Хаертдинов, О. Кульпин, А. Юдин, Т. Самойлова), Набережных Челнов (Н. Бикташев, Э. Бусова, А. Вашуров, Л. Владыкин, А. Гараев, Х. Гимазетдинов, Г. Иванов, Р. Круглякова, М. Шайдуллин), Нижнекамска (А. Фатхутдинов), Зеленодольска (Р. Галиуллин, Х. Сибгатуллин), Бугульмы (Г. Миргалимов).



Яркая радуга на фоне синего неба и трепещущее под свежим порывом ветра алое с голубым знамя РСФСР — этот емкий поэтический символ, найденный казанской художницей Е. Киселевой для выставочного плаката, значка и каталога «Большая Волга», выражает то чувство душевного торжества, весеннего возрождения и вдохновения, которое остается основным эмоциональным впечатлением у посетителей выставки «Большая Волга».

рәисе **Илгизәр Самакаев.** – Менә минем натюрмортым бар: сусыл, матур анар җимешләре арасында сугышчан граната ята, ул теләсә кайчан шартларга мөмкин. Моны кемнең аласы килсен? Минем яраткан темам – безнең көннәрнең оҗмахы һәм тәмугы. Мин тамашачыга шуны күрсәтәм: безне ракеталар саклаган вакытта без оҗмахта яшибез булып чыга. Әгәр минем белән әлеге теманы тагын 15–20 рәссам күтәреп чыкса, өндәмәнең куәте күп тапкыр артыр иде.

– Без туган ягыбыз тарихын күптән өйрәнәбез. Берничә ел инде без, «Сәләт» лагерын оештыручылар һәм Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә, Идел Болгарстаны башкалаларының берсе булган Биләргә багышланган проектны гамәлгә ашырабыз, тарихи материалдан, мифлегендалардан табылган образларны ачыклыйбыз. Рифкать Вахитов, Равил Заһидуллин, Фиринат Халиков тарихны детальләштерә, тамашачыга якынайта. Мөдәррис Минһаҗев Болгар тарихын өйрәнә, – ди Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге Идарәсе рәисе **Альберт Шиһабиев.** – Әмма безнең берлекнең барлык вәкилләре дә үз күргәзмәләре белән галереяга әләгә алмый. Экспозицияләр үткәрүне чиратка салсаң шәп булыр иде. Тулаем алганда, Татарстанда үзенчәлекле рәссамнар күп. Зөфәр Гыймаев, Виктор Тимофеев, Илгизәр Хәсәнов, Владимир Акимов, Виктор Анютин эшләре башка төбәкләр һәм хәтта илләр музейларын бизи. Күп кенә кызыклы рәссамнарның Казаннан ерак районнарда яшәве дә игътибарга лаек. Георгий Иванов дәверендә Яр Чаллының үз мәктәбе формалашты. Мәдияр Хаҗиев яңа буын тәрбияләде. Республиканың көньяк-көнчыгышында Мәснәви Хәертдинов җитәкләгән Лениногорск музыка-сәнгать училищесы шәкертләре – Олег Кульпин, Тамара Самойлова һәм башкалар эшли. Аларның үзгә реалистик язу манерасы тоемлана. Галерея аларның иҗатына ешрак мөрәҗәгать итсен һәм хезмәттәшлекне көчәйтсен иде. Семинарлар, сәнгать белеме буенча чаралар, резиденцияләр өчен моннан да яхшырак урынның булуы мөмкин түгел.

– Элек галерея Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге карамагында иде. Без анда хисап, төркемнәр, яшьләр күргәзмәләре үткәрдек. Хәзер ул Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музее составына керә һәм безнең өчен ябык, гәрчә кайчандыр ТАССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе Харис Якупов инициативасы буенча республика авторлары иҗатын күрсәтү өчен төзелгән булса да, – ди Татарстан Рәссамнар берлеге җитәкчесе **Илнур Сираҗиев.** – Евгения Васильева күргәзмәсе – коммерция проектына мисал. Әмма бит шул рәвешле сынлы сәнгатьнең потенциалы үтерелә. Сәнгать фондлары формалаштыру системасы СССР белән бергә юкка чыкты, яңасы исә пәйда булмады. Алай гына да түгел: хәзер безнең өчен заллар юк. Галерея ремонтка ябылгач, Милли мәдәни үзәктә күрсәтелә идек, хәзер исә бу мәйданчыгыбыз да юк. Харис Якупов исемендәге премиягә җибәрелгән эшләрне Мәҗитов музеена куйдык. Сайлап алынган 76 эштән 26 сы гына сыйды. ТАССРның 100 еллыгына күргәзмәне Яр Чаллыда һәм Яшел Үзән галереяларында уздырдык. Вазгыять үзгәрер, дип ышанасы килә. Иҗат ресурсларын саклап калу өчен, без үзебезнең хәлдән килгәннең барысын да эшләячәкбез.

1991

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ

1991 елдан «Татарстан коммунисты» **«Татарстан»**га әверелә. «Хәерле юл, «Татарстан», үзеңнең күпмеңлек аудиторияңә лаеклы бул», – дип язылa яңа, инде тугызынчы исемен алган «Татарстан» журналының баш мәкаләсендә.

Журнал үзенең форматын һәм дизайнын күп тапкыр алыштыра, тулы төсләр белән, калын булып чыга башлый. Әмма 1991 елдан соң аның исеменә инде беркем дә кагылмый.

МӨХӘРРИРЛӘР

Рафаэль Мостафин

Нигездән яңартылган журналның исемен үзгәртү инициативасы яңа баш мөхәррир Рафаэль Мостафинныкы була. Талантлы язучы һәм публицист, әдәби тәнкыйтьче, журналист, педагог Рафаэль Әхмәтович Мостафин тарихка «Татарстан» журналының беренче баш мөхәррире булып кереп кала (1991–1998 еллар). Тирән белемле, зыялы, рус һәм татар телләрен бердәй яхшы белүче, Казанда да һәм Мәскәүдә дә зур абруйга ия Рафаэль Мостафин журнал белән хезмәттәшлек итүгә иң яхшы галимнәрне һәм экспертларны, сәясәтче һәм икътисадчыларны, тарихчы һәм язучыларны җәлеп итә. Аның җитәкчелегендәге журнал Татарстандагы, ил тормышындагы яңа чор турында күпмедер мәгънәдә нечкә һәм интеллектуаль фикерләү үрнәгенә әверелә.

Рифат Фәттахов

«Татарстан»га 1998–2009 елларда җитәкчелек иткән Рифат Әхмәтович Фәттахов, журналыбызны юбилее белән котлап, болай дип язды: «Татарстан» журналының кыйбласы бервакытта да, нинди генә чорда, нинди генә исем астында чыкса да, үзгәрмәде... Әлбәттә, һәр чорның үз таләбе, үз мәнфәгате. Мин эшли башлаган 1998 ел – республикабызда зур тарихи үзгәрешләр барган чор. Республика исемен йөрткән журналга ул чактагы Президентыбыз Минтимер Шәймиев тарафыннан: «Татарстан» журналы республикабызның «визит карточкасы» булырга тиеш», – дигән максат-бурыч куелды. Бу – бик зур дәрәҗә дә, бик зур ышаныч та иде. Без шул шигарь астында эшләдек, иҗат иттек». Бу чорда өр-яңадан рус телле авторлар коллективы оеша һәм рус телендәге басма да кабат кайтарыла (берничә ел журнал татар телендә генә чыга). «Татарстан» тышкы яктан да нык үзгәрә: ул сыйфатлы фин кәгазендә бастырыла башлый. Журналның тиражы сизелерлек арта. Кайбер елларда ул 10 мең данәгә якынлаша.

Айдар Сәлимгәрәев

2009 елда «Татарстан»га беркадәр вакыт дәвамында ул чакта «Татмедиа» АҖнең генераль директоры урынбасары булган Айдар Сәетгәрәевич Сәлимгәрәев җитәкчелек итеп ала. Ул оператив рәвештә профессиональ команда туплый, аның алдына форматны яңарту, стилистиканы һәм материалларны бирү рәвешен үзгәртү бурычы куела. Бу чорда көндәшлеккә сәләтле өр-яңа продукт дөньяга килә.

Диләрә Байчурина

Диләра Камилевна Байчурина – «Татарстан»ның ирләрдән генә торган баш мөхәррирләр сафына хатын-кыз элементы кертеп җибәрә. Ребрендинг нәтиҗәсендә журнал яктырып китә, матур һәм заманчага әверелә. Журнал белән ул 2009 елдан 2012 елга кадәр җитәкчелек итә. «Бу зур үзгәртеп кору тарихы иде. Мин бу чорны барлык яңаны актив кертү чоры буларак искә алам», – ди ул. Гомумән, 90 еллыгына журналны яшәртәләр. Аның айпад-версиясе, сайты барлыкка килә. Аның девизы мондый була: ул картаймый, ул яшәрә, ул һәрвакыт беренче сафларда!

Артём Тюрин

Редакция җитәкчелегендә Артём Дмитриевич Тюрин торган өч ел вакыт күпләрнең хәтеренә шау-шулы акцияләрнең рекордлы саны белән кереп кала: «Татарстан» флагы астында ретроавтомобильләр узышыннан башлап, «Главный по факту» дигән көчле премия булдыруга кадәр. Креативлыкның иң югары ноктасы – Эльбрус тавына, биш мең метр биеклеккә күтәрелеп, «Татарстан» флагын кадап кую. Шушы ук чорда басманың татар редакциясе яңа штат берәмлекләре белән тулыландырыла. Нәтиҗәдә татарча «Татарстан»да тәрҗемә материаллар кими һәм оригинальләре арта.

КИЛӘЧӘК КУНАГЫ

Автор: Әскәр Сабиров

«Татарстан» исеме белән басыла башлаган журналыбыз республикабыз тормышына кагылышлы гаять мөһим темаларны яктырта. Басманың 1997 елның апрель санында басылган мәкаләдә Татарстанда битум ятмаларын үзләштерүнең перспективалары турында языла. Танылган журналист Марсель Зариповның мәкаләсе бүгенге көнгә бик аваздаш. Безнең хәбәрчебез хәзерге вакытта үтә үзле нефть ятмаларын эшкәртүнең яңа технологияләре турында сөйли.

Карлы басу, урман. Офыкта – язга кадәр йокыга талган елга. Һәм кинәт җиргә үзләренең корыч капшавыч-борыннарын чумдырган куркыныч монстрлар пәйда була. Башка Галактиканы хәтерләткән, Җир өчен ниндидер ят манзара. Хәер, чит планета кунакларының моңа бернинди дә катнашы юк. Бу – үз планетабыз. Татарстан. Үтә үзле нефть чыгарыла торган Ашәлчә чыганагы.

Фотолар «Татнефть» ГАҖның рәсми сайтыннан алынды



Огненных горизонтов

На татарских промыслах есть возможность увидеть промышленную разработку битумов - пока в опытном, экспериментальном варианте, и я отправился на Мордовско-Кармальское месторождение.

Побежала дорога, замелькали села и аулы, речки, холмы, леса. Сарабикул, Мордовская Кармалка, Шугур, Спиридоновка, речки Шушма и Сугушлинка - названия, знакомые еще по описаниям научных экспедиций Рычкова, Лепехина, Палласа, Губкина, поискам нефти предприимчивыми, но, увы, неудачливыми Малакиенко, Шандором, Деминым...

Кара алтын ятмалары – менә шушында, аяк астында гына диярлек. Җир куенында әллә ничә чакрымга җәелгән нефть «бәлешенә» кадәр ара Дубайдагы Бурҗ Хәлифә бинасының күзәтү мәйданчыгы биеклеге кебегрәк – йөз егерме метр чамасы. Тик менә җир астына төшә торган лифт уйлап табылмаган әле, безнең максат та башкарак – нефтьне җир өслегенә чыгару. Мәсьәлә бер дә җиңелләрдән түгел: үтә үзле нефть гади кара алтыннан бик нык аерыла. Анда, тирәндә, куе һәм сузылып килүчән массалы, сигез катлы йорт калынлыгындагы катлам яшеренгән. Ул тыныч кына эшсез-файдасыз хәлдә ята бирә, чөнки һәркем белгән сыек нефть чыгарган кебек, гадәти насослар белән гади скважина аша бу кара байлыкны якты җир өстенә күтәртә алмыйсың. Бөтенләй башка технологияләр һәм бөтенләй башка чыгымнар таләп ителә.

Ә ник әле кирәкмәгәнне эшләп йөрергә соң? Ромашкино кебек яхшылап тикшерелгән, үзләштерелгән йөзләрчә нефть чыганагы бар, алар миллионлаган тонна нефть бирә... Әйе, дөрес. Әмма киләчәкне уйлаганда бу алай түгел. Чөнки Ромашкино да, күп кенә башка ятмалар да, ни кызганыч, кичәге яки бүгенге көн генә дигән сүз. Якындагы берничә унъеллыкка гына алар – иртәгәсе көн чыганагы. Ятмалар үзләштерелә һәм картая. Кара алтынны куллану үсә бара, планетада нефть запаслары тагын да тизрәк кими. Шул ук вакытта, янәшәбездә генә, чын мәгънәсендә, аяк астында – «башка» төр байлык, үтә үзле нефть ята һәм аның күләме шаккатыра.

Татарстанда гына да үтә үзле нефть запаслары, төрле бәяләүләр буенча, миллиард ярым тоннадан җиде миллиард тоннага кадәрне тәшкил итә. Күпме бу, әллә азмы? Хәтерләсәгез, республикада гадәти ятмалар үзләштерелгән җитмеш биш ел эчендә өч миллиард тоннадан артыграк углеводород чималы чыгарылган. Менә шуннан нәтиҗәләр ясагыз.

Арттырып, шапырынып сөйләргә күнекмәгән галимнәр үтә үзле нефть ятмаларын планетабызның дөньякүләм энергия чималы запасы дип атый. Ашәлчә – үзенә күрә сынау полигоны. Чагыштырмача зур түгел ул, монда бәхетле иртәгәсе көнебезнең стратегик хәзинәсенә ачкыч яратып карарга җөрьәт иттеләр.

ҖИР АСТЫНДА ПАРЛЫ МУНЧА

Җир пейзажына космос детальләре кертә торган, кармавычларны хәтерләткән авыш корыч баганалар, асылда, торбаүткәргечләр төене ул. Тик алар гадәти скважинадагы кебек, җир астына вертикаль түгел, ә ниндидер башка сыймаслык почмак ясап кереп китә. Утырган бал кебек үзле нефтьнең ни рәвешле өслеккә чыгарылуын ачыкларга теләүчеләр өчен әлеге «кармавыч» баганалар ярдәмгә килә ала.

– Җир өслегенә чыга торган горизонталь скважина бораулана, аның астында параллель рәвештә – тагын берәү. Өстәгесенә кайнар пар җибәрелә. Пар үтә үзле нефтьне сыек хәлгә килгәнче җылыта һәм аны икенче скважина белән җир өстенә чыгарып була. Асылда, беренче карашка, барысы да гади генә, – дип аңлатты журналистларга ул вакытта «Татнефть»нең генераль директоры булган Шәфәгать Тәхәветдинов, махсус технологик нечкәлекләрне төшереп калдырып. Бу ун ел элек, әлеге ысулны тәҗрибә рәвешендә сәнәгатьтә куллану беренче нәтиҗәләрен генә китерә башлаган чакта иде.

Нефтьчеләр өчен бу гадилекнең ни дәрәҗәдә катлаулы икәнен әлеге эшнең детальләре күрсәтә. Соңыннан ачыкланганча, үтә үзле нефть чыгару принцибын безнекеләр ерак Канадада карап кайткан икән, анда мондый чималны иртәрәк чыгара башлаганнар. Тик канадалылардан аермалы буларак, татарстанлыларның бу юнәлештә эш тәҗрибәсе дә, технологияләре дә, яраклы җиһазлары да юк иде.

Горизонталь скважина бораударга кирәк дип әйтүе генә җиңел. Ул төп продуктлы горизонтка кадәр барып җитәргә, аның янында үтәргә, ә аннары 100–120 метрдан соң кабат җир өстенә калкып чыгарга тиеш бит... Татарстанда да, гомумән, Россиядә

дә ул чакта һичкемнең мондыйны эшләп караганы юк иде. Ә чит илләрдәге нефтьчеләр нәрсә, диярсез... Аларның серләрне ачарга атлыгып тормавы аңлашыладыр.

Билгесез нәрсә куркыта. 2006 елда Ашәлчә ятмасында эксперимент ясарга карар кылып, беренче скважинаны бораууларга тотынгач, бу эшне читтән генә күзәтүчеләр бертавыштан уңышсызлык юрый.

«Аларның барысы да бер фикердә булды, янәсе, бу мөмкин нәрсә түгел, – дип сөйләде журналист халкына «Татнефть» ГАҖнең үтә үзле нефть чыгару идарәсе башлыгының беренче урынбасары Роберт Әхмәдуллин. – Ләкин «Барыбер бораулап чыгабыз!» – дип әйтерлек бер кеше табылды».

Бу үҗәт зат генераль директорның бораулау буенча урынбасары Михаил Студенский була. Һәм ул үзенең хаклыгын раслый. Дөрес, беренче горизонталь скважинаны бораулау, дөнья тирәли сәяхәт өчен Жюль Верн геройларына күпме вакыт кирәк булса, нәкъ менә шулкадәргә сузыла.

Беренче скважина, тәүге ике скважина, беренче тапкыр пар җибәрү... Булачак технологик чылбырның һәр этабы чын җиңү була. Ниһаять, тирәндәтирәндә пар мунчасында йомшарып, насослар куып торган нефть, җир өстенә менәргә «ризалашып», беренче тапкыр югары күтәрелгәч, Татарстан нефтьчеләре һәм галимнәре уйлап тапкан үтә үзле нефть чыгару технологиясенең яшәргә хокуклы икәне ачыклана.

Ә кармавычлар – төрледән төрле почмак ясап җир астына кереп киткән торбаүткәргечләр – әнә шул искиткеч скважиналар инде ул, хәзер инде алар көйләп-җайлап куелган. Аларның берсеннән пар җибәрелә, ә икенчесе буйлап җир куеныннан углеводород чималы өскә чыгарыла...



Сегодня российской экономике не до битумов, изнемогающая под бременем
"реформ", она и легкие месторождения отдает на откуп иностранцам. Берите,
пользуйтесь, владейте! Сколько коммерческих банков мельтешат в рекламах,
расхваливают свое финансовое благополучие... И ни один не догадался
профинансировать разработки битумных полей, извлечение пропадающих в
этих породах дорогостоящих - дороже "черного золота" - ванадия, никеля,
цезия, стронция, рения. -

Проблемы добычи битумной нефти скважинами, над которыми с неистребимой
верой в удачу бьются татарские нефтяники, выходят за пределы интересов
одного региона. В битумах - энергетическое, нефтехимическое будущее
человечества! Мне кажется, мировое сообщество могло бы объединить силы,
средства, наличные технические ресурсы, на одном промысле отработать всю
технологию, начиная с добычи и кончая переработкой сырья, с обязательным
извлечением всех компонентов, которые (опровергая укоренившиеся стереотипы)
не ухудшают, а умножают достоинства "черной крови" земных недр. А потом
обретенный опыт можно было бы с успехом и выгодой растиражировать по
другим нефтеносным регионам, странам и континентам. Зачем же поодиночке
изобретать порох?!

МӘҖЛЕСЛӘРСЕЗ ҺӘМ КУПШЫ СҮЗЛӘРСЕЗ ГЕНӘ

Сүз уңаеннан, Ашәлчә ятмасында беренче тонна үтә үзле нефть чыгару хөрмәтенә купшы мәҗлесләр оештырылмый. Әлеге эш шау-шусыз гына, матбугат вәкилләрен чакырып тормыйча гына башкарыла. Җир асты хәзинәсенә ачкыч шактый кыйммәткә төшә. Экспериментал скважинадан чыгарылган һәр тонна нефть 40 мең сум зыян китерә.

Шулай баш вату, меңләгән сум акчаны сарыф итү кирәк идеме, гадәти нефтьне суырт та, гарантияле керемең килеп торсын шунда. Үсеш һәм иртәгәсе көн турында уйламасаң, мөгаен, кирәк тә булмагандыр. Тик тарихта һәрвакыт шулай: берәүләр бүгенге көн белән яши һәм оттыра, икенчеләре тәвәккәлли дә конвейер уйлап тапкан Генри Фордларга әйләнә.

«Татнефть»тә икенче вариантны сайлыйлар. Ашәлчә чыганагы үзенчәлекле полигонга әверелә, анда үтә үзле нефть чыгару технологиясе тикшерелә һәм камилләштерелә. Гади укучыга ятманың тәҗрибә рәвешендә үзләштерелү барышында уйлап табылган күп кенә алдынгы яңалыклар һәм карарлар турында сөйләүнең мәгънәсе юктыр, чөнки монысы – артык үзенчәлекле тема. Ә менә нәтиҗәләрне хәтта белгеч булмаган кешеләр дә бәяләр, дип уйлыйм.

Шулай итеп, вакыйгалар хроникасы:

2006 ел. Май. Россиядә беренче тапкыр кире җир өстенә чыга торган ике горизонталь скважинаны бораулау төгәлләнә. Июль. Горизонталь скважинадан беренче тонна үтә үзле нефть чыгарыла.

ла: әлеге байлыкларны акыл белән һәм нәтиҗәле үзләштерү Россиянең энергетик куркынычсызлыгын тәэмин итүгә саллы өлеш кертергә мөмкин.

Ниһаять, 2020 елның август ае. Татарстанда ун миллион тонна үтә үзле нефть чыгарылган. Үтә үзле нефть ятмаларында 1046 скважина эшли. 2016 ел белән чагыштырганда, нефть чыгаруның үзкыйммәте ике тапкыр кими. Компаниядә тормышка ашырыла торган СНВ-3200 проекты быел ук өч миллион 200 мең тонна нефть чыгаруны күздә тота.

Бүген биредә нефть чыгару нәтиҗәлелеген арттыру һәм алынган чималны эзерләүнең яңа, тагын да камилрәк технологияләрен һәм ысулларын сыныйлар. Унбиш ел эчендә классик схемага әйләнгән ике горизонталь скважина белән чыгару ысулы да үзгәртелергә мөмкин икән. Галимнәр продуктив катламны җылытырга пар җибәрү, ә аннары «йомшаган» нефтьне югарыга күтәрү өчен ике түгел, ә бердәнбер скважинаны куллану схемасын уйлап тапкан. Фантастикамы? Хәзер инде юк. Бер үк скважинаны циклы режимда эшләргә генә өйрәткәннәр: башта ул җир астына кайнар пар ташый, аннары – кара алтын чыгара. Соңыннан – янә пар һәм янә нефть... Күз алдыгызга китереп карагыз әле, нәтиҗәдә никадәр акчаны янга калдырырга була.

2012 ел. Үтә үзле нефть чыгару табыш китерә башлый. Тәҗрибә рәвешендәге үзләштерү эшеннән экренләп сәнәгый эксплуатациягә күчәләр. Хәзер биредә тәүлегенә 200 тоннадан артык чимал чыгарыла. Ятманы үзләштерә башлаган көннән соң, аннан 176 мең тонна чимал алынган инде. «Ашәлчә ятмасында беренче скважинаны – 80 тәүлек, ә соңгысын дүрт тапкыр тизрәк бораулыдылар. Максат – 15 тәүлек эчендә бораулау, ул чакта бу инде осталык түгел, ә сәнгать булачак!» – дип, хис-кичерешләрен белдерә ул чакта «Татнефть»нең генераль директоры Шәфәгать Тәхәветдинов.

2016 ел. Февраль ае. Ашәлчә ятмасында үтә үзле нефтьнең беренче миллион тоннасы чыгарыла.

2017 елның октябрь ае. «Нурлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе операторы-бригадиры Алексей Степанов 15064 номерлы скважинадан өченче миллион тонна нефтьнең пробасын ала. Мондый тарихи вакыйгага бу юлы матбугат вәкилләрен дә чакыралар. Хәзер инде Ашәлчә ятмасындагы эшхәлләрне көтелмәгән нәтиҗәле бер эксперимент дип кенә атап булмый.

– Беренче миллион тоннаны без 10 ел чыгардык. Чираттагы ике миллионны – ике ел ярым, – дип аңлата үтә үзле нефть чыгару идарәсе башлыгы Марат Әмирханов. – Киләсе елга бурыч – кимендә ике миллион тонна...

2018 елның декабре. Татарстанның үтә үзле нефть ятмаларында бишенче миллион тонна чимал чыгарыла. Биредә һәр тәүлек саен 5600 тоннадан артык углеводород чималы алына. Илебездәге үтә үзле нефть запасларының өчтән бер өлеше Татарстанда икәнлеген исәпкә алсак, нәтиҗә үзеннән-үзе сора-

ҮЗЕН АКЛАГАН ТӘВӘККӘЛЛЕК

Шулай да әлеге үтә үзле нефть гадәти нефтькә караганда беркайчан да арзанрак булмаячак. Пар җитештерү өчен җылылык үзәкләре кору, парны җир астына җибәрү, горизонталь бораулауда кулланыла торган искиткеч катлаулы җиһазлар, ниһаять, алынган чималны кулланучыларга җибәрергә мөмкинлек бирә торган стандартларга җиткерү... Әмма сүз, исегезгә төшерәбез, стратегик энергия ресурслары турында бара, алар якынлашып килгән гадәти нефть дефицитын капларга тиеш. Бу очракта арктик шельф нефте альтернатива булырга мөмкин, тик ул, мөгаен, берничә тапкыр кыйммәткәрәк төшәчәк. Анда, Арктикада, җан өшеткеч салкынлык белән боз гына бихисап...

– Россиядәге үтә үзле нефть ятмалары кешеләр күп яши торган урта полосада урнашкан. Бүген күпләрнең карашы төбәлгән Төньяк Боз океаны шельфыннан аермалы буларак, урта полосада нефть чыгару эшен оештыру өчен кирәкле бөтен нәрсә – хезмәт ресурслары, инфраструктура, юллар бар. Шулай булгач, биниһая зур чыгымнар таләп иткән шельфка керешкәнче, бүген монда яңа технологияләргә күчү рациональрәк түгелме? – дип сорау куйган иде Ашәлчә чыганагын үзләштерә башлаганда ук Шәфәгать Тәхәветдинов.

Икенче яктан, ул искә алган «плюс»лар бер үк вакытта тискәре як та булып тора. Әйе, шул ук Канада белән чагыштырганда, безнең үтә үзле нефтебез кешелек шәһәр-авыллар корган, үзләштергән урыннарда ята. Тик моның куркыныч тарафы да шунда.

– Канадада – елга, тундра, ә бездә бөтен җирдә торак пунктлар, бөтен җирдә – су чыганаклары. Алла сакласын, экологиягә зыян килергә мөмкин! – дип зарланды «Татнефть» ГАҖ генераль директоры Наил Маганов ике ел элек чираттагы нефть саммитында. – Сыйфатлы мониторинг кирәк. Куркыныч бик зур һәм бу куркынычларны азмыкүпме юкка чыгару, булдырмау өчен без биниһая акчалар тотабыз.

Элеккеге һәм хәзерге «генерал»ларның сүзләре никадәр каршылыкта булмасын, алар икесе дә гаять принципиаль мәсьәләдә уртак фикердә. Татарстан нефтьчеләре үз өстенә алган авыр йөк – бу өлкәдән юл ярып бару эше кесәгә суга. Яңа технологияләрне сынау һәм гамәлгә кертү чыгымнары, экологияне саклауга тотылган чыгымнар, чыннан да, искиткеч зур. Тик, беренчедән, бөтен компания дә мондый авыр йөкне үз өстенә алырга әзер түгел, икенчедән, күп чыгым таләп иткән эштә юл ярган пионерларның ресурслары да чиксез дип карарга ярамый.

Мәсьәләнең чишелеше кайда? Монда, мөгаен, нефть саммитларының берсендә Татарстан Президенты киңәшчесе Ренат Мөслимов китергән мисалны искә алу урынлыдыр. «АКШның Техас штатында, – дип искә төшерде ул, – биш ел эчендә нефть чыгаруны икеләтә арттырдылар, ә якындагы биш елда аны тагын ике тапкыр арттыру планлаштырыла. Ә без ул кадәр булдыра алабызмы? Юк. Чөнки эш мохите андагыча түгел. АКШта дәүләт процесс белән идарә итә. Нефть алу күләменә бик сак карыйлар. Нефть чыгару проектлары бөтен җирдә ташламаларга ия: алар өчен федераль һәм аерым бер штат тарафыннан ташламалар каралган. Әмма иң мөһиме: кайбер проектлар 40–50 һәм хәтта 80 процентка дәүләт тарафыннан финанслана. Һәм әлеге капитализм мәркәзендә проектны тормышка ашыруның барлык этаплары иң кырыс контрольдә тотыла. Безнең менталитетта болай эшли алмыйбыз, әмма шуңа омтылырга кирәк...»

Дәүләт Думасындагы энергетика комитетының элеккеге башлыгы Иван Грачев та Мөслимов фикерен яклый.

– Һәрвакытта да үтә үзле нефть чыгаруны мөмкин кадәр зур салым ташламалары таләп ителгән мөһим юнәлеш, дип санадым. Әгәр Себердә нефть чыгарганда андый ташламалар бирелә икән, нәтиҗәлелек ягыннан алардан һич калышмаган башка ятмалар да ни өчен ташламалардан файдаланмаска тиеш? – дип, үз фикерен ачыклады ул күптән түгел РБК-Татарстан порталына биргән әңгәмәсендә, сүз уңаеннан Арктика нефтьчеләре өчен салым йөгенең нульгә якынлыгын искәртеп.

Әмма стратегик проект һич хупланмады дип әйтү дә дөрес түгел, әлбәттә. Шунда ук булмаса да, үтә үзле нефть чыгаруга НДПИ (файдалы казылмалар чыгарган өчен салым) ставкасы нульгә төшерелде (2008 елдан – ред.), экспорт пошлинасы 10 процентка кадәр кимеде. Янга калган акчаларның алдан билгеләнгән максатларда гына тотылуы игътибар үзәгендә булды. Күптән түгел инвесторлар һәм аналитиклар белән бер очрашуда «Татнефть»нең генераль директоры Наил Маганов:

– Салым аша стимуллаштыру чаралары ярдәмендә «Татнефть» үтә үзле нефть ятмаларын үзләштерү проектына 105 миллиард сумнан артык инвестиция кертте. Ә нефть тармагындагы күп кенә көндәшләр бу юнәлешне технологик таләпләр һәм икътисадый шартлар күзлегеннән артык куркыныч дип карады, – дип хәбәр итте.

Дөрес, бүгенге чынбарлык шундый ки, үтә үзле нефть чыгаруны арттыру турында сөйләгәндә бик сак булырга туры килә. Бер яктан, киләсе елдан үз көченә керә торган яңа салым режимы тез астына суга, икенче яктан – ОПЕК+ килешүе нигезендә кабул ителгән нефть чыгару күләме буенча чикләүләр юл яба. Өметле, ләкин бик үк табышлы булмаган юнәлешне алга таба үстерү кирәкме-юкмы – моны тирәнтен уйлар вакыт.

Хәер, якын киләчәккә бәйле пессимистик фикерләргә исә шул киләчәк кунагы – үтә үзле нефть, дөресрәге, аны чыгару технологиясе үзе каршы килә. Аның үзенчәлеге шунда ки, ятмага кайнар пар җибәреп, пар камерасы булдырганнан соң, нефть чыгару эшен инде туктата алмыйсың.

– Бернигә дә карамастан, без инде үзләштерелә башлаган чыганакларда эшне дәвам итәчәкбез, – дип хәбәр итте күптән түгел «Татнефть» генераль директоры урынбасары Рөстәм Хәлимов. – Ә менә үтә үзле нефть ятмаларының яңаларын күтәртү мәсьәләсендә без, әлбәттә, хәзерге вазгыятьне исәпкә алачакбыз.

Үсеш булачакмы соң? Бөтен ил өчен хәл итәргә алынмыйбыз, әмма «Татнефть»нең позициясе ышаныч уята. Нефть чыгаруда өметле проектларга ярдәм итү яңа җитештерү, эш урыннары, инновацияле алга китеш бәрабәренә бөтен ил икътисады өчен мультипликатив эффект тудырачагына монда һәрвакыттагыча ышаналар.

Югарда әйтелгәннәрне, әлбәттә, кабат исбатларга кирәк түгел инде. Татарстанда үтә үзле нефть ятмаларын эшкәртү тәҗрибәсе – моның иң яхшы дәлиле. ■

ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№9 (321) – СЕНТЯБРЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Үзеңнеке читкә әйләнгәч

Уңыш кәрҗине

Замандашлары Исхакыйны ничек хәтерли

— ИДАРӘ ИТӘР ӨЧЕН, МӘГЪЛҮМАТЛЫ БУЛЫРГА КИРӘК

– КЕМ БЕЛӘНДЕР ИДАРӘ ИТӘР ӨЧЕН, **МӘГЪЛҮМАТЛЫ БУЛЫРГА КИРӘК**

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов – бүгенге көндә мәгълүматның роле, бюрократия белән көрәштә социаль челтәрләрнең файдасы һәм Инстаграмда үзенең активлыгы турында.

– Кем беләндер идарә итәр өчен, мәгълүматлы булырга кирәк. Мәгълүмат күп булган очракта, аны дөрес итеп эшкәртү, файдалану мөһим. Идарә системасы кире элемтә булмаганда эшләмәячәк. Элемтә өзелгәндә без урыннарга ниндидер директивалар, күрсәтмәләр юллыйбыз, тик дөрес эшлибезме-юкмы икәнлеген белмибез. Бер яктан караганда, әлбәттә, социаль челтәрләрдә тәнкыйтьләгәндә, үгет-нәсыйхәт биргәндә күңелле түгел. Әмма бу – гаять көчле кире элемтә. Безнең профессиональлегебез әлеге кире элемтәдән дөрес итеп файдалануда чагыла. Мин әлеге барлык мәгълүмат, күңелгә бик ошап бетмәсә дә, тулысынча каралырга тиеш дип саныйм.

«Халык контролендә» беренче яртыеллыкта гына да 30 меңнән артык мөрәҗәгать пәйда булды. Алар төрле юнәлешләргә карый – төзекләндерү, дәваханәләр, мәктәпләр, юллар. Һәм бу әйбәт –

аларның 70 процентка якынын без эшлибез. Арада инвестицияләр таләп итә торганнары да бар, аларын үзебезнең инвестицияле программаларыбызга кертәбез. Ни генә дисәк тә, **без әлеге сигналларны кабул итәбез, туплыйбыз һәм теге яисә бу проблеманың халыкның күпмедер өлеше өчен мөһим икәнлеген аңлыйбыз.**

Гомумән, **электрон хөкүмәт һәм электрон хезмәтләр күрсәтү системалары эшне күпкә җиңеләйтә, гадиләштерә, бюрократизмны киметә һәм кире элемтә булдыра.** Элек ничек иде бит – газеталарның безне мактаган чаклары, тәнкыйтьләгән чаклары бар иде. Бу – шулай ук кире элемтәнең бер формасы. Безне мактаучылар ниндидер эйфория тудыралар иде.

Бүген халык белән эшләү бөтенләй икенче. **Кешеләр үз фикерләрен белдерәләр, һәм бу «Халык контроле» генә түгел. Мин теркәлгән социаль челтәрләрдә мондый мөрәҗәгатьләр күп. Һәм мин әлеге сораулар өчен җавап бирүче коллегаларымнан һәрвакыт мөрәҗәгатьләрне теркәүләрен сорыйм.** Мәгълүматны алу гына түгел, аны исәпкә кую һәм процесска контрольлек итү дә мөһим. Мин мондый аралашудан баш тарткан коллегаларымны да беләм. **Ләкин без – җәмгыятьнең бер өлеше һәм, ошыймы-ошамыймы, без аннан аерым яши алмыйбыз.**

Ни өчен Инстаграмга фотоларны еш элмәмме? Минем карашымча, бик матур һәм күркәм нәрсәләр һәм вакыйгалар бар. Минемчә, бу фотолар мине социаль челтәрләр аша күзәткән кешеләргә дә кызык була ала. Барысын да урнаштырып өлгерә алмыйм, булдыра алган җирдә элэм. Мәсәлән, мәктәп ачылышы, балалар бии. Бу начармыни? Мөмкинлегем булганда, фото яисә кечкенә генә берәр ролик элеп куям.

Мин бит үземнең әллә кемлегемне расларга яисә тагын шундый берәр нәрсә күрсәтергә теләмим. Безнең илдә башка беркайда да булмаган ничаклы урыннар бар, гаҗәеп вакыйгалар булып тора. Безнең Камчатка, Сахалин, Магадан, Байкал һ.б.лар бар. Анда да кешеләр нормаль яши. Алар чит ил инвесторларын көтмиләр, үзләре заводлар төзиләр. Мәсәлән, мин шаккаттым: Итуруп һәм Шикотян утрауларында менә дигән мәктәпләр, балалар бакчалары бар, юллар төзелә, эш урыннары ачыла. Мөгаен, бу аларга бик җиңел бирелмидер, әмма алар илебезнең чын патриотлары. Һәм мин россиялеләрнең, татарстанлыларның кайдадыр бик еракта, бездән 8 сәгать очарга кирәк булган якларда да, Россия кешеләренең бик матур итеп яшәүләрен күрүләрен телим. Араларында татарлар да күп.

Безнең илебез бик матур, һәм мин кешеләр игътибар итсен өчен әлеге матурлыкны күрсәтергә тырышам. Чит илләргә генә йөрмәсеннәр, Россиядәге күркәм урыннарга да барсыннар. ■

«Татарстан», №9, 2018. Андрей Кузьмин белән «Галстуксыз әңгәмә». «Татарстан-24».

Фото: Рамил Гали, «Татар-информ» МА.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫННАН «ТАТАРСТАН» ТОРТЫ

Автор: Александр Ванечкин

Ниһаять! 2020 елның декабрендә республиканың төп журналы үзенең йөзьеллык юбилеен бәйрәм итә – без үзебезне дә, укучыларыбызны да туган көнебез белән котлыйбыз! Ерак 1920 елның салкын декабрендә журналның беренче саны дөнья күргән, аңа ‹‹Вестник Татарского областкома РКП (б) ›› дигән бик озын исем бирелгән.

Шундый тантаналы дата уңаеннан бәйрәм оештыруга яманаты чыккан пандемия комачауласа да, кунакларны ‹‹Татарстан›› торты белән сыйламый булмый бит инде! Һәм менә, рецептлар, ГОСТлар һәм кирәкле ингредиентларны туплап, бәйрәмдарыбыз ‹‹Татарстан›› легендар торт пешерүгә керешә.

Фото: Александр Ефремов

ЗУРАБ ХУБУЛАВА ХЫЯЛЫ

Республикабыз кулинариясенең визит карточкасы булган «Татарстан» тортын 1970 нче еллар башында Зураб Хубулава уйлап тапкан, дип санала (40 ел буе «Заря» кондитер фабрикасын җитәкләгән әлеге данлыклы шәхес белән әңгәмәне «Татарстан» журналының 2009 елгы май санынннан табып укырга мөмкин).

Түбән калорияле, бисквитсыз, суыткычсыз да озак саклана ала торган мондый торт аның хыялы була.

ТАТАРСТАН КҮЧТӘНӘЧЕ

Халык тортны бик яратып кабул итә. Казаннан китүче һәркем «Татарстан» поездында үзе белән күчтәнәч – «Татарстан» тортын да алып китүне изге бурычына саный. Әмма торт бик дефицит була, фабрика территориясендәге кибеткә иртәнге сәгать алтыдан озын чират тезелә...

БАЛАЧАК ТӘМЕН КАБАТЛАУ

Кыскасы, тәме һәркемгә балачактан таныш булган менә шул «легенданы» пешерергә туры киләчәк иде безгә. Белгечләр алдан ук кисәтеп куйды – өй шартларында бу хәтта кулинарларның да бик сирәгенең генә хәленнән килә, ә инде дилетантлар турында әйтеп торасы да юк... Әмма, «Татарстан» булыйк та, «Татарстан» тортын пешерә алмыйкмыни! «Пешерәбез, әлбәттә!» – дип карар кылды журнал коллективы һәм, җиң сызганып, алъяпкыч ябып, эшкә дә кереште.

МӘГЪНӘЛЕ ИРТӘНГЕ АШ

Чит кешеләрдән безнең бу эшне һичшиксез ерып чыгасыбызга бер генә кеше – «Россия 24» телеканалындагы «Завтрак со смыслом» программасын алып баручы Эльмира Җәләева гына шикләнмәде. Һәм без аның ышанычын акладык та! Коллегабызны иртәнге ашка тортсыз калдыра алмыйбыз бит инде – үзен дә әлеге кулинария җәүһәренең автордашы булырга чакырдык.

– Башта йомырканың агын сарысыннан аерабыз! – дип эш куша «Татарстан» редакциясенең офис-менеджеры Ләйсән Һадиева.

– Аксымнарны блендерга салабыз! – дип агрегатны эшкә әзерли хәбәрчебез Олеся Бондаревская.

– Шикәр белән! – дип шәрехли корректор Лилия Мөхәммәтшина.

– Сарыларыннан тәбә кыздырырбыз! – дип, кулындагы табасын селки шеф-редактор Әскәр Сабиров.

Барысы да ярдәм итәргә ашыга, шунлыктан кадрдагыларга (анда исә «Татарстан» журналының баш мөхәррире Татьяна Вафина һәм «Завтрак со смыслом» программасын алып баручы

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Йомырка (аксымы гына) – 20 данә
- Шикәр – 1кг 700 г
- Патока – 700 г
- Агар-агар – 30 г
- Ачы шоколад – 100 г
- Мүк җиләге конфитюры – 200 г

Эльмира Җәләева) торт бик җиңел һәм тиз пешерелер кебек тоела.

Әмма бу шулай тоела гына шул...

ТАТЛЫ ТӘМ-ТОМ

Машина торт җәемнәре өчен аксым күперткән арада (инструкция буенча моңа кырык-илле минут таләп ителә!) пешекчеләр крем-суфле әзерләүгә керешә. Бер савытка салынган ингредиентлар күләменнән күренгәнчә, ул безедан да баллырак булырга охшаган. Бер килограмм шикәр белән 700 грамм патоканы, болгата-болгата, сүрән утта кайнатып чыгарабыз, аннары суда җебетеп куелган агар-агарны өстибез дә, пешерәбез-пешерәбез-пешерәбез... Менә инде блендер аксымны ап-ак күбеккә әйләндерде, һәм без әлеге күбекне, пергамент җәелгән табага сылап, бер сәгатькә мичкә тыктык... Крем исә һаман пешә әле. Ярый ла сөйләшер сүз күп – журналның йөз еллык тарихы бик кызыклы вакыйгаларга искиткеч бай.

Безнең коллегаларыбыз – «Татарстан» журналистлары республикадагы иң мөһим вакыйгаларда катнашкан һәм аларны яктырткан бит: Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышын, ике сугыштан соңгы хәрабәләрне торгызу чорын, халыкның хезмәттәге батырлыкларын – ачлыкка каршы көрәшне, күмәкләштерүне, индустрияләштерүне... Күпләп нефть чыгара башлау, Чулманда нефть-химия җитештерүләре комплексын һәм КАМАЗны төзү, Әлмәт, Түбән Кама, Яр Чаллының зур сәнәгать үзәкләренә әйләнү процессы. Республика илебез өчен вертолетлар, самолетлар, зур йөк автомобильләре, нефть химиясе продуктлары, шиннар, кораблар, компрессорлар һәм суыту җиһазлары, полиэтилен, синтетик каучук, медицина һәм оптика җиһазлары, дарулар һәм юу-чистарту матдәләре җитештерә... «Татарстан» боларның барысы турында да «Путь Ильича», «Причал», «Татарстан большевигы», «Татарстан коммунисты» дип исеме шактый еш үзгәреп торган басмаларында язып барган...

– Пешеп чыгар алдыннан кремга күпертелгән аксым өстисе бар! – дип, сүзебезне бүлә хәбәрчебез Руфия Фазылова.

– Шуңарчы исә аларны туглап күпертергә оныт-магыз! – дип исебезгә төшерә чыгарылыш мөхәррире Фәридә Әхмәтҗанова.

– Шуңарчы исә йомырканың агын сарысыннан аерырга онытмагыз! – дип, тагын бер тапкыр тәбә ашарга әзер булуына ишарәле Әскәр Сабиров.

– Шуңарчы исә аларны сатып алырга онытмагыз! – дип бүлдерә бухгалтер Ольга Басаркина, тик, суыткычны ачып карагач, гафу үтенә.

Кадрда: «Завтрак со смыслом» программасын алып баручы Эльмира Җәләева һәм «Татарстан» журналының баш мөхәррире Татьяна Вафина.

Кабат йомырканың агын сарысыннан аерабыз һәм кирәклесен – блендерга, калганын табага салабыз.

– Аз гына шикәр өстәгез, – дип өйрәтә корректор. – Тик табага түгел инде, блендерга, блендерга, Әскәр Әсфәнович!

– Их, тозлы балык ашасаң иде хәзер... – дип авыр сулый баллы ярымфабрикатлар – безе һәм кремны авыз итеп туючылар.

Шул шәрехләүләрне тыңлый-тыңлый, пешергән кремыбызны күпертелгән аксымга саклык белән генә агызабыз. Болгаткач, мүк җиләге конфитюрын да өстибез – һәм менә матур алсу төстәге крем әзер. Безе җәемнәре дә пеште һәм суына. Технология буенча, алар бер тәүлек суытылырга тиеш.

Тик безнең ул тәүлегебез юк. Шоколад эреткән арада гына суытабыз да эшебезне дәвам итәбез.

СОКЛАНДЫРГЫЧ

Иң кызыклы мизгел – тортны җыю. Дизайнерыбыз Леонид Гобәйдуллинга җәемнәрне крем сылап өю процессы журналны битләргә салуны хәтерләтте: гади ашамлыклар – йомырка һәм шикәрдән (текст һәм фотосурәтләрдән, дип укы) торт (журнал, дип укы) пәйда була.

– Сулгарак, уңгарак ... – дип өйрәтә дизайнер. – Бу кырыйдан куерак сылагыз, алайса чокырланып тора... Әнә тегендә исә нигәдер күтәрелеп тора – тигезләгез! Ян-ягын да сыларга онытмагыз!

Сокландыргыч...

Тортка шоколад хәрефләр төшергәндә исә матурлык буенча баш кешебездән ике кулинарга да шәп эләкте. Матур язу осталыгы юк икән икебездә дә. Компьютер клавиатурасына күнеккән куллар каләм генә түгел, кулинария шприцы тотудан да бизгән шул инде.

ҺӘВӘСКӘР МАТУРЛЫК

Бернигә дә карамастан, торт әзер. Булдырдык! Һөнәрмәндләр – Зураб Хубулава коллегаларыныкы кебек үк матур түгел әлбәттә, шулай да бик күркәм!

– Яраткан кешегә бик тәмле, – дип күнегелгән гадәте буенча төзәтә корректор, кашыгын ялый-ялый.

«Татарстан» журналы редакциясе һәм «Завтрак со смыслом» программасын төшерү төркеме татлы тәгам ератучылардан булып чыкты – бик тәмләп авыз иттеләр. Торт шундый зур иде, һәркемнең өенә кучтәнәч итеп алып китәргә дә җитте. Татлы тәм-том бигрәк тә каләм әһелләренең әбибабайлары күңеленә хуш килде. «Балачак тәмен хәтерләтә, – дип ләззәтләнде алар, торт белән чәй эчә-эчә. – Әмма нәрсә тәме икәне генә аңлашылмый...»

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

Торт бүлешергә Америкадан журналыбызның тышлыгы героинясы да очып килде. Брайтон Бичта мондый сыйны пешерә белмиләр икән.

Фото: Александр Эшкинин

1 Аерабыз!

2 Салабыз!

3 Туглыйбыз!

4 Алабыз!

5 Пешерәбез!

6 Җыябыз!

7 Бизибез!

8 Пешерәбез!

9 Эретәбез!

10 Язабыз!

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Где купить журнал "ТАТАРСТАН"
Мөнда «Татарстан» булды
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Буа башлыгыннан яшелчәләр белән пешкән сарык ите
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
11 декабря 2020
Шамил Идиатуллин икенче тапкыр «Большая книга» әдәби премия лауреаты булды
10 декабря 2020
«Казан утлары» журналы кеса форматындагы татарча китаплар чыгара башлады
Татар җәмгыятьчелеге Рафаэль Ильясовны соңгы юлга озатты
09 декабря 2020
Татарстан геройларына «ТАССР төзелүгә 100 ел» медален тапшыру хакында карар чыкты
әһәмиятле
«Тел ул – мистик субстанция»
Телне берничә сәгатьтә өйрәнү... Бу мөмкинме? Лингвист-полиглот Дмитрий Петров киңәшләре
игелекле
Коткар Россияне, Америка!
Чит ил ярдәме бабаларыбызны ничек ачлыктан алып калган
игелекле
Салавычның кендек әбисе
Аналар көненә багышлап
мәңгелек
әһәмиятле

Реклама 16+

ҮЗЕБЕЗДӘ ҺӘМ ВАКЫТТА АДАШСАК...

Автор: Луиза Янсуар

Соңгы ике сезонда киң экраннарга шактый күп сериаллар чыкты һәм рейтингларда һәрберсе үз урынын яулады. Арада әллә ни зур промо каралмаган һәм күз уңыннан читтәрәк калган, әмма һичшиксез игътибарга лаек берничәсенә тукталырга булдык. Бу сериаллар нигездә бер сезонга ия, кайбер проектлар пандемия шартларында зыян күреп ябылды. Әмма оныталырга тиеш түгелләр, шәхсән минем фикеремчә.

Фото: https://www.kinopoisk.ru/ сайтыннан алынды

СИСТЕМАНЫҢ ЙӨРӘГЕ БУЛСА…



Томми, 1 сезон, 12 эпизод
Иле: АКШ
Жанры: детектив, драма
Режиссерлары: Кристин Мур, Сара Пиа Андерсон, Адам Аркин
Сценарий: Пол Аттанасио, Маргарет Роуз Лестер
Рольләрдә: Иди Фалько, Майкл Чернус, Эделейд Клеменс, Расселл Дж.Джонс, Оливия Люси Филипп, Владимир Каамано, Тони Патано, Томас Садоски һ.б.

Россиядә сериал 2020 елның февралендә «Амедиатека» платформасында пәйда булды. Әйтергә кирәк, бу ел сезонының иң уңыш казанган һәм күп каралган сериалларыннан дип атап булмый, әмма проект үзенең стиле, тыгыз, мавыктыргыч сюжет линиясе һәм күркәм каһарманнар галереясе, хәтта ки ансамбле белән башка күп кенә проектлардан бик тә аерылып тора. Һәм, әлбәттә, төп героиняны уйнаучы Иди Фалько харизмасы белән дә.

Абигейл Томас (кушаматы Томми) – Лос-Анджелес полициясен җитәкләүче беренче хатын-кыз полицейский. Бу урында аңа кадәр утырган начальник гауга белән китә, берьюлы 8 туташ вә ханым аны харассментта гаепли, аның шулай ук үзенең һәм хезмәттәшләренең криминал эшләргә катнашы барлыгы да ачыклана. Шәһәр мэры бу четерекле ситуациядән ничек ак вә пакь булып чыгарга белмичә баш ваткан арада, аңа яңа баш бәласе өстәлә: федераллар постка җитәкче итеп хатын-кызны билгеләргә тәкъдим итәләр, аннан да бигрәк традицион булмаган ориентацияле, камин-аут ясаган хатын-кызны – атаклы Томмины. Хәер, Томминың даны моның белән генә чикләнми. Аның «уңайсыз» һәм «үзсүзле» дигән даны да бар әле тагын.

Һәм менә мэрга үз йөзен саклап калган хәлдә, хакимияткә хатын-кызны китерүгә ризалашу белән берргәттән, аны ничек итеп үз кубызына биетергә икәнне дә уйларга кирәк булып чыга. Ярый да, Томми офисында аның күп еллар буена тәрбияләп, утыртып куйган «колагы» вә «күзләре» бар. Тик Томми килгән мизгелдән башлап бу офистагы шартларны вә кагыйдәләрне баштанаяк үзгәртә: ул бирегә креслода гына утырырга килмәгәнлеген беренче эш көнендә үк раслый.

Постын, шәһәр гражданнарының ихтирамын, сайлаулардагы рейтингын саклау иң беренче урында торган сәясәтче белән баштанаяк полицеский булган, әмма шул ук вакытта искиткеч туры сүзле, үзфикерле һәм олы йөрәкле, нечкә күңелле (әлбәттә, боларны әллә ничә кат бронежилет астында сакларга, күрсәтмәскә омтылса да) хатын-кыз, әни һәм инде әби дә булган Томми арасында каршылыклы, әмма бик тә кызыклы мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Өстәвенә, Томми бик тә ирониялe һәм үткен телле булуы белән беренче сериядән үк күңелне яулап ала. Безнең күңелне генә түгел, бөтен департаментныкын да!

Озын сүзнең кыскасы, бу икәү бер-берсенә баш бирмәскә тырышып каршылыкка керсәләр дә, икесенең дә бер-берсе кулланган тактикага соклануы ярылып ята… Менә шушы урыннан сериалның нерв җепселе ахыргача сузыла.

Идарә итү хокукы хатын-кыз кулында булганда система ничек үзгәрә ала һәм аның тирәсендәге ир-егетләр нинди метаморфозалар кичерә – бу сорауга да, бик четерекле «башкаларга охшамаган булу» темасына да уйланырга чакыра «Томми» сериалы. Ул үтә динамик башлана һәм акрынлап безне шәхси кичерешләр яссылыгы аша системага эләккән һәм анда үз урынын расларга мәҗбүр булган кешеләрнең роле, миссиясе проблемасына китереп чыгара. Томми героинясы аша без тагын бер сорауга да җавап табабыз: система кеше йөзле… хәтта йөрәкле дә була ала икән. Тик бу йөрәкнең үзенең исән калу-калмавы гына шикле…

ОҖМАХ УРТАСЫНДАГЫ ТӘМУГ

Святилище, 1 сезон, 8 эпизод
Иле: Швеция
Жанры: детектив, триллер
Режиссерлары: Энрико Мария Артале, Оскар Тор Аксельссон
Сценарий: Рэйчел Фловердэй, Чарли Флетчер
Рольләрдә: Йозефин Асплунд, Мэттью Модайн, Лоренцо Рикельми, Барбара Мартен, Уилл Меллор, Натали Рапти Гомес, Агнешка Гроховска, Филипп Ардитти һ.б.

Премьерасы шулай ук «Амедиатека» платформасында узды. Әмма ул шул дәрәҗәдә яңгырамады ки, «Кинопоиск» әле һаман да аңа бәя биреп, тиешле рейтинг-мөһерен тәгаенләмәгән. Шулай да, «Святилище», үтә характерлы жанрлы сериал буларак, күз уңыннан төшеп калырга тиеш түгел, минемчә. Ул үзенең психологиясе һәм фабуласы белән шактый кызыклы сораулар куя һәм безне аң катламының аргы ягында яшеренгән лабиринтларга сәфәргә чакыра. Өстәвенә, соңгы дистә елларда үзенчәлекле төсмер алган һәм инде швед киносына хас булган атмосфера, визуал белән дә җәлеп итә.

Гадәти швед супермаркеты хезмәткәре Хелена көннәрдән бер көнне юлга кузгала. Аның белән без, тамашачы да. Әлбәттә, ул бара торган юлның пейзажлары безне беренче кадрлардан ук сихерли, кызыктыра. Һәм, аңлашыла инде, контраст та тудыра: юкка гына безне Италия Альпларында урнашкан элиталы ябык хастаханәгә алып бармыйлар бит инде... моның интрига башы булуы анык билгеле.

Хелена бирегә балачактан аерылган һәм сирәкмирәк кенә күреп үскән игезәк туганы Сириның хәлен белергә – аны туган көне белән тәбрикләргә дип килә. Һәм икенче көнне Хелена инде... үзенең документлары белән качып киткән Сири ролендә уяна.

Сири ролендә калгач, ул башта гауга кубара, ситуацияне ачыклауларын таләп итә. Ситуацияне бераү дә ачыкларга ашыкмый: Сири биредә шактый күп кәмитләр эшләгән булып чыга. Һәм менә Хелена өчен беренче көнне җәннәт почмагы булып күренгән пансионат акрынлап барлык яклары белән ачыла башлый. Һәркем аерым үз йортларында яшәгән һәм беренче карашка абсолют «иректә» булган пациентлар белән табиблар арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы йомгагы аны бөтенләй дә таңга калдыра. Хелена үзенә бирергә дә шикләнгән сорауга китерә: кем монда җүләррәк тә, кем нормаль? Һәм, гомумән, нәрсә ул психологик норма?

Йозефин Асплунд героинясы фильмның буеннан-буена үзенең абстракция белән кайнар, хәтта ки дуамал характерны бербөтенгә берләштергән уены белән киеренкелектә тота. Ул уйнаган үз акылында булган Хелена белән психик тайпылышлы Сири арасында сюжет тирәнәйгән саен чагыштырулар ясап карыйсың. Гомумән, каст зур тәэсир ясый – геройларның барысы да калку, җете һәм характерлы.

Тора-бара без бу пансионатның икенче катламын гына түгел, ә өченче катламын да ачабыз. Һәм аңлыйбыз: мондагы тикшеренүләр пациентларны дәвалауга гына юнәлтелмәгән, мондагы табиблар кайчандыр үзләре үк бирегә сорауларына җавап эзләр һәм... табар өчен килгән.

Оҗмах уртасында яңадан беренчел сафлыкка кайтып буламы? Әллә бу нибары иллюзия генәме?

ҮТКӘНГӘ КАЙТСАК, НИШЛӘР ИДЕК?

Переправа, 1 сезон, 11 эпизод
Иле: АКШ
Жанры: драма, фантастика, детектив
Режиссерлары: Дэвид Фон Энкен, Роб Боумен, Дэвид Бойд
Сценарий: Джей Битти, Майкл Нардуччи
Рольләрдә: Стив Зан, Натали Мартинес, Томми Бастоу, Роб Кэмпбелл, Рик Гомес, Маркус Харрис, Грант Уитни Харви, Джей Карнс, Симона Кэссел, Келли Миссал һ.б.

Кайчандыр дөньяны шартлаткан Lost (безнең прокатта «Остаться в живых» буларак билгеле) 6 сезон буена күңелне җилкетеп, нерв җепселләрен киеренкелектә тотты. Ә менә шул ук продюсерлар зур өмет баглаган «Переправа» әлегә бер сезоны белән кала бирә. Гәрчә, әйтергә кирәк, идеясе һәм сюжет линиясе бик кызыклы, җәлеп итәрдәй булса да. Дөрес, төшерүчеләргә һәм фабуланы тәкъдим итүчеләргә сораулар юк түгел, каст ягыннан да кайбер рольләргә симпатия туып җитми, әмма нигездә бу җиренә җиткереп эшләнгән сыйфатлы һәм кызыклы проект.

Беренче эпизодта ук сериал үзенең ачкыч вакыйгасы белән аң катламы аша үтеп керә һәм кызыксынуны иң югары ноктасына җиткерә: Орегон штатындагы гап-гади Порт-Канаан шәһәрчегендә җирле шериф белән аның ярдәмчесе пляжда аунап яткан кеше гәүдәсенә юлыгалар, әмма ул гәүдә берәү генә булып чыкмый, суда бихисап кеше барлыгы ачыклана. Коткару хезмәтләрен чакыртып, батучыларны тартып чыгара башлыйлар. Барлыгы 450 кеше табыла.

Билгеле инде, федераллар һәм башка ведомстволар килеп төшә һәм бу эшне үз кулына ала. Шериф әнисен югалткан бәләкәй кыз Лиянең кайгысын йөрәгенә якын ала, алар сөйләшеп китәләр. Лиянең Библияне белмәве, гомумән җир тормышын күзалламавы ачыклана. Баксаң, бәлага юлыккан бу кешеләр төркеме барысы да – ерак киләчәктән. Хәзерге кешелек белән киләчәктәге кешелек арасындагы 150 һәм аннан да арырак ел вакыт хәлиткеч булып чыга: киләчәктәгеләр сугышлар белән теткәләнгән һәм яшәү көннән-көн куркынычрак булган өзлексез апокалипсиста яши. Алар бирегә хәлне үзгәртер өчен кайтырга булганнар...

Сериалның үз кодлары һәм теле бар – бу сөендерә һәм сихерле. Без киләчәктә кешелекнең Югары затлар белән Түбән затларга бүленгәнлеге турында беләбез. Кайсыдыр бер төркем затлар эволюция барышында көчлерәк булып әверелгән һәм, аңлашыла инде, хакимиятне үз кулларына алган. Һәм шул «затлылар» башкалардан азат булыр, рәтләрне чистартыр өчен вирус уйлап тапкан...

Әгәр башка барып сыеныр урыны калмаган, йә булмаса, башка берни дә көтмәгән бер төркем лузерлар (болай дип әле безнең заманда әйтәләр!) бүгенгедә безнең арабызга килеп төшсә, алардан нәрсә көтәргә була? Арада барысы да изге ният белән кайтачакмы? Җитмәсә, алар белән бергә арага килеп эләккән баланың – Лиянең – әнисе апекс булуы ачыкланса. Ә апексларны киләчәк дөньясында куралмыйлар, бу дөньяда исә – куллары җитсә – юк итәрләр иде. Әмма апекслар кеше кулы белән юк итәрдәй эволюция баскычында түгел инде...

Һәм менә сериал безнең алга куйган иң әһәмиятле сорау: әгәр без үткәнгә кайта алсак, нәрсә үзгәртер идек? Гомумән, нидер үзгәртә алыр идекме?!

...Ә бәлки, юк та. Монда инде бу кайтучылар, баксаң, беренчеләр генә дә түгел икән... Элеккегеләре дә – арабызда.

«Причал» журналы, №7, 1925 ел.

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

ПРОСТО | БАНК
ГРУППА ГАЗПРОМБАНКА

НИҺАЯТЬ, ЯРДӘМ АЛУ КУЛАЙЛАНДЫ

Үз бизнесың булу күп мәсьәләләрне вакытында хәл итәргә кирәк дигән сүз. Бу исә күп игътибар һәм көч таләп итә. Яңа эш башлаучы бизнесмен эшмәкәрлек мәсьәләләре белән бергә финанслар буенча директор, бухгалтер, гади хезмәткәр вазыйфаларын да алып бара. Ул бер үк вакытта сатучы да, хисап та тапшыра, үз бизнесының үсеш стратегиясен дә билгели. Эшмәкәрләрнең үзләре оста булган төп эшләре белән шөгыльләнүе никадәр мөһим икәне яхшы аңлашыла. Газпромбанк төркемендәге «КУБ» банкының (АҖ) – «Просто|Банк» проекты моны бик җиңел тормышка ашыру мөмкинлеге бирә. Без «КУБ» банкының өлкән вице-президенты – «Просто|Банк» филиалы идарәчесе Денис Хренов белән әңгәмә корып, банкның эшмәкәрләргә ничек хезмәт күрсәтүен һәм шундый катлаулы вакытта бизнеска ничек ярдәм итә алуын белештек.

– «Просто|Банк»ның үзе өчен билгеләгән миссиясе – эшмәкәрләрнең тормышын бераз булса да җиңеләйтү, аларга бизнесларын алып бару эшен кулайлаштыру. Бу күркәм альтруизммы яки аек исәп-хисапмы?

– Без win-win принцибында, ягъни ике як өчен дә файдалы нигездә эшләү мөмкинлеген табарга тырыштык. Банк сервисларын ахыр кулланучы өчен кулайлаштыру – клиентларны җәлеп итүнең иң яхшы ысулы. Өстәвенә, без әле яңа гына эш башлаган күп кенә эшмәкәрләрнең ярдәмгә мохтаҗ булуын аңлыйбыз. Аларга акча күчерү мөмкинлеге һәм эквайринг кына кирәк түгел, ә финанслар дөньясында юламан зарур. Финанс мәсьәләләрен автоматлаштырып, онлайн-бухгалтериягә керү мөмкинлеге биреп, бизнесны теркәргә булышучы, даими түләүләрне башкарып торучы таләп ителә. Безнең сервислар никадәр тулырак, аңлаешлырак һәм кулайрак булса, клиент үзенә кирәклене шулкадәр күбрәк алачак. Шул рәвешле без клиентлар белән бергә үсә барабыз. Безнең эш принцибы – һәркем куллана алырлык булу һәм гадилек. Тиз үсешебезнең нигезен без әнә шунда күрәбез.

– Банкның бизнеска чыннан да булышлык күрсәтергә сәләтле шәп продуктлары бармы? Алар бүгенге базар таләпләренә ни дәрәҗәдә туры килә?

– Проектны планлаштырганда, без ваклап сату һәм хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә сатудан килә торган акчаны җыю белән бәйле продуктларның мөһимлеген аңлый идек. Беренче чиратта – эквайринг. Без ике айлык каникуллар тәкъдим итәбез, ул вакытта хезмәт күрсәтү бәясе нульгә тигез. Әгәр айлык акча әйләнеше 100 000 сумнан артмаса, терминал өчен дә түләргә туры килмәячәк. Әлегә базарда беркемдә дә андый тәкъдим юк.

– Кече бизнес һәм яңа эш башлаучы эшмәкәрләрне, гадәттә, банклар бер дә иркәләми. Әйтегез әле, сез, бары тик кече бизнес белән генә эшлисезме, әллә инде барыбер дә зур-зур оешмалар белән эш йөртүгә өстенлек бирәсезме?

– Безнең банк төркеме эчендә билгеле бер сегментларга бүленеш алымы кулланыла. Эре бизнес белән эшләү – ул Газпромбанк төркеменең төп банкы карамагындагы беренчел хокук. Безнең проект исә нәкъ менә кече һәм микробизнес белән эшләү өчен булдырылган. Әлеге очракта йә шәхси эшмәкәрләр, йә чагыштырмача зур булмаган акча әйләнешенә ия ҖЧҖләр, йә үзмәшгуль гражданнар күздә тотыла. Бу – Россиянең барлык шәһәрләрендә дә эш алып бара торган шактый зур тармак. Барлык процесслар – теркәү һәм хисап ачу вакытында уңайлылык тәэмин итү нигезләрен корганда, без нәкъ менә шушы аудиториягә йөз тотабыз. Шуңа күрә соравыгызга җавап анык: безнең банк – кече эшмәкәрләр өчен.

– Шундый күпсанлы, колачлы булуына карамастан, ни өчен банклар бу сегментка әллә ни игътибар бирми?

– Мин кече бизнеска тиешле игътибар күрсәтелми дигән сүзләр белән һич килешмим. Күргәнебезчә, бу өлкәдә көндәшлек көчле һәм эре финанс институтларының барысы да диярлек хәзер кече бизнес өчен үз тәкъдимнәрен яхшырту өстендә эшли. Теге яки бу сервисны кертү эшендә иң кыйммәткә төшә торганнары – читтән торып хезмәт күрсәтү сервислары. Баштагы мәлдә иң кыйммәтле, иң «затлы» сервислар, мобиль банк һ.б. иң эре клиентларга тәкъдим ителде һәм алар өчен генә ачык иде. Чөнки болар барысы да нульдән башлап яңа продукт булдыруны, бик кыйммәтле, югары классы белгечләр яллауны һәм озак вакыт таләп итә. Бу чыгымнар исә күрсәтелә торган хезмәтнең бәясендә чагыла, ә андый хакны зур компанияләр генә күтәрә ала. Әмма вакытлар узу белән, технологияләр арзаная бара. Өстәвенә, читтән торып эшли торган сервисларны күбәйтү филиаллар, бүлекләр һ.б.дан гыйбарәт хезмәт күрсәтү челтәрен төзүгә тотыла торган чыгымнарны булдырмаска мөмкинлек бирә. Инфраструктура күзлегеннән караганда, проектыбыз искиткеч кулай булып күренә. Мондый структура кече эшмәкәрләргә бөтен Россия Федерациясе буенча хезмәт күрсәтергә һәм сервислардан һәркем файдалана алырлык итәргә мөмкинлек тудыра.

– Сезнең «Просто|Торговый» тариф планы башка банкларның тәкъдименнән ни белән аерыла? Ул кемгә йөз тота һәм аннан кем файдалана ала?

– «Просто|Банк»ның ике айлык каникул бирү каралган тәкъдименең уникальлеге шунда: ул эшмәкәргә өстәмә чыгымнарсыз икенче терминал алырга мөмкинлек бирә. Безнең тарифлар аңа ни дәрәҗәдә уңайлы, дистанцион банкыбыз интерфейсы аны ни дәрәҗәдә канәгатьләндерә, ахыр чиктә, безнең колл-үзәк белән эшләү аңа ни дәрәҗәдә уңайлы – эшмәкәр боларны сынап карый ала. Икенче яктан, эквайринг өчен ике ай түләү алынмый торган мондый тариф әле яңа гына эш башлаган эшмәкәрләр өчен бик шәп. Алар әле бер-ике ай гына эшли, клиентлар кайчан килә башлар икән дип көтә, акча әйләнешен әле арттырырга гына керешә. Әлбәттә, җиһазларның бәясен беренче көннән үк түләргә кирәк булган гадәти продуктлар мондый вазгыятьтә бизнеска шактый җитди авырлык булып тора. Без исә: «Рәхим итегез, ике айлык аренда каникуллары. Сез эквайринг операцияләре өчен генә түгел, җиһазлар өчен түләүдән дә азат», – дип әйтәбез. Якын арада өстәмә рәвештә без онлайн-кассалар сатып алу һәм куллануга бәйле кызыклы тәкъдим ясарга, шулай ук кредит бирүнең гадиләштерелгән системасын корырга планлаштырабыз.

Просто|Банк. Ниһаять, бик гади.

www.prostobank.online
Тел. 8 (800) 550–51–37

Реклама. «КУБ» банкы (АҖ), Газпромбанк төркеме, РФ Үзәк банкының 15.09.2015 елда бирелгән 2584 номерлы генераль лицензиясе

[1] Отыш-отыш.

РЕСПУБЛИКА БЕЛӘН 65 ЕЛ БЕРГӘ

Быел Татарстан тантаналы рәвештә ТАССР төзелүенең 100 еллыгын билгеләп үтә. 2020 елның зур юбилейлары рәтеннән, һич тә икеләнмичә, төбәктәге төп предприятиеләрнең берсе өчен мөһим бер датаны – «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнең 65 еллыгын да санарга була. Чыннан да төбәкнең икътисадына һәм социаль өлкәсе үсешенә саллы өлеш керткән компания, озак еллар дәвамында татарстанлыларны җылылык белән тәэмин итеп, республикабыз белән иңгә иң үсте, үзгәрде.

АЯККА БАСУ ЧОРЫ

Сугыштан соңгы чорда ТАССРга халык хуҗалыклары объектларын һәм халыкны энергия һәм җылылык белән тәэмин итү бурычы куела. Республиканың газ тармагы барлыкка килү тарихы 1950 нче елларга – Миңлебай – Казан газүткәргеч магистрален кулланышка тапшыру вакыйгасына барып тоташа. Ул сугыштан соңгы СССРда озынлыгы ягыннан – өченче, Татарстанда беренче була. Предприятие үсешенә 1969 елда проект-смета бюросы һәм укыту курслары комбинаты ачылу да зур йогынты ясый. 1970 нче елларда Советлар Союзында беренче тапкыр Миңлебай – Казан продукт үткәргече буенча сыекландырылган газ транспорты гамәлгә ашырыла, Казан Оргсинтез белән Түбән Кама Нефтехимга чимал китерелә. Яңа газүткәргечләр пәйда булу нәтиҗәсендә авылларга газ килә һәм, СССРда беренче булып, этан фракциясен югары кискенлек режимында магистраль үткәргеч аша транспортлау процессы үзләштерелә. 1980 нче еллар республиканың җылылык-энергетика комплексы үсешендә тагын бер үсеш ноктасы була – Түбән Кама сәнәгать төененә газ китерү–читкә җибәрү үткәргече кулланышка тапшырыла, Түбән Камадагы ТЭЦ -1, ТЭЦ-2, КАМАЗ җылылык-электр үзәге газны ягулык буларак куллана башлый.

ҺӘР ЙОРТКА ГАЗ

Торак пунктларны табигый газ белән тәэмин итеп, Татарстан газчылары республиканың һәр кешесе өчен уңайлылыклар тудыруга үз өлешен кертте. 1950 нче еллардан башлап, торак фонды сыекландырылган балонлы газ белән тәэмин ителде, әмма 1970 нче еллар башында табигый газга күчә башладылар. Бу процессны

РЕКЛАМА. Фотолар «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнән алынды

тизләтү өчен, ТАССРны газ белән тәэмин итүнең генераль схемасы эшләнде. Шуны искә төшереп үтик: авыл җирләрен табигый газ белән тәэмин итү дәрәҗәсе 1990 нчы еллар башына 5% була, ә инде 1995 ел башына ул 35,5% ка җитә. Илне модернизацияләү газ тармагында да яңа ысуллар куллануны таләп итә. Шулай итеп, Татарстан Республикасының беренче Президенты – һәрвакыттагыча стратегик фикер сөрешенә ия Минтимер Шәймиев, алдан күрүчәнлек күрсәтеп, газлаштыруның төгәлләнүе турында указга кул куя. Указга ярашлы, 1995–2001 еллар эчендә Татарстан Республикасында 340,4 км газны китерү-читкә җибәрү үткәргече, 30 автоматлаштырылган газ бүлү станциясе, 18608,4 км түбән басымлы газүткәргеч төзелә һәм кулланышка кертелә, 329 629 фатирга газ үткәрелә. Шул рәвешле, 2003 елның августында Татарстан Республикасын табигый газ белән 100 процентка тәэмин итү программасы төгәлләнә. 2003 елның август аенда кулланышка Уренгой–Ужгород һәм Казан–Түбән Новгород магистраль газүткәргечләре арасында тоташтыргыч газүткәргечләрне тапшыру вакыйгасы Россиянең Газ белән тәэмин итү буенча бердәм системасы өчен дә зур вакыйга була. Татарстан илдә табигый газ белән тәэмин итү дәрәҗәсе буенча алдынгы урынга чыга.

– Татарстан газчылары һәр йортка, һәр фатирга барып җитте. Безнең республика өчен газлаштыру – бөтен буыннарның хыялы иде. Газның авылларга килеп җитүе өчен без сезгә бурычлы, – диде ул чакта Минтимер Шәймиев.

КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

2020 елда Татарстан газчылары эшчәнлегендә стратегик планнар коруга бөтенләй яңача якын килү гамәлгә кертелә. Ул планнар масштаблы программалар ярдәмендә тормышка ашырыла. Шуларның берсе – 2023 елга кадәр ТКХ, сәнәгать предприятиеләрен газлаштыру буенча төбәк программасы. Программага ярашлы, табигый газны куллану күләме 1800 млн кубометр тәшкил итәргә тиеш, халыкны газ белән тәэмин итү күләме – 99,71%. Шулай ук Җәмгыять тарафыннан 2021 елдан алып, 2025 елга кадәрге чорда газ белән тәэмин итү һәм газ үткәрү үсеше программасы әзерләнә, анда республиканың 94 торак пунктында бистә араларында газүткәргечләр һәм редуцияләнгән газ пунктлары төзелеше карала. Проектның мөһим бер этабы булып, Казан шәһәренең газ бүлү челтәрләренең ышанычлылыгын күтәрү программасы тора, ул 2031 елга 50 км озынлыкта боҗралы һәм резервлы газүткәргечләр системасы төзелешен күздә тота. Әлеге система ремонт яки торгызу эшләре вакытында халыкны газ белән өзлексез тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк. Газчыларга инновацион технологияләр дә ярдәмгә киләчәк – юлдашлы геодезия җиһазлары җир астындагы полиэтилен газүткәргечләрне эзләячәк. Җәмгыятьнең телемеханикалаштыру программасы читтән торып идарә итү системасын җайга салачак һәм гадәттән тыш очракларны тиз арада хәл итү мөмкинлеге бирәчәк. Программа тулысынча гамәлгә ашырылгач, линияле өлештә телемеханикалаштыру дәрәҗәсе – 99,2%, ГРС – 97,55%, ГРП – 23,1% тәшкил итәчәк.

Республика ягулык-энергетика комплексының әйдәп баручы предприятиесе ел саен «Газпром» ГАҖнең иң яхшы бүлекчәләре арасына керә, ул бүгенге көндә Россия Федерациясенең үзәктәге төбәкләренә, ерак һәм якын чит илләргә 240 млрд кубометрдан артыграк табигый газ озата, шул исәптән 18 млрд кубометр газ белән Татарстан Республикасын, шулай ук күрше республикаларны һәм өлкәләрне тәэмин итә. Хәзерге вакытта республикада 1 млн 500 мең фатирга газ кергән, ә «Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте коллективында 10 меңнән артыграк кеше эшли. Һичшиксез, Татарстан газчыларының республика үсешенә керткән өлеше, аның тотрыклылыгы һәм бүгенге казанышлары ихтирамга лаек. Күп еллар дәвамында нәкъ менә алар үзләренең катлаулы, ләкин әһәмиятле хезмәтләре белән коммерция предприятиеләренең эшләвен һәм халыкның иминлеген тәэмин итә. «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ коллективында югары квалификацияле белгечләр эшли, алар теләсә кайсы бурычны төгәл башкарып чыга. Быел алар республика белән бергәләп, туган предприятиеләренең юбилеен билгеләп үтә. Алар менә 65 ел инде Татарстанга яңадан-яңа үрләр яуларга ярдәм итә!

СЫЙФАТЛЫ АЗЫК-ТӨЛЕК – ТАТАРСТАНЛЫЛАРГА. ҺӘМ АЛАЙ ГЫНА ДА ТҮГЕЛ

ТР Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына быелгы Юлламасында Рөстәм Миңнеханов, «безнең уртак бурыч – республика агросәнәгать комплексын югары нәтиҗәле һәм конкуренциягә сәләтле тармак итү», дип ассызыклады.

Республика аграрийлары быел ничек эшләделәр, киләчәккә алар үзләренә нинди максатлар куялар, азык-төлек, шул исәптән хәләл продукция экспортын ничек арттырырга – бу турыда «Татарстан»га Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сөйләде.

– Марат Азатович, узып баручы 2020 елда Сез алып бара торган тармакта булган төп вакыйгалар турында сөйләгез әле.

– Агымдагы елда без тармактагы табыш китерми торган хуҗалыклар өлешен киметүгә аерым игътибар бирдек. Шул максатларда, булган резервлардан файдалану буенча чаралар планын эшләп, күчмә аудитлар уздырылды. Алга таба бу эшне максатчан дәвам итүне һәм түбән нәтиҗәле предприятиеләргә ярдәм итүне планлаштырабыз.

Җирдә эшләүче һәм республика азык-төлек иминлегенең нигезен тәэмин итүче Кеше үз хезмәте өчен тиешле түләү алырга хокуклы. Авыл хезмәтчәннәренең хезмәт хакын күтәрү максатларында без барлык төр авыл хуҗалыгы эшләрен бәяләү буенча даими эш алып барабыз, тәкъдимнәр әзерлибез, аларны предприятиеләргә, муниципаль районнарга җиткерәбез. Тармак хезмәткәрләрен эшкә мотивацияләү өчен, югары нәтиҗәләргә ирешү юлында ярыш ысулын үстерүгә ярдәм итә торган кызыксындыру чаралары эшләнде.

Мәсәлән, кече хуҗалыкларның позицияләрен ныгыту өчен ел саен 2 млрд сумнан артык грантлар һәм субсидияләр бүлеп бирелә. Шуны да әйтергә кирәк: 2021 елда без узган елларда грантлар алган фермерларның максатчан күрсәткечләренә ирешүләрен һәм алган йөкләмәләрен вакытында үтәүләрен тикшереп торуны дәвам итәчәкбез.

Министрлык тарафыннан шулай ук «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык инициативасына ярдәм итү» илкүләм проекты составындагы «Фермерларга ярдәм итү системасын булдыру һәм авыл кооперациясен үстерү» федераль проекты гамәлгә ашырыла. Бу юнәлешне финанслауга 2021 елга 320 млн сум акча бүлеп бирү планлаштырылды.

– Дөньяда хәләл продукция куллануга карата күзәтелә торган тотрыклы тренд – товар җитештерүчеләр өчен менә дигән мөмкинлек. Аграрийлар моннан ничек файдалана?

– Сез хаклы, бу уңайдан безнең алда республиканың агросәнәгать комплексы продукциясе, шул исәптән хәләл продукция экспортын арттыру буенча җитди бурыч тора. Бүгенге көндә ул 236 млн АКШ долларын тәшкил итә, бу – еллык план күрсәткеченнән 74,2%. Шуңа күрә без, әлбәттә, продукцияне алга этәрүдә Министрлык ягыннан ярдәм күрсәтүне дәвам итәчәкбез – моны чит илләрдә дә, шулай ук Россиядә һәм республикада да сәүдә вәкиллекләре белән хезмәттәшлек аша башкарабыз. Потенциаль сатып алучылар эзләүдә экспортерлар белән хезмәттәшлек итү һәм чимал белән тәэмин итү өчен безнең товар җитештерүчеләр белән элемтәләр урнаштыру, РФ Росагролизинг линиясе буенча техника сатып алуның мөмкин булган вариантларын эшләү дәвам итәчәк. Киләсе елга Татарстанның «Хәләл» стандарты продукциясен экспортлауны 2 тапкырга арттыру планлаштырыла. Моның өчен экспортер илләрнең таләпләре үзенчәлеге нигезендә «Хәләл» стандарты продукциясен җитештерүче компанияләрне аккредитацияләү буенча Россия Авыл хуҗалыгы күзәтчелегенең республика филиалы белән эш алып барыла.

Җирле продукцияне төбәк дәрәҗәсенә чыгару кысаларында, Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, безнең җитештерүчеләргә «Мәскәү ярминкәләре» сәүдә мәйданчыклары аша Мәскәүнең азык-төлек базарларына чыгуда ярдәм күрсәтелә. Һәм, әлбәттә инде, без гадәттәгечә үзебезнең республика территориясендә ярминкә чараларын уздыруны дәвам итәбез.

– Марат Азатович, киләсе елга аграрийлар өчен төп бурычлар буларак нәрсәләр күздә тотыла?

– Киләсе ел уңышы өчен аны формалаштыру технологиясе эшләнде инде, ул тәкъдимнәр рәвешендә республиканың барлык авыл хуҗалыгы оешмаларына җиткерeләчәк.

Министрлык тарафыннан кирәк күләмдә минераль ашламалар сатып алу бурычы куелды.

Фото ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынды

Ә хуҗалыклар чыгымнарының бер өлеше өчен төбәк бюджетыннан субсидия биреләчәк.

Тармакта бара торган инновацион процесслар шартларында, терлекчелек комплексларын югары технологияле җайланмаларга күчереп, аларны модернизацияләү эшләрен дәвам итүне планлаштырабыз.

2021 елда Инвестиция меморандумы кысаларында 25 инвестиция проектын гамәлгә ашыру күздә тотыла (инвестицияләрнең гомуми күләме 25,2 млрд сум тәшкил итә), шул исәптән терлекчелек юнәлеше буенча – 18, биредә инвестицияләр күләме 16 млрд сум карала.

Нәселле терлекчелекне үстерү буенча максатчан эш дәвам итәчәк. Безнең максат – ныклы нәсел базасын булдыру, аны саклау һәм арттыру. Шуны әйтергә кирәк: республиканың нәсел хуҗалыклары товар хуҗалыкларының һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның нәселле яшь терлеккә булган ихтыяҗын 100%ка тәэмин итәргә сәләтле.

Алдагы бурыч: интенсификацияләү һәм терлекчелекнең нәтиҗәлелеген күтәрү, без моны, беренчедән, терлекләрне идентификацияләүнең бердәм системасын кертүгә бәйле цифрлаштыруда күрәбез.

“ Тармакта бара торган инновацион процесслар шартларында, терлекчелек комплексларын югары технологияле җайланмаларга күчереп, аларны модернизацияләү эшләрен дәвам итүне планлаштырабыз.

Безнең икенче мөһим бурыч – баланслы рационнар әзерләү өчен азык үзәкләрен булдыру. Республика хуҗалыкларында җитештерелә торган продукциянең сыйфатын күтәрүгә, аның үзкыйммәтен киметүгә һәм җитештерү процессларын оптимальләштерүгә, нәтиҗәдә, җитештерелә торган сөт һәм итнең табыш китерүен арттыруга ярдәм итә торган мондый үзәкләр төзү эше башланды инде.

Әйе, экспортны арттыру мөһим, әмма сыйфатлы азык-төлек, беренче чиратта, үзебезнең республика халкы өчен булырга тиешлекне аңларга кирәк. Шул ук вакытта безгә җитештерү куәтләрен арттырырга кирәк. Бу – иң мөһиме, һәм без моны эшләүне дәвам итәчәкбез. ■

КИЛӘЧӘККӘ ЛИФТ

«Яшьләребезгә уңышлар телим, һәм сезнең һәр башлангычыгызга ярдәм итәчәкбез дип ышандырам», – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2010 елда Республика яшьләр форумында катнашучылар белән очрашу вакытында. Очрашу талантларга ярдәм итү һәм үстерү буенча зур проектка нигез булды. Быел аңа 10 ел тулды.

«Заманәлиф» – латин имласындагы заманча татар әлифбасы шулай дип атала. Мисал өчен, аны чит илләрдә яши торган татарлар куллана. Татар сүзләрен латин хәрефләре белән язганда, ул тел белән таныш булмаган чит ил кешеләренә аңлаешлырак. Тагын әле ул – күпмедер дәрәҗәдә милли традицияләрне халыкара дәрәҗәгә чыгару өчен тренд та. Менә шушылардан илһам алып, Талантлар Университеты студенты Алия Минһаҗева яшьләр өчен «Zamanalif Wear»[1] киемнәр брендын уйлап чыгарган һәм аны социаль челтәрләр аша тарату буенча уңышка ирешкән. Алдагы планнары – бренд тирәсендә тулы бер экосистема булдыру. Быел Алия мәктәпне тәмамлый. Алга таба белем алу буенча вариантлары төрле, әмма ләкин кыз күбрәк хокук белемнәренә тартыла – эшкуар хокукый яктан белемле булырга тиеш. Боларның барысы да Талантлар Университеты программасы ярдәмендә тормышка ашырылган, шуның нәтиҗәсендә Алия үсә алган, хәтта ки өлкән эшкуарларны көнләштерерлек тизлек белән уңыш казанган.

КӨЧЛЕ БУЫН

10 ел эшләү дәверендә Университет 1200 сәләтле баланы үзенә туплаган. Университетның беренче проектлары урынга чыгып эшләнгән. 2015 елда «Мине шәһәрем – минем талантым» программалары кысаларында аның белгечләре «КАМАЗ» машинасында күчмә интерактив күргәзмә оештыра. Әчтә техника һәм җиһазлар була, шулар ярдәмендә балаларга республика предприятиеләре – автомобиль җитештерүчеләр турында, шулай ук Университетның ничек итеп республика җитештерүчеләре белән аларның булачак кадрлары арасында диалог булдыруда арадашчы ролен уйнау мөмкинлеге турында сөйлиләр.

– Бүген без әлеге юнәлештә Татарстанның эре компанияләре – «КАМАЗ», Казан вертолет заводы, ICL[2], «Ак Барс» банк, «Унистрой» һ.б. белән хезмәттәшлек итәбез. Предприятиеләр мәктәп укучыларының һәм студентларның конструктив идеяләрен кабул итәргә ияләшә генә башлады әле, әмма берничә кызыклы мисал да бар инде. Мәсәлән, Бөгелмә көллиятендә укучылар җирле предприятиегә мобиль комплекслар ярдәмендә бораулау җайланмаларына ремонт ясауны оптимальләштерү һәм шул рәвешле чыгымнарны киметү проектын тәкъдим итте, – дип сөйли Университетның башкарма директоры Айдар Акмалов. – КАИның Чистай филиалында студентлар исәпләү җайланмаларына ябыштырыла торган инструкция кәгазе җилеменең адгезив үзенчәлекләрен көчәйтә торган технология эшләделәр. «Ак Барс» банк безгә берничә, аерым алганда, банк карталарын хезмәтләндерү өчен куркынычсызлык системаларын булдыру буенча бурычы белән мөрәҗәгать итте. Без хакатон үткәрдек, анда Иннополис студентлары җиңеп чыкты. Университет – эш бирүче яки тренировка өчен кейс бирергә әзер булган компания белән булачак белгечләр арасындагы күпер ул. Яшь белгечләр тәкъдимнәр белән чыга, компанияләр аларга ярдәм итә. Һөнәри яктан үзеңне табу өчен зур адым бу. Безнең уңышларның бер күрсәткече – студентларның эшкә урнашуы. Андый мисалларны берничә дистә санарга була.

ҺӘРКЕМГӘ ҖИТӘРЛЕК КАПИТАЛ

Университетның максаты – талантлы яшьләрне Татарстанда алып калу, «талантлар икътисады» – сәләтле яшьләр хезмәт базарының ихтыяҗына гына җавап биреп калмыйча, республика ярдәме белән үзенең проектларын, предприятиеләрен, эш урыннары булдыра торган система барлыкка китерү. Университетка керү җиңел – халыкара һәм федераль олимпиадаларда һәм республика реестрына кергән конкурсларда уңышка ирешергә һәм utalents.ru сайтына гариза бирергә кирәк. Университет студентларына – 12–30 яшь. Гариза канәгатьләнде-

[1] заманалиф веа, [2] ай си эл

Реклама. Фото «КОУТ 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасыннан алынды.

релгәннән соң, сайтта булачак студентның шәхси кабинеты ачыла, ул компетенцияләргә диагностика үтә (предметлар һәм soft skills[3] буенча), шуннан соң аңа цифрлы пароль бирелә. Аннан соң ул үзенең үсеш планын төзи. Укырга кергәндә, студентның хисабына 100 балл, ягъни 50 мең сум салына. Бу акчаларны ул үзенең проектына яисә өстәмә белем алуга тота ала. Олимпиадаларда һәм конкурсларда уңышларга ирешкән саен аңа баллар исәпләнә, алар да капиталга әйләндерелә.

– Шул рәвешле без балаларга белем алуның иң нәтиҗәле социаль лифт икәнлеген төшендерәбез. Әгәр алар үсешкә йөз тота икән, бу аларга бик нык ярдәм итә. Параллель рәвештә без республиканың югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итәбез, чөнки укучылар үзләре теләгән юнәлеш буенча белем алуларын дәвам иттерсен иде, дип телибез. Укучыларыбызны актив рәвештә эшкуарлыкка җәлеп итәбез. Проектларын эшләп чыгарга, финанслау чыганакларын планлаштырырга, грантларга гаризалар бирергә ярдәм итәбез. Үзләрен эшкуарлыкта сынап караганнарның 80 проценты минеке түгел, дигән нәтиҗәгә килә. Әмма тегеләре дә, болары да алга таба үзләренең һөнәри юлын аңлы рәвештә сайлаячак инде, – дип Айдар Акмалов.

Университет даими рәвештә остазлар исемлеген киңәйтә. Нигездә алар – мәктәп, белем бирү үзәкләре, университетлар укытучылары. Алар өчен аерым профессиональ үсеш программасы булдырылган, ул алга таба үсешкә булышлык итә. Университет белән остаз сыйфатында предприятиеләрдән белгечләр, шулай ук эшкуарлар хезмәттәшлек итә.

– Без мәктәп укучыларының әти-әниләре белән эшкә зур игътибар бирәбез. Кайчак аларның бала өчен иң яхшы мөмкинлекләр турындагы күзаллаулары аның үзенең омтылышлары һәм ресурслары белән туры килми. Без андый очракларда баланс табарга тырышабыз, – ди Айдар Акмалов. – Моннан тыш, безнең өчен әти-әниләр ягыннан элемтә дә мөһим. Әти-әниләрнең күбесе безнең программалар буенча шөгыльләнә торган балаларның үсешкә омтылышы артуын әйтә.

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

2010 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов балалар һәм яшьләр белән очрашу үткәрде, анда республикада яшь талантларга онлайн ярдәм күрсәтү буенча платформа булдыру идеясе яңгырады. Концепция шул ук елны эшләнә башлады. 2012 елда расланды, ә 2014 елда «2015–2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы эшли башлады. Аның операторы итеп яңа оешкан Талантлар Университеты билгеләнде.

УҢЫШ ЛАБОРАТОРИЯЛӘРЕНДӘ

Университет республиканың министрлыклары белән уртак проектлар да эшли. Даими рәвештә ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә «Ел инженеры» конкурсы үткәрелә – проект студентларга һәм яшь белгечләргә республика предприятиеләренең гамәли бурычларын хәл итәргә мөмкинлек бирә. Бер төркем проектлар Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм ТР Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә гамәлгә ашырыла.

Бүген Университетның иң перспективалы юнәлешләренең берсе – «Сириус» Белем бирү үзәге моделе буенча төзелгән Республика сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү үзәге. Ул Казанда «Казан ачык талантлар университеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Республика олимпиада үзәгенең хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә барлыкка килде. Үзәкнең төп мәйданы «Дуслык» сәламәтләндерү-белем бирү комплексында урнашкан. Һәр ай башында ике яки өч атналык профильле программалар эшли башлый. 2020 елда программа өч – фән, сәнгать һәм спорт юнәлешләрен үз эченә ала.

Үзәк базасында 18 фәнни-тикшеренү лабораториясе, уку кабинетлары һәм робот техникасы, виртуаль чынбарлык, тулыландырылган чынбарлык, яңа препаратлар синтезы, яңа материаллар эшләү, технологик процессларны симуляцияләү һәм башка бик күп дәресләр өчен җиһазландырылган мәйданчыклар эшли.

– Үзәктә мәктәп укучылары югары уку йортлары җитәкчелегендә фәнни-гамәли эшчәнлек белән шөгыльләнсен өчен барлык шартлар да булдырылган, – ди Айдар Акмалов. – Шул рәвешле без һөнәри юнәлеш кенә биреп калмыйбыз, укучыларны чынбарлыктагы проектларга җәлеп итәбез, шулай ук алга таба монда – Татарстанда фән белән шөгыльләнеп һәм проектлар аша үсешкә ирешү мөмкинлекләрен күрсәтәбез.

[3] софт скиллс

«КУЛИБИННАР БАНДАСЫ»

Реклама. Фото «ЭНИКС» АҖнең алынды

Татарстанның күп кенә әйдәп баручы компанияләре ерактагы 1980 нче елларда – сәяси һәм эшкуарлык эшчәнлеге активлашкан, үзгәрешләр җиле искән чорда оешкан. Нәкъ шул вакытта Валерий Побежимов җитәкчелегендә яшь авиамодельләштерүчеләр түгәрәгендә «ЭНИКС» АҖнең легендар коллективы туплана, 30 елдан соң ул киләчәкнең оча торган аппаратларын җитештерү буенча тотрыклы эшли торган компания булып таныла.

1980 нче елларда Валерий Побежимов «Сокол» тәҗрибә-конструкторлык бюросының перспективалы эшләнмәләре бүлегеннән яшь авиамодельләштерүчеләрдән торган бердәм көчле команда туплый. Галимнәрнең нәкъ шушы буыны республикага һәм илгә пилотсыз оча торган аппаратлар өлкәсендә революцион ачышлар бүләк итә һәм Россиянең әлеге тармакта көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итә.

Компания мондый нәтиҗәләргә дистә еллар дәвамында предприятиенең төп коллективын саклау бәрабәренә ирешкән: аларны хәтта шаяртып «Кулибиннар бандасы» дип йөртәләр. Бүген дә коллективның атказанган вәкилләре арасында – генераль директорның беренче урынбасары Игорь Нагибин, юнәлеш буенча баш конструктор Илдар Якупов, баш конструктор урынбасарлары Вадим Кузьминский һәм Сөләйман Саттаров, тәҗрибә җитештерүенең ябыштыру участогы бригадиры Зөфәр Ваккасов, баш хисапчы Зифа Конова, икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча баш белгеч Энҗе Побежимова, механика-җыю эшләре (тәҗрибә җитештерүе) слесаре Зөфәр Идиятуллин.

Биредә барлыгы 300 кеше хезмәт куя. Хәзер «ЭНИКС» – идеядән алып, аны гамәлдә башкаруга, укыту һәм яңа техниканы хезмәтләндерүгә кадрлар тулы циклны үз эченә алган заманча җитештерү предприятиесе. Предприятиенең җыю цехларында тәүлек әйләнәсе эш кайный, санлы программа идарәсе нигезендә эшли торган станоклар гүли, конструкторлар пилотсыз оча торган яңа аппаратлар сыза, аларга ярашлы электроника һәм кирәкле двигательләр эшләнә. Компаниянең үзен үз программалары белән тәэмин итүе – аның аерым горурлыгы. Әлеге ноу-хауга чит илләрнең бөтен инвесторлары ия булырга тели.

Хәзерге вакытта предприятиенең эшчәнлегендә төп юнәлеш булып, төрле билгеләнештәге пилотсыз оча торган авиация комплексларын эшләү һәм аларны сериялап җитештереп сату тора. «ЭНИКС» АҖнең инновацион технологияләренә Россиянең оборонасында ихтыяҗ зур. Компаниянең әйләнеше 3 млрд сумга якынны тәшкил итә, иң зур ихтыяҗ – Е95 мишенена, аның буенча һава һөҗүменә каршы оборона системалары, мәсәлән, күпләргә билгеле булган «Игла» ПЗРКсы һәм «Панцирь» ЗРПКсы ата. Алар барлыгы 800 данә җитештерелгән, меңгә якын пилотсыз оча торган разведчик эшләп чыгарылган.

«ЭНИКС» компаниясе үзенең сыйфатлы һәм ышанычлы продукциясе белән егетләребезне кайнар нокталарда күп тапкырлар саклап калып, чын профессионаллар коллективы буларак, абруй яулады, аның РФ Оборона министрлыгы һәм көч структуралары белән эшләү буенча зур тәҗрибәсе бар. Быел компания үзенең 32 яшьлеген билгеләп үтә. Предприятие коллективын әлеге бәйрәмнәре белән котлыйбыз һәм эшләрендә яңа уңышларга ирешүен телибез!

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Медицина фәннәре кандидаты, офтальмолог-хирург Яков Вургафт, медицина фәннәре докторы, клиника директоры Лилия Нефедовская, медицина фәннәре кандидаты, офтальмолог-хирург Дмитрий Липинский.

КАЗАНДА КҮЗЛЕКЛӘРСЕЗ ДӨНЬЯ ТУДЫРДЫЛАР

Ил өчен җиңел булмаган 1990 нчы елларда оешып һәм, үз-үзен саклап кына калмыйча, югары дәрәҗәдәге заманча учреждение булып җитешкән компанияләр турында сөйләгәндә, бик күпләргә яхшы таныш «Третий глаз» дәвалау учреждениесен дә аерым билгеләп үтәргә кирәк. Ул Татарстанда беренче шәхси медицина фәнни-тикшеренү үзәге дә. 1998 елның август башында ачылган клиника 200 000 нән артык пациентка күрү сәләтен кайтарган.

«Третий глаз» озак еллар инде татарстанлыларга һәм башкала кунакларына яңа дөнья – иң заманча, яңа, фәнни нигезләнгән һәм практикада сынаулар үткән дәвалау ысулларын кулланып, күзлекләрсез дөнья бүләк итә. Яңадан күрү сәләте һәм күңелдә гармония хисе, кешеләр һәм әйберләр дөньясында үзеңне иркен тою – медицина үзәгендә булып чыкканнан соң, кешеләр менә шундый халәт кичерә. Кеше өчен әйләнә-тирә дөнья яктырып китә, матурлана, җете төсләр белән балкый, алар еллар буе үзләрен бимазалаган комплекслардан арына. Даими рәвештә Россия һәм чит илләр клиникаларында стажировкалар үтүче югары квалификацияле белгечләр актив рәвештә иң яңа җиһазлар һәм материаллар куллана, ул исә югары сыйфат һәм нәтиҗәнең озак вакытларга җитүен күздә тота. Биредә иң зур ихтыяҗ булган хезмәтләндерү төре – лазер коррекциясе, ул Татарстан Республикасында беренче тапкыр 1998 елда үткәрелә. Әлеге процедура кыска вакыт эчендә максималь дәрәҗәдә нәтиҗәгә ирешү мөмкинлеге бирә, коррекцияләүнең югары төгәллеген тәэмин итә; күз тукымаларына зыян минималь дәрәҗәдә була (лазер нуры бары тик мөгез катлавына гына кагыла), шуңа өстәп, тотрыклы рефракцион нәтиҗә һәм уңышсыз килеп чыгу ихтималының минималь дәрәҗәсе. Шунысы мөһим: заманча лазерның мөмкинлекләр диапазоны хәтта катлаулы рефракцион аномалияләрне дә төзәтү мөмкинлеге бирә (миопия 10 Dn артык, астигматизм – 6.0 Dn артык, гиперметропия +3.0 Dn булганда да), ә күз күремен коррекцияләү бер яки ике күзгә дә берьюлы ясалырга мөмкин. 2004 елдан башлап, клиникада офтальмологиядә шактый киң таралган катаракта (күз ясмыгы тоныклану) авыруын да җөйләр салмыйча гына бик бәләкәй итеп кисеп дәвалыйлар. Еш кулланыла торган процедуралар арасында шулай ук кератоконус, кылыйлыкны дәвалау, күз кабаклары пластикасы бар. Клиникада балаларны да, өлкәннәрне дә кабул итәләр.

– Безнең миссия – күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын тәэмин итү. Без пациент бездән бәхетле булып китсен дип тырышабыз, моның өчен табибларыбыз даими рәвештә заманча дәвалау һәм диагноз кую ысулларын өйрәнә, – дип сөйли медицина фәннәре кандидаты, Европа катаракта һәм рефракцион хирурглар ассоциациясе әгъзасы, «Третий глаз» офтальмология клиникасының баш табибы Дмитрий Липинский. – Ачылганнан алып, безнең куллар аша 200 меңнән артыграк пациент узды! Шушы вакыт эчендә безнең клиника эш процессын камилләштерү принципларыннан тайпылмады. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең куркынычсызлыгы һәм югары сыйфатлы булуы – клиниканың өстенлекле бурычы.

Биредә хезмәтләрнең сыйфатын гына кайгыртып калмыйлар, дөрес атмосфера да тудыралар – һәр белгеч үз эшен яратып башкара, үзенең белемнәрен һәм күнекмәләрен камилләштерергә омтыла. «Третий глаз» клиникасы коллективы бердәм механизм кебек эшли, һәркем үз урынында зур һәм дус гаиләдәге кебек мөһим бурыч башкара. Озак еллар дәвамында клиника үз-үзен саклап кына калмады, ә коллективның һәрбер әгъзасының үз эшенә, уртак эшкә җитди мөнәсәбәте нәтиҗәсендә заманча дәвалау учреждениесе булып формалашты. Безнең бурыч – күз авыруларын дәвалау һәм пациентларга яхшы күрү мөмкинлеген кайтару.

Медицина эшчәнлеге алып бару өчен 2016 елның 26 гыйнварындагы ЛО-16-01-004884 номерлы лицензия.
Реклама. Фото «Третий глаз» дәвалау учреждениесеннән алынды

Азат Хамаев, VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе, декабрьдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Илшат Ганиев, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры

СТРАТЕГ, СӘЯСӘТЧЕ, ЛИДЕР

– Хөрмәтле Азат әфәнде!

Шәхсән үз исемемнән һәм комбинатыбыз хезмәткәрләре исеменнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларымны кабул итегез!

Бөек фикер ияләре әйткәнчә, җиңү бары тик дәртле, ялкынлы омтылыш, туган илеңә кайнар мәхәббәт, кыюлык һәм энергия булганда гына килә ала. Сез дә һәрвакыт шулай, уңышлы дәүләт эшлеклесе генә түгел, ә республикабызның чын патриоты да булдыгыз һәм шундый булып каласыз. Сезнең тормышыгыз – дәүләт мәнфәгатьләренә хезмәт итү, тормышта сайланган принципларга тугрылык һәм көндәлек тырыш хезмәт үрнәге. Кече яшьтән авыл хуҗалыгы эшенең һәм ерак татар авылы көнкүрешенең кыенлыгын белеп үскәнсез, аннары – Татарстан сәнәгатенең җитештерү мәйданчыкларында эшче һөнәрләренең авыр хезмәтен үз җилкәгездә кичергәнсез, шул рәвешле җитәкче вазыйфаларга кадәр күтәрелә алгансыз. Һәм бүген алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советының законлы сайланган депутаты, ТР Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе буларак, республика халкы мәнфәгатьләрен уңышлы яклыйсыз. Сез актив тормыш позициягез, үз көчегезгә ышаныч һәм халык проблемаларына битараф булмау белән аерылып торасыз. Республика гражданнары Сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән мөһим социаль мәсьәләләрне кыю рәвештә күтәреп чыгасыз. Бай җитәкчелек тәҗрибәгез, максатчанлык һәм эшне ахырына кадәр җиткерә, сүзенә һәм хезмәтенә һәрвакыт тугры кеше булып кала белүегез фикердәшләрегезне яңадан-яңа һөнәри казанышларга рухландыра, сайлаучыларда – ышаныч, хезмәттәшләрегез һәм партнерларыгызда хөрмәт уята.

Сез югары дәүләт вазыйфаларында эшләүнең искиткеч бай тәҗрибәсенә ия, бу урыннарда үзегезне фикердәшләр командасы тупларга һәм аны җитәкләргә, алга куелган теләсә нинди бурычны хәл итәргә сәләтле күренекле стратег, лидер һәм зирәк җитәкче сыйфатында абруй казандыгыз. Сезне законнар чыгару тәҗрибәсе һәм дипломатик осталыгы һич бәхәс уятмый торган үткен сәясәтче буларак беләләр. Якташларыгыз Сезнең белән лаеклы горурлана, чөнки Сез эшләрдә һәрвакыт тәвәккәл зат, дусларыгыз арасында исә – игътибарлы әңгәмәдәш. Форсаттан файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы хезмәттәшегез буларак, иң ихлас хөрмәт сүзләремне җиткерәсем килә. Мин һәрвакыт Сезнең һөнәри яктан оста, белемле, эшкә сәләтле, оештыруга талантлы һәм инициативалы булуыгызны искә алам. Бу сыйфатлар киләчәктә дә Татарстан һәм Россия файдасына уңышлы хезмәтегездә булышлык итәр, дип ышанам.

Хөрмәтле Азат Кыямович! Әлеге истәлекле юбилей көнендә Сезгә чын күңелдән барлык уй-ниятләрегездә һәм эш-гамәлләрегездә уңышлар телим! Сезне яңа үрләр һәм шатлыклы вакыйгалар, изге максатлар һәм аларга ирешү өчен киң мөмкинлекләр көтеп торсын! Алга таба да тормыш энергиягез командагызга көч-куәт бирсен! Сез җан тынычлыгы, сәламәтлек, бәхет һәм иминлек насыйп булсын!

Реклама

Фото «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ тарафыннан бирелде

Дамир Кәримуллин,
«КМЖБ» АЖ
генераль директоры

ТӘҖРИБӘ ҺӘМ ЗИРӘКЛЕК

– Хөрмәтле Азат Кыямович!

«КМЖБ» АЖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән туган көнегез белән тәбриклап, иң җылы котлаулар һәм изге теләкләр ирештерәм!

Сезнең гомер юлыгыз бик күп вакыйгалар һәм казанышлар белән тулы. Сез осталык һәм зирәклек белән ныгытылган һөнәри тәҗрибә һәм искиткеч бай тормыш тәҗрибәсе туплагансыз. Киң колачлы белемлелек, актив гражданлык позициясе, максатчанлык һәм эшкә гаҗәеп сәләтегез зур хөрмәткә лаек.

Сезгә хас хезмәт сөючәнлек, үҗәтлек, нинди генә вазыйфа башкарсагыз да, алга куелган бурычларны җиренә җиткереп үтәргә мөмкинлек бирә. Иң яхшы нәтиҗәгә омтылу, принципларга һәм үз өстегезгә алган йөкләмәләргә тугрылык хезмәтегезнең төп нигезен тәшкил итә. Үз вакытында ТР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, хәзер исә ТР Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе буларак, Татарстанның авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә керткән өлешегезне бәяләп бетергесез.

«КМЖБ» АЖ Директорлар советы рәисе сыйфатында сез предприятиебез эшендә актив катнашасыз, моның өчен ихлас рәхмәт сүзләрен җиткерергә рөхсәт итегез.

Бу истәлекле көндә Сезне котларга теләүчеләр арасында урын алуыбыз безнең өчен зур куаныч. Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, шатлык, берсеннән-берсе колачлы мәсьәләләрне хәл итү эшендә яңа уңышлар телибез! Сезгә һәм якыннарыгызга имин, мул тормыш насыйп булсын!

Реклама

Шамил Яһүдин,
«Татнефтепром-Зүзәйнефть» АЖ
генераль директоры,
VI чакырылыш ТР Дәүләт
Советы депутаты

КЫЮЛЫК, ХЕЗМӘТ ҺӘМ УҢЫШ

– Хөрмәтле Азат Кыямович!

Шәхсән үз исемемнән һәм компаниябез хезмәткәрләре исеменнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Әлеге истәлекле көнне бөтен тормышыгызның Татарстан үсешенә багышланганлыгын билгеләп үтәсем килә. Хезмәт юлыгыз җиңүләр һәм кыю адымнар, нәтиҗәле карарлар белән тулы. Эшче һөнәрләр үзләштереп, завод хезмәтенең авырлыкларын үзегездә сынагач, сез тормышта яңа юнәлеш сайладыгыз һәм Россия парламентында закон чыгару эшенә актив кушылдыгыз. Тәҗрибәле белгеч, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре буларак, сез Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында күп еллар уңышлы эш алып бардыгыз.

Иң колачлы максатларга ирешергә сәләтле югары нәтиҗәле җитәкче сыйфатларына ия булуыгыз бәхәссез. Алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советының депутаты, ТР Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе буларак, Сез республика парламентында гражданнар мәнфәгатен яклау юнәлешендә мөһим эш башкарасыз. Форсаттан файдаланып, дәүләт эшендә карашлар һәм югары идеаллар ягыннан якын кеше буларак, Сезгә хөрмәтемне белдерәм.

Хөрмәтле Азат Кыямович! Әлеге гомер бәйрәмендә Сезгә нык сәламәтлек, оптимизм, бәрәкәт һәм киләчәктә дә Татарстан файдасына уңышлы эшчәнлек телим!

Фотолар «КМЖБ» АЖ һәм «Татнефтепром-Зүзәйнефть» АЖ тарафыннан бирелде

Фото «Камгэсэнергострой» КТИ» ЖЧЖ тарафыннан бирелде

Альберт Петров,
«Камгэсэнергострой»
КТИ» ЖЧЖ
генераль директоры

ХАЛЫК ЫШАНЫЧЫН АКЛАП

– Хөрмәтле Азат Кыямович!

Сезне шәхсән үземнең һәм предприятиебез хезмәткәрләре коллективы исеменнән ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Татарстаныбыз үсешенә керткән хезмәтегез өчен бүген Сезгә ихтирам һәм рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Сез сәясәттә зур уңышларга ирештегез, җәмгыятьтә танылу һәм хөрмәт казандыгыз. Сез зур абруйга ия, чөнки республикабыз халкы Сезне талантлы һәм инициативалы җитәкче буларак кына түгел, үз сүзендә торучан кеше буларак та яхшы белә. Сезнең һөнәрмәндлегегез, оештыру сәләтегез, зур сәяси тәҗрибәгез һәм шәхси сыйфатларыгыз Сез җаваплы булган һәр тармактагы бөтен бурычларны хәл итәргә һәм һәрвакыт, һәр урында файда китерергә мөмкинлек бирә.

Дәүләт Советының халык ышанычын күптән яулаган ветераннарыннан берсе буларак, Сез зирәк дәүләт эшлеклесе, ихлас патриот һәм чын парламентарий үрнәге булып торасыз. Сезгә мөһим һәм нәтиҗәле эшчәнлегегез, лаеклы тырыш хезмәтегез өчен олы ихтирамымны белдерәм.

Хөрмәтле Азат Кыямович, туган көнегездә мин Сезгә яңа идеяләр һәм яңа башлангычлар, республика данын арттырудагы игелекле хезмәтегездә ышанычлы һәм тугры фикердәшләр телим! Гармония, бәхет, уңыш юлдаш булсын, гаиләгездә һәрвакыт сәламәтлек һәм сөенеч ташып торсын!

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
facebook.com/protatarstan
twitter.com/protatarstan
БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
instagram.com/protatarstan
Реклама 16+

Александр Груничев, ТРның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе, декабрьдә үзенең юбилеен билгеләп үтә.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

СЕЗ ҮЗ ЮЛЫГЫЗ ИТЕП, ДӘҮЛӘТКӘ ХЕЗМӘТНЕ САЙЛАГАНСЫЗ

– Хөрмәтле Александр Станиславович!

«Татэнерго» компаниясе хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе вазыйфасы компетентлылык һәм һөнәри осталыкны, оештыру сәләтен, алдан күреп эш итә белүне һәм көн саен конкрет мәсьәләләрне хәл итүне сорый. Сездә бу сыйфатларның барысы да бар. Сез дәүләт хезмәтен үз юлыгыз итеп сайлагансыз.

Сезнең фидакарь хезмәтегез һәм эш тәҗрибәгез, еракка карап эш итә һәм урталыкны саклый белүегез нәтиҗәсендә Татарстанда законнарны үтәүдә, кулланучылар балансын, дәүләт һәм сатучылар арасында тиешле тотрыклылыкны булдыруда, бизнес белән хакимият арасында хезмәттәшлекне оештыруда хәерхаһлы атмосфера урнашкан.

Хөрмәтле Александр Станиславович! Сезгә чын күңелдән җаваплы дәүләт хезмәтен башкаруда зур уңышлар телим! Тормышыгызда башланган яңа ел һөнәри һәм шәхси казанышлар алып килсен! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, бәхет, уңышлар һәм иминлек юлдаш булсын!

Реклама

Валерий Сазанов,
«Газотранспорт компаниясе» ҖЧҖ
генераль директоры

ТКХНЫҢ ТОТРЫКЛЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ГАРАНТЫ

– Хөрмәтле Александр Станиславович!

Компания хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Сезнең Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе вазыйфасында алып барган эшчәнлегез – безнең гражданнарның имин яшәвенә, ресурслар белән тәэмин итә торган оешмаларның зыянга эшләмәячәгенә ышаныч ул. Сезнең һөнәри һәм кешелеклелек сыйфатларыгыз, шулай ук катлаулы хәлләрдә дөрес карарлар кабул итә һәм хезмәттәшлеккә ачык була белүегез Дәүләт комитетының нәтиҗәле эшчәнлеге гарантиясе булып тора. Эшнең нәтиҗәсенә югары җаваплылык белән карау, һәрдаим яңа уңышларга юнәлгәнлек Сезнең Татарстан сәнәгате үсеше хакына алып барган күпкырлы эшчәнлегегезгә ярдәм итә.

Тупланган тәҗрибәгез, җаваплылык, һөнәри осталыгыгыз киләчәктә дә алга куелган бурычларны уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирәчәгенә ышанам. Без Сезнең белән эшләү мөмкинлеген югары бәялибез һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен Сезгә рәхмәтлебез.

Сезгә алга таба да җаваплы вазыйфагызда уңышлар һәм ниятләрегезнең чынга ашуын телибез! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бетмәстөкәнмәс иҗади энергия, ныклы сәламәтлек, иминлек юлдаш булсын!

Фотолар «Татэнерго» АЖ, «Газотранспорт компаниясе» ҖЧҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Фәез Зарипов,
«Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ директоры

TATNEFT
АО «Альметьевские тепловые сети»

ВАКЫТ БЕЛӘН СЫНАЛГАН НӘТИҖӘЛЕЛЕК

– Хөрмәтле Александр Станиславович!

Шәхсән үземнән һәм предприятиебез коллективы исеменнән юбилеегыз белән котлауларны кабул итегез! Сезнең хезмәт биографиягез көндәлек тырыш хезмәт һәм дөрес карарлар кабул итә белү үрнәге булып тора. Озак еллар буе Сез республиканың Монополиягә каршы көрәш идарәсен җитәкләдегез, хәзер исә тагын җаваплы вазыйфага – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе итеп билгеләндегез. Сезнең финанс тармагында, тарифларның дәүләт тарафыннан көйләнүе өлкәсендә гаять зур тәҗрибәгез һәм казанышларыгыз бар.

Тарифлар тармагында законнар үтәлүенә аеруча игътибар бирә торган предприятие җитәкчесе буларак, Сезгә иң җылы тәбрикләүләребезне җиткерәм һәм киләчәктә дә уңышлы хезмәттәшлеккә өметләнеп калам.

Хөрмәтле Александр Станиславович! Сезгә ихлас күңелдән һөнәри эшчәнлегегездә зур уңышлар һәм яңа җиңүләр телим! Бәхетле, уңышлы озын гомер юлы үтәргә язсын! Авыр эшегездә киләчәктә дә уңышлар юлдаш булсын, гаилә учагының җылысы исә республикабыз данын арттыруда куәт биреп торсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, бәхет телим!

Фото «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76,
8-9272-483-384
e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

КЕЧЕ ШЫРДАН: КИЛӘЧӘККӘ ӨМЕТ БЕЛӘН...

Автор: Руфия Фазылова

Ни хикмәт, шәһәрдә кар, шыкраеп катып, бозга әйләнә дә куя. Ә авылда ул тәмле итеп аяк астында шыгырдый. Гүя яңа яуган ак кар сине сәламли... Ныклабрак карасаң, ак кар өстендә песи, эт эзләрен (ә бәлки башка, кыргыйрак берәр җанвар) эзләрен очратасың. Авылның кышы үзгә шул, табигый, җанга рәхәт...

Яшел Үзән районының Кече Шырдан авылына баргач, әнә шулай чын кышка сокланып, яңа яуган ак кар белән «сөйләшеп» кайттык.

Фото: Александр Ефремов



– Ярты ставкага булса да, почтальон хезмәтен үтим, – диде Саимә Миңнуллина

– Авыл бетмәс дип ышанам, – диде яшь фермер Булат Минһаҗев

КАЮМ НАСЫЙРИ САЛДЫРГАН МӘЧЕТ

Кече Шырдан зур түгел, 106 йортның утызында гына кеше яши. Дөрес, җәй айларында авыл җанлана икән – дачниклар кайтып тула.

Иң беренче шуны әйтергә кирәк: Кече Шырдан – Каюм Насыйриның туган авылы. Биредә яшермиләр, танылган татар мәгърифәтчесе, язучысы алар өчен горурлык кына түгел, ә авылны саклап калуның бердәнбер чарасы да. Хикмәт менә нидә – Кече Шырданда туристлык маршруты ясарга телиләр. Боз кузгалган инде – кунакларны сыйлар өчен чәйханә эшләнгән, ул җәй буе халыкка хезмәт күрсәткән. Мәскәүдән, Россиянең башка шәһәрләреннән кунаклар килгән. Каюм Насыйри акча биреп төзеткән мәчетне дә яңадан торгызганнар. Аның янәшәсендә заманча музей (шунда ук китапханә дә булачак) эшләп яталар. Матурлап ясалган кое, чишмәләр дә бөек мәгърифәтче исеме белән бәйле.

– 2015 елда, Каюм Насыйриның 190 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә, авылда беренче тапкыр бөек якташыбызга багышлап Коръән мәҗлесе уздырдык, – диде Олы Шырдан авыл җирлеге башлыгы Рәис Кәримов. – Менә шунда авылдашлар мәчет кирәк, дип әйтте. Ә нишләп яңа мәчет төзергә, дип уйлаштык. Бездә бит Каюм Насыйри үзе төзеткән мәчет бинасы исән. Аны реставрацияләп, авылдашларга кире кайтарырга мөмкин, дигән фикергә килдек. Һәм шушы идеяне Кече Шырданда туып-үскән, бүген Казандагы шәхси проект-конструкторлык бюросы җитәкчесе Асия Гобәйдуллина күтәреп алды. Аның матди ярдәме белән (әлбәттә, бүтән авылдашлар, Яшел Үзән халкы, тирә-як авыллар, предприятиеләр кулларыннан килгәнчә ярдәм итте) тарихи иман йортын яңадан эшләп чыктык. 2017 елның августында реставрацияләнгән мәчеттә беренче азан тавышы яңгырады.

Мәчетне яңарту эшләре башлангач, «Каюм Насыйриның туган җирен яңадан торгызу» фонды да оеша. Эшнең башында әлеге дә баягы Асия Гобәйдуллина тора. Каюм Насыйри музеен да әлеге ханым үз акчасына эшләтә. Аны тантаналы рәвештә февраль аенда ачарга уйлыйлар.

Инде янәдән мәчет тарихына кайтыйк. 1901 елда Кече Шырданда бер мәчет була.

К. Насыйриның туган нигезе. Дөрес, анда бүген бүтән гаилә яши

2013 елдан Россиянең Милли агачлар реестрына кертелгән тал агачы. Реестрдан күренгәнчә, талга 300 ел чамасы, биеклеге – 8 метр, кәүсәсенең диаметры – 2 метр ярым



Берничә ел элек авыл җирлеге үзидарәсе грант откан булган. Чишмәләрне шул акчага ясаганнар



Авылда сыер белән ат тотучы бердәнбер гаилә – Шәриповлар

Тик икенче мәчет төзү ихтыяҗы да туа, чөнки авылда 528 ир кеше исәпләнә. Авыл җыенында Каюм Насыйри мәчет төзелешенә 1 мең сум акча бирәчәге турында әйтә. Галим сүзендә тора да. Ни кызганыч, Каюм Насыйри яңа мәчетне күрә алмый, 1902 елда вафат була. Ә яңа гыйбадәтханә авыл халкының яраткан, изге урынына әйләнә. Совет власте килгәч, 1939 елда мәчет ябыла. Ул мәктәп функциясен үти башлый. Соңрак авылның медпункты, китапханәсе, колхоз идарәсе бинасы була. Соңгы елларда Каюм Насыйри төзеткән мәчет бинасы буш торган. Алда әйтелгәнчә, бары 2017 елда гына Аллаһ йортына яңадан җан өрәләр.

– Төрле чыганакларда Каюм Насыйри бик фәкыйрь яшәгән, сәер кеше булган дип язалар, – дип сүзгә кушылды Гүзәл Минһаҗева. – Насыйрилар нәселе бик укымышлы, гыйлемле һәм шул ук вакытта хәлле кешеләр саналган. Әтисе Габденнасыйр мулла бөтен булган акчасын, малын җыеп, Мәскәүдә зур сабын эшкәртү остаханәсе (завод дип тә әйтәләр) ача. Ике туган – Мәскәүдә, ике туган Казанда эш итә.

ШӘҺӘРДӘН – АВЫЛГА!

Авылның бүгенгесе белән кызыксынам. Мәктәп яшендәге балалар юк икән. Иң яшь гаилә дигәннәре дә илледән узган кешеләр. Аңлашыла ки, белем бирү үзәге дә юк. Алай гына түгел, авыл кибетсез дә яшәп ята хәтта. Атнага ике тапкыр ипи алып килэләр, ди үзе.

Авылның үзәге – мәчет, төзелеп ята торган музей һәм чәй йорты. Алардан читтәрәк иске клуб бинасы моңаеп утыра. «Буржуйка» миче белән җылытыла торган мондый клубларны хәзер бик сирәк авылларда очратасың. Менә шул янтайган мескен клуб янәшәдә генә яңа салынган мәчет, чәй йорты, музейга исе китеп карап торадыр кебек тоелды...

Әлеге заманча эшләнгән социаль, мәдәни объектлар янәшәсендә ике катлы яңа ике йорт та бар. Аларның берсе Асия ханым Гобәйдуллинаныкы, икенчесе аның апасыныкы икән. Шушы урамга иң беренче аяк баскач, һич кенә дә Кече Шырданны бетеп баручы авыл дип уйламыйсың. Бетә торган авылга мондый йорт салалармыни?!

– Авыл бетмәс дип ышанам, – диде яшь фермер Булат Минһаҗев та. – Һәрхәлдә, шуның өчен тырышабыз. Мин Яшел Үзән шәһәрендә үскән егет, җәйләрен биредә яши идек. Әти авылга яшәргә кайтам дигәч сөенгәннәрем! Кош-корт үстереп карыйсы килде. Аллага шөкер, яңа шөгыль безгә ошый, ә иң мөһиме – булдыра алабыз.

Минһаҗевлар алты ел элек Кече Шырданга күченеп кайткан. Башта гаилә башлыгы Җәүдәт абый авыл тормышын ялгызы башлап җибәргән. Тормыш иптәше Гүзәл Минһаҗева Яшел Үзән район газетасында хезмәтен дәвам иткән. Дөрес, атна саен кайтып йөргән.

– Җәүдәт белән Булат кош-корт алабыз дигәч, шикләнеп тә куйдым, – диде Гүзәл апа. – Тик минем егетләр бик тәвәккәл, уйласалар, тоталар да эшлиләр. Булат та акрынлап авылга күченде. Казанда ике көн эшләп, ике көн ял итә ул. Иремнең дә эш режимы шундый. Берсе эштә булганда, икенчесе авылда кош-кортларны карый.

Лаеклы ялга чыккач, Гүзәл апа да тулысынча Кече Шырданга күченгән. Миңа исә Булатның янып торган күзләре ошады. Йөзәр баш күркә, каз, тавыклар – барысы турында да яратып, белеп сөйли. Токымлы тавыклар алып кайткан. Алар яшел йомырка сала икән.

– Үзебездән арткан күкәйләрне Казанга, Яшел Үзәнгә алып барып сатам, – диде Булат. – Хәзер инде үз клиентларым бар. Күркә, тавык итен дә шулай урнаштырам. Сораучылар күп.

Күркә дигәннән, суйганнан соң, бу кошның бер түшкәсе 15–18 килога кадәр җитә. Берьюлы икешәр күркә алучылар да бар икән.

– Кош-кортларга азыкны үзебез әзерлибез, – диде яшь фермер. – Игенне сатып алабыз да тарттырабыз. Шуңа күрә безнең ит тәмле була, кошлар химиясез азык ашап үсә.

Минһаҗевлар үзләре өчен ике баш умарта да тота. Безгә дә ул балдан авыз итү бәхете тәтеде. Арттырып әйтү түгел, мондый балны ашаган юк иде... Тагын үләннәр дә җыеп киптерәләр икән. Чәйнең хуш исе, тәме турында аерым бер язма әзерләргә булыр иде...

БЕР СЫЕР ДА БЕР АТ

Кече Шырданда сарык асраучылар күп. Ә менә сыер белән ат тотучы бер генә гаилә бар. Шуңа да биредә сөткә хәтта чират икән.

Шәрипов Марсель абый белән Фәридә апа икәү генә гомер итәләр. Олыгаеп кына бергә кушылганга, балалары булмаган. Лаеклы ялга чыксалар да, ир белән хатын каралты тутырып мал асрый.

– Сыерсыз әллә ничек бит, – дип елмайды Марсель абый. – Фәридә саумыйм дип әйтсә, әлбәттә, бетерербез. Тик алай дими әле. Мин үзем малларны бик яратам.

Фәридә апа аягына операция ясаткан, шулай да зарланмады:

– Ничек тә тырышырга иде инде, физзарядка кирәк, – диде хуҗабикә. – Авылда сыер булмагач, сөткә кытлык зур. Пенсиягә өстәмә бит, акчасы да килә. Хуҗалык булгач, өйне, каралтыкураларны да яңартасы килә. Әле менә быел яңа мунча эшләп куйдык. Мал тотуның файдасы бар инде.

Бүген Шәриповлар хуҗалыгында сыер, тана, үгез, ат, утызлап баш сарык бар. Әле алга таба

да Кече Ширданны яңа сауган сөт белән тәэмин итәргә җыеналар.

– Малларга азыкны сатып аласызмы? – дидем хуҗа кешегә.

– Игенне сатып алабыз. Ә печән белән проблема юк. Ташландык бакчалар күп хәзер, анда печән үсә. Хуҗа кешеләр хәтта чабып та бирәләр. Мин трактор белән барып алып кына кайтам.

Авылның тагын бер тырыш гаиләсе белән таныштык – Миңнуллиннар. Ирле-хатынлы Ринат абый белән Саимә апа ике кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Балалар гаиләләре белән шәһәрдә яши. Ел саен диярлек авыллар арасында уздырыла торган «Иң матур йорт» конкурсында катнашып, Миңнуллинар җиңүче була икән.

Әле кар күмәргә өлгермәгән бакчадагы агач хайван, кош-корт сыннарын карап, өй эченә уздык. Ике катлы йортның тәрәзә төбендә әллә нинди матур гөлләр үсеп утыра. Тагын Саимә апа берничә савытка кыяклы суган да утырткан.

– Язга кадәр шулай суган үстерәм, артыгын күрше-тирәгә сатам да, – диде хуҗабикә.

Миңнуллиннар йорты авыл кешеләренә почта бүлекчәсе (!) булып хезмәт итә икән. Өйгә керүгә өстәл, урындык, санагыч тора. Шунда ук – газета-журналларга язылган кешеләр һәм пенсия алаучылар исемлеге дә. Хәтта почтада сатылырга тиешле товарлар да тезелеп киткән.

– Ярты ставкага булса да, почтальон хезмәтен үтим, – диде Саимә Миңнуллина. – Хәзер газета-журналлар атнага ике генә килә бит, авырсынмыйм үзе.

– Матбугатка язылучылар күпме соң? – дим.

– Әйе, бар. Егермеләп өйгә почта таратам. Унтугыз пенсионерым бар, аларга айга бер пенсия бирәм. Коммуналь түләүләр дә алам.

Моннан тыш Саимә апа социаль хезмәткәр дә – авылның җиде ялгыз әби-бабаен карый ул. Атнага ике тапкыр Яшел Үзән шәһәренә барып, азык-төлек төяп кайта икән.

Миңнуллиннар умартачылык белән дә шөгыльләнә. Каршыдагы бакчаларында утыздан артык оя кортлары бар. Кышка кортларны бакчада калдырганнар.

– Безнең эти дә умартачы иде, – диде Ринат абый. – Кечкенәдән кортлар янында үстем. Үземне белгәннән бирле корт асрыйм. Киңәшкә дә күп киләләр, кортларны сатам да.

– Утыз оя кортны карарга кем булыша? – дим.

– Хатын инде. Җае туры килгәндә малай кайта. Миңа бик кеше кирәкми дә, өйрәнгән, белгән эш бит.

«БОЗ КУЗГАЛДЫ...»

Рәис Кәримов авыл буенча йөртеп чыкты. Каюм Насыйриның нигезен дә барып күрдек. Анда бүген бүтән гаилә яши икән, дөресрәге, җәйгә кайтып йөри. Каршысында кое бар. Кайчандыр шул коедан кечкенә Каюм су ала торган булган. Тау астына төшеп, матурлап эшләнгән чишмәне дә күрдек. Бу урында шуны әйтим: кое, ике чишмәгә заманча итеп корылмалар ясалган. Берничә ел элек авыл җирлеге үзидарәсе грант откан булган. Чишмәләрне шул акчага ясаганнар. Ә коены Асия Гобәйдуллина оешмасы эшләгән.

Үзсалым дигәннән, киләсе елда биредә йорт саен 2 мең сум акча җыярга сөйләшкәннәр. Дәүләт арттырып кайтаргач, авылга трактор алырга уйлыйлар. Йорт саен кеше яшәмәсә дә, кышын һәр урамны чистартырга кирәк бит.

Авыл җирлеге башлыгы бик юан бер талны да күрсәтте. Ул 2013 елдан Россиянең Милли агачлар реестрына кертелгән икән. Реестрдан күренгәнчә, талга 300 ел чамасы, биеклеге – 8 метр, кәүсәсенең диаметры – 2 метр ярым. Мондый борыңгы – ике гасырлык имәннәр авыл клубы янында да үсә.

...Кече Ширдан бик матур урында урнашкан. Чагыштырмача Казанга да ерак түгел – алтмыш чакрым тирәсе. Гөрләп торган авылның ни өчен шулай беткәне гаҗәбрәк тә тоелды. (Колхозлар таралган, монысы аңлашыла.) Тик бит үз эшеңне башлар өчен менә дигән җир бу. Авыл җирлеге башлыгы чын күңеленнән Кече Ширданның якты киләчәгенә ышана:

– Соңгы биш елда гына берничә йортны сатып алдылар. Ә хуҗа булган йортның тирә-ягы каралган була. Шунда аның бала-чагасы да кайта, ә димәк, авыл гөрләп торачак. Туристлар өчен менә дигән урын бу. Авылның исеме халык телендә күбрәк булган саен, аңа игътибар да артачак. Өстәвенә, Асия Гобәйдуллина кебек авыл өчен янып, барысын да эшли торган кешеләр бар... Мин исә җәннәт почмагына тиң шушы авыл туристлар өчен генә түгел, кешеләр өчен яшәү урыны да булыр, дигән якты теләктә калам.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Гүзәл Минһаҗева, журналист, авыл тарихын өйрәнүче:

– Авыл турында, Каюм Насыйри язмаларыннан кала, башка мәгълүмат юк. Аның версиясе буенча, күрше Бишбатман авылында башта татарлар гомер иткән. Бу авыл тирәләренә Болгардан берничә кеше килеп, җәй буе маллар ашатып, кышка үзләренә кайтып китә торган булганнар. Болгар дәүләте җимерелгәч, әлеге кешеләр шушы җирләрне хуп күреп, бирегә күченеп килгәннәр. Бу вакытта Бишбатманда Бикташ исемле кеше яшәгән. Шул Бикташ янына килеп, яшәү урыны сайлап йөргәннәр.

Ширдан урыны аларның күңеленә хуш килгән һәм алты кеше бирегә килеп төпләнгән. Икесенең уллары да булган. Алты ир-атның да исеме билгеле түгел, әмма ике улның исемнәрен тарих саклап калган: Бираш һәм Атна Хуҗа. Моннан берничә генә чакрым ераклыкта урнашкан Иске Йорт авылында Атна Хуҗа дигән чишмә дә бар. Бираш белән Атна Хуҗаның этиләре, бирегә күчеп килгәч, Хаҗга китә һәм шунда вафат була. Ә балалары авылны үстерүне дәвам итә. Кызганыч, Кече Ширдан исеме каян килеп чыккан дигән сорауга төгәл генә җавап юк.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Катерина Котова,
Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 440 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-3337
Басарга кул куелды: 07.12.2020
Басмадан чыкты: 11.12.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә
3350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 5790 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә:

Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:

Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

«ТАТМЕДИА» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Яңа «Татарстан» елы белән!
ТАТАРСТАН 1991
ТАТАРСТАН 1998
ТАТАРСТАН 2000
татарстан 2010
ТАТАРСТАН 2016
ТАТАРСТАН 2017
Блокнот агитатора
СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА 1930
БОЛЬШЕВИК ТАТАРИИ 1935
БОЛЬШЕВИК ТАТАРИИ 1937
КОММУНИСТ ТАТАРИИ 1958
КОММУНИСТ ТАТАРИИ 1969
КОММУНИСТ ТАТАРИИ 1987
Блокнот агитатора
ВЕСТНИК 1920
КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ 1921
КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ 1922
КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ 1923
КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ 1924
ПУТЬ ИЛЬИЧА 1925
ПУТЬ ИЛЬИЧА 1925
ПРИЧАЛ 1925
ПРИЧАЛ 1925
СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА 1926
СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА 1927
Блокнот агитатора
Яңа «Татарстан» гасыры белән!
Реклама 16+